КОЛЛЕКЦИОН САН

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№5 (364)
МАЙ 2022

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ИМАННЫ ЮЛДАШ ИТЕП...

СЕЗНЕҢ БИЗНЕС ӨЧЕН ӘЗЕР МӘЙДАНЧЫК

«АВИАТОР»ДА ЭЛЕКТРОН ҖАЙЛАНМАЛАР ҺӘМ ПРИБОР ТӨЗЕЛЕШЕ ӨЛКӘСЕНДӘ ФИКЕРДӘШЛӘР БЕРЛӘШМӘСЕН ОЕШТЫРАБЫЗ.

ХЕЗМӘТТӘШЛЕККӘ ҺӘРВАКЫТ ШАТ ҺӘМ СЕЗНЕ УҢЫШЛЫ ЭШКУАР, ҖИТЕШТЕРҮЧЕ ҺӘМ БИЗНЕС БУЕНЧА КОЛЛЕГАЛАР АРАСЫНДА КҮРЕРГӘ ӘЗЕР!

Технопарк АВИАТОР
«АВИАТОР» ЭЛЕКТРОН СӘНӘГАТЬ ПАРКЫ
ТЕХНОЛОГИК ЭШКУАРЛЫК ОАЗИСЫ
Технопарк АВИАТОР
Дементьев урамы
«АВИАТОР» технопаркы
Тулырак 94 биттә
Hi Tec-КВАРТАЛ ТӨЗЕЛЕШЕ КОНЦЕПЦИЯСЕ БУЕНЧА ЭШ БАРА
+7 (906) 328-17-66
+7 (917) 227-28-28
Казан, Дементьев ур., 2Б к4
aviatorkzn.ru
mail@aviatorkzn.ru
Реклама

PRESSA

Фото Энже Нармаева архивыннан

Фото: ТР Президенты матбугат хезмәтеннән алынды

Хөрмәтле татарстанлылар!

Россия мөселманнары өчен истәлекле дата – Идел буе Болгар дәүләте тарафыннан ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы – 2022 елның төп вакыйгаларыннан берсе.

Бүген традицион ислам, дөньядагы төп диннәр белән бергә, социаль тотрыклылыкны, гаилә институтын ныгытуга, Россия җәмгыятенең ныклы үсешенә ярдәм итә.

Шунысы да куандыра: безнең күпмилләтле илебез өчен төрле халыкларның һәм диннәрнең дус-тату яшәве – тормыш нормасы, бөтен дөнья җәмәгатьчелеге өчен үрнәк.

Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путин 2022 елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетын төзергә күрсәтмә бирде. Юбилейның аеруча әһәмияте шунда: Идел буенда ислам халыкларның ирекле сайлавы нәтиҗәсендә ныгып кала һәм бары тик тыныч юл белән генә тарала.

Идел буе Болгар дәүләте тарафыннан ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү мәгариф һәм мәдәниятнең алга таба үсешенә куәтле этәргеч бирер, ә иң мөһиме – Россия мөселманнарының туплануына ярдәм итәр, традицион гуманистик кыйммәтләрне яңартуда җәмгыять һәм дәүләтнең тыгыз бәйләнешен күрсәтер дип ышанам.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы Президенты

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Гамир Дәүләтшин, Айдар Кәрибуллин,
Рафыйк Мөхәммәтшин, Разыя Сәхипова, Ксения Сёмина,
Айдар Хабетдинов, Айдар Хәйретдинов,
Фаяз Хуҗин, Зөфәр Шакиров, Айдар Юзиев
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Лариса Давыдова
Тышлыкта: Энҗе һәм Евгений Нармаевлар
Фото Нармаевларның гаилә архивыннан

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
3 220 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–1292
Басарга кул куелды: 06.05.2022
Басмадан чыкты: 16.05.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 3550 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 6770 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

سُورَةُ البَقَرَة

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

وَلِكُلٍّ وِجْهَةٌ هُوَ مُوَلِّيهَا ۖ فَاسْتَبِقُوا الْخَيْرَاتِ ۚ أَيْنَ مَا
تَكُونُوا يَأْتِ بِكُمُ اللَّهُ جَمِيعًا ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

١٤٨

Һәрберсенең юнәлә торган тарафы бар. **Сез яхшы гамәлләргә ашыгыгыз.** Кайда гына булсагыз да, Аллаһ сезне җыеп китерәчәк. Һичшиксез, Аллаһ һәрнәрсәгә кодрәтле.

«Бәкара» сүрәсе, 148 аять

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **963 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик татарстанда

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШ ӨЧЕН «БЕР ЧЕМЕТЕМ ТОЗ»

Казан Кремлендәге «Кол Шәриф» мәчетен ике меңнән артык уникаль фарсы келәме бизи. Бу келәмнәр – Иран Ислам Республикасы бүләге. Мәскәүдә оештырылган бүләк тапшыру тантанасында ул вакытта Иранның Россиядәге илчесе тыйнак кына болай ди: аның иле «татар халкының яңарыш юлында әзерләгән ризыгына бер чеметем тоз» өсти. «Тозсыз ботка да пешереп булмый», – дип җавап бирә ТР Президенты вәкиле, бөтен татарстанлылар исеменнән Иран халкына һәм ил җитәкчелегенә рәхмәт әйтеп, әлеге кыйммәтле бүләкләрне кабул итеп алганда.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

6. Хакыйкатьтә – көч
Татарстан мөфтие – Идел буе Болгарстанында исламны кабул итүнең әһәмияте турында

14. Иман һәм гыйлемгә юл
Идел буе Болгарстанында ничек һәм нәрсәгә укытканнар

16. Ислам мәдәниятен һәм җәмгыятен яңарту хәрәкәте
Ни өчен мәдрәсәләр ислахчылык үзәгенә әйләнә

20. Казан ханлыгының соңгы имамы
Кол Шәриф турында без нәрсә беләбез

22. Курсави дәвере
Татар дини реформалары карлыгачы нинди идеяләрне алга сөргән

24. Шиһабетдин Мәрҗани мирасы
Галим үзенең төп хезмәтендә нәрсә турында язган

26. Габдулла Бубый тараткан мәгърифәт нуры
Ни өчен авыл мәдрәсәсе ислам дөньясының мәгърифәт үзәгенә әверелә

28. Миллионер улы – халык хезмәтчесе
Галимҗан Баруди үз халкын дөньяга ничек таныткан

30. Ризаэтдин Фәхретдин васыятьләре
Атеизм чорында мөфти динне ничек яклаган

32. Тормыш максаты – милләтне белемле итү
Ни өчен Муса Бигиев яңарыш теориясе хатыйбы була

34. Хакыйкатькә хокук биргән диплом
Илнең мөселман өммәте өчен кадрлар һәм интеллектуаль элитаны кайда әзерлиләр

40. Ислам эстетикасы
Ни өчен «сәнгать» төшенчәсе ислам мәдәниятендә аерым бер мәгънәгә ия

46. Кухня
Интернетны шаулаткан салат нинди була

54. Дәверләр аша сәяхәт
Ислам мәдәнияте музеенда нинди раритетлар саклана

58. Җүкәтау – болгарларның Кама буендагы шәһәре
Чистай шәһәре янында нинди артефактлар табылган

72. Татар авыллары
Усы: кыйблага карап...

82. Хәтта космостан да күренә
Урта гасыр Көнчыгыш Европасының иң бөек калаларының берсенә ничек барырга

109. «Туган батыр» эпосы
Массакүләм мәдәният геройларын күләгәдә калдырырлык яңа татар эпосын кем эшли

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

КАМИЛ СӘМИГУЛЛИН: «ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТЕП, ХАЛКЫБЫЗ ҮЗЕНЕҢ ЯЗМЫШЫН БИЛГЕЛӘГӘН»

922 елдан безне тулы бер мәңгелек – 1100 ел аерып тора. Бу вакыт эчендә ил-дәүләтләр, халыклар туып, үсү-ныгу чорларын кичереп, юкка чыгарга өлгергән. Ә ата-бабалар тарафыннан кабул ителгән динебез ислам бүген яңарыш чорын кичерә. Аның яшәү көче нидә? «Татарстан» журналы сорауларына Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җавап бирә.

КӨЧ-КУӘТ – ХАКЛЫКТА

– Көч – хаклыкта. Ислам – хак дин, ул сукырларча табынуга түгел, ә дәлилләргә һәм хакыйкатьне эзләүгә нигезләнә. Кешелеккә уйлау сәләте юкка гына бирелмәгән. Дәлилсез иман зәгыйфь, ышанычсыз була. Иманы ныграк булсын өчен кешенең дәлилләр эзләячәген Аллаһы Тәгалә аңлый. Хак Тәгаләнең барлыгы нәкъ менә акыл белән танылa. Шуңа күрә күп кенә галим, ба-

Фотографияләр ТР Диния нәзарәте тарафыннан тәкъдим ителде.

лигълык яшенә җиткән һәр акыллы кешенең беренчел шәригать бурычы – Аллаһы Тәгаләнең барлыгын аңлаудан гыйбарәт, дигән нәтиҗәгә килгән. Аллаһы Тәгалә хәтта болай ди: «Бел, Аллаһтан башка һичбер Илаһ юк!» («Мөхәммәд» сүрәсе, 19 аять). Ягъни Хак Тәгалә кешедән акыл белән нигезләнгән иман таләп итә. Бу беренче аңлатма. Икенче сәбәп Аллаһының Үзенең Кыямәт көненә динебезнең нигезе Изге Коръәнне саклап калырга вәгъдә бирүеннән гыйбарәт. Ул болай ди: «Һичшиксез, Коръәнне Без иңдердек һәм Без аны (гына үзгәртелү, югалудан) саклыйбыз» («Әл-Хиҗр» сүрәсе, 15 аять). Исламның күп гасырлык тарихы әлеге сүзләрне раслый. Динебезне һәрзаман диярлек юк итәргә тырышалар: хәрби походлар яки көч кулланып чукындыру дисеңме, атеизм көрәшеме яки көнбатышның ялган демократик идеаллары әләме астында исламның чын мәгънәсен идеологик бозу дисеңме... Бүген Россия үзен ислам дөньясының бер өлеше буларак таныта, ә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны без Президент Владимир Путин ярдәме белән билгеләп үтәчәкбез. Ягъни ислам ул – бернигә дә карамастан, бөтен дөньяда актив үсештә булган дин. Һәм ул кыяматкә чаклы дәвам итәчәк, чөнки Хак Тәгалә безгә моны Үзе вәгъдә иткән.

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТӨНЬЯК БАШКАЛАСЫ

– Бүген ислам – Россия Федерациясендә төп диннәрдән берсе. Шул ук вакытта төрле чорларда ул хәзерге Татарстан территориясендә, Идел буе төбәгендә кискен көндәшлек, кысрыклаулар һәм хәтта террор шартларында яшәргә, җан асрарга, исән калу өчен көрәшергә мәҗбүр булган. Иман чисталыгын ничек саклап кала алганнар соң?

– Совет атеизмы чорын бик төгәл тасвирлаган шундый бер хәдис бар: «Кешеләргә бер заман килер, ул заманда сабырлык белән динен үтәүче зат кулына утлы күмер тотучы кебек булыр». Совет елларында безнең күренекле татар имамнары, ишаннарыбыз иманнары хакына коточкыч изүләргә, сөрген газапларына, үлемгә дучар ителә.Алар барысына түзә, Аллаһка хыянәт юлына бармый. Галимҗан хәзрәт Баруди язмышының нинди фаҗигале икәнен беләсезме? Ул күренекле мөселман галиме, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, мөфти булган. Күп еллык сөргеннәргә, тентүләргә, төрле эләкләргә карамастан, ул татар халкына үз-үзен аямыйча, фидакарьләрчә хезмәт итә. Галимҗан хәзрәт ике тапкыр мөфти итеп сайлана, чөнки совет мөселманнары аның әчкерсез тырышлыгын күрә. Хәтта үлеме дә игелек юлында вакытта килә: 1921 елның 6 декабрендә мөфти хәзрәтләре, Идел буенда ачлыктан интегүчеләргә ярдәм сорап, Мәскәүгә юнәлгән була... Шундый шәхесләр бәрабәренә татарларда ислам сакланып калган да. Заманында үзләренә ислам кушканнарны үтәү бөтенләй тыелган әби-бабаларыбызның да ролен киметергә ярамый. Алар яшерен рәвештә ураза тоткан, намаз кылган, дини китаплар укыган һәм саклаган, безгә иман нигезләрен тапшырган, әмма, ни кызганыч, дини белемнәрне тапшыру чылбыры өзелгән. Революция исә барлык диннәрне дә, әйтерсең, «пауза» төймәсенә басып туктатып куйган, рухи үсеш тоткарланган. Әмма, Аллага шөкер, соңгы 30 елда Татарстанда ислам күзгә күренеп үсеш алды. Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов алып барган сәясәт нәтиҗәсе буларак, республикада мәчет-мәдрәсәләр төзелә һәм эшли, һәркайда азан яңгырый, кешеләр иманга һәм ышанычлы белемнәргә омтыла, көчле белгечләр әзерләнә, хәләл яшәү рәвеше идеяләре алга сөрелә, күпбаскычлы ислам белем бирү системасы үсә, дин фәне алга бара... Җәмгыятьтә «Казан – ислам дөньясының төньяк башкаласы, ә Татарстан – мөселман төбәге» дигән фикер ныклап урнашты.

ЯЗМЫШНЫ БИЛГЕЛӘГӘН ЮЛ

– Үткәннәргә әйләнеп кайтыйк. Ислам динен кабул итү ата-бабаларыбызның һәм киләчәк буыннарның әхлакый, мәдәни кыйммәтләрен, тормыш юнәлешләрен формалаштыруга нинди йогынты ясаган?

– Болгарлар өчен исламны рәсми рәвештә кабул итү мөһим дәүләти һәм прагматик әһәмияткә ия була, чөнки 922 ел вакыйгаларыннан соң безнең ата-бабаларыбызның икътисадны үстереп җибәреп, дипломатик мөнәсәбәтләрне киңәйтә алуы билгеле, әмма татарларның рухи мәдәниятенә ислам ясаган йогынты тагын да мөһимрәк. Мөгаен, исламны кабул итеп, халкыбыз үз язмышын билгеләячәк төп юлны сайлаган һәм Хак Тәгаләнең аерым рәхмәтенә ирешү – Аллаһның

бар кешелек өчен җибәрелгән ахырзаман Пәйгамбәре Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вәсәлләм өммәте әһле булу бәхетен үзе өчен ачкандыр. Ислам татарларга югары рухи мәдәният, мәгърифәтчелек традицияләренә һәм Аллаһы Тәгаләнең изге үгет-нәсихәтләренә нигезләнгән тирән әхлак алып килде. Гасырлар дәвамында динебез безгә тыныч хезмәттә дә, Ватан өчен яу кырларында да ярдәм итте, кайгы-хәсрәт килгәндә юаныч булды, шатландырды һәм рухландырды... Һичшиксез, татарларга ислам өлешебезгә тигән иң кырыс сынау чорында да милләт буларак сакланып калырга көч һәм мөмкинлекләр бирде.

БӨЕК МИРАСЫБЫЗ

– Үз чиратында, ислам дөньясында татар дин галимнәренең, җирле мөселманнарның роле нидән гыйбарәт? Нинди идеяләр яклау тапкан һәм ислам дөньясының алга таба үсешенә ярдәм иткән?

– Татар дини мәктәбе Россиядә генә түгел, бөтен ислам дөньясында иң борынгы һәм иң көчлеләрнең берсе санала. Мәрҗани, Гаспринский, Баруди, Утыз Имәни, Рәсүли, Рәмзи, Курсави, Фәхретдин, Ялчыгол кебек татар фикер ияләре – бөтендөнья ислам фәне, ислам фикере һәм фәлсәфәсе күгендәге якты йолдызлар. Барлык классик татар дин гыйлеме хәнәфи-матуриди мирасына нигезләнгән. Күренекле татар мөселман галиме Мөхәммәт Морат Рәмзи: «Татар имамнары һәрвакыт иманнары буенча сөнниләр, матуридитлар, гамәлләре буенча хәнәфитләр була, һәм алар арасында яңалык таратучылар юк», – дип язган. «Традицион ислам нәрсә ул?» – дип сораганда, мин һәрвакыт 1917 елгы революциягә кадәр Татарстан һәм Идел буе территориясендә таралган ислам юнәлеше турында сүз барганын аңлатам. Һәм менә хәзер шушы күпьеллык паузадан соң хәнәфи мәзһәбе һәм матуриди гакыйдәсе торгызыла башлады. Бу бик мөһим, чөнки нәкъ менә татар дин фәненең хәнәфи-матуриди гакыйдәсендәге мирасында без татар милләтенә хас мәгърифәт һәм толерантлылыкның, төрле милләт һәм дин халыклары белән күрше булып тату яшәвенең чишмә башын күрәбез.

Әмма болар барысы да хәзер – тарих. Кызганыч, бүген без инде бакыйлыкка күчкән милләттәшләребез белән генә горурлана алабыз. Хәер, хәзерге татар өммәтенең дә, һичшиксез, чит ил ислам дине галимнәрен җәлеп итәрлек казанышлары бар. Мәсәлән, Татарстан Диния нәзарәте әкренләп татарның Коръән басу традицияләрен торгызуга ирешеп бара. Мөселман дөньясында беренче

басма Коръәннең 1803 елда Казанда нәшер ителүе һәм «Казан басмасы» дип аталуы мәгълүм. Ул үзенә генә хас шрифтта басылган һәм әнә шул шрифт ярдәмендә бөтен дөнья буйлап таралган. Бу китап беренче тапкыр голәмаләр даирәсе тарафыннан танылган Коръән басмасы була, чөнки ул «Әр-Рәсем әл-Госмани» стандартына туры килә. Татарстан Диния нәзарәте «Казан басмасы»н безнең көннәрдә берничә тапкыр яңадан бастырды, тик ул китаплар репринт, ягъни түбән сыйфаттагы басма буларак кына дөнья күрде. Ә узган ел ахырында без танылган «Казан басмасы» типография шрифтын торгызуга ирештек – аутентик типография эзе нигезендә шул ук исемдәге компьютер шрифтын эшләдек. Хәзер чын тарихи күренешен саклап калган заманча компьютер символларын кулланып, без Коръәннең яңартылган «Казан басмасы»н әзерлибез.

Гомумән алганда, Коръәнне өйрәнү белеме – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең өстенлекле эш юнәлешләреннән берсе. Бу өлкәдә тагын бер казанышыбыз – Коръән мәгънәләрен рус һәм татар телләренә тәрҗемә итү. «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» һәм аның русчасы булган «Калям Шариф. Перевод смыслов» китаплары бүгенгәчә мөселман китап базарында бестселлер булып кала бирә.

Сүз уңаеннан, нәшрият эшен дә хәзерге татар өммәтенең казанышларына кертергә була. ТР Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йортын 2013 елда без дини әдәбиятны бастыру өчен оештырган идек, ә хәзер ул Россиядә иң зур мөселман медиахолдингларының берсенә әйләнде: биредә ислам турында китаплар гына түгел, вакытлы басмалар да нәшер ителә, «Хозур ТВ» мөселман телеканалы, «Азан» радиосы, берничә интернет-проект эшли. Иң соңгыларыннан берсе – беренче татар онлайн-мәдрәсәсе. Ул шулкадәр кирәкле булып чыкты ки, без бу порталда Россиядән генә түгел, ә Европа, АКШ, Австралия, Кытай кулланучыларын да күзәтәбез. Татарстанда ислам белем бирү системасы да Россиядә иң көчлеләрдән санала. Бүген республикада 8 мәдрәсә, мәчетләр каршында оештырылган 700 дән артык курс, 2 югары уку йорты һәм Болгар ислам академиясе эшли, читтән торып укуукыту программалары да, ачык лекцияләр дә бар. Бездә дини белемне башлангычтан алып академия дәрәҗәсенә кадәр үзләштерергә мөмкин.



Интернет-проект – беренче татар онлайн-мәдрәсәсе.

ТЫНЫЧЛЫК ҺӘМ ИСЛАМ – АЕРЫЛГЫСЫЗ ТӨШЕНЧӘЛӘР

– Конфессияләрнең үзара тыныч яшәве, толерантлык – Татарстанның дөньяны гаҗәпләндерүдән туктатмый торган үзенчәлеге. Соңгы мисалларның берсе – «Туган авылым»да үткән ифтар мәҗлесе, анда башка конфессия вәкилләре дә чакырылган иде. Тынычлык һәм ислам сүзләре ни өчен нәкъ менә Татарстанда бер-берсенә тиңдәш?

– Ислам диненең тынычлыкны, иминлекне белдергән асылын Татарстан белән генә чикләү дөрес түгел. «Ислам» сүзе «сәлам», ягъни «иминлек, тынычлык» сүзеннән килеп чыккан. Ислам – тынычлык, иминлек һәм алгарыш китерә торган дин ул. Әмма без кабат-кабат акланырга һәм исламның террор, наданлык һәм артта калу дине түгеллеген,аның чын чикләре, асылы һәм ул өндәгән нәрсәләр миһербанлык, матурлык, дөреслек һәм игелеклелектән гыйбарәт икәнлеген тәкрарларга мәҗбүрбез. Кызганыч, кайбер халыкара гаммәви мәгълүмат чараларының яла-ялганы аркасында безнең якты динебез дөнья җәмәгатьчелеге каршында пычракка манылган. Югыйсә тарихтан яхшы беләбез: Аллаһ Илчесе җитәкчелегендә мөселманнар үз дәүләтләренә – Гарәп хәлифәтенә нигез салгач, аның территорияләренә башка илләрдән куылган чит дин вәкилләре килеп урнашкан. Мөселман булмаган кешеләр хәлифәт җирләрендә яшәп, үз диннәрен бик иркен тота алган: христиан фәлсәфәчесе Иоанн Дамаскин яки яһүд теологы Маймонидны искә алу да җитә, алар үзлә-

Мәчет төзелеше.

рен иректә һәм иминлектә тойган, үз диннәрен өйрәнгән, укыткан, китаплар язган. Россиянең күпчелек өлешендә мөселманнар гасырлар буе йөз тоткан хәнәфи мәзһәбе шулай ук төрле мәдәниятләр һәм диннәр мозаикасы шартларында барлыкка килгән. Бөек имам Әбү Хәнифә төрледән төрле диннәр һәм агымнарның үзәге булган Куфа шәһәрендә яшәгән һәм эшләгән.

Татарстанда халыкларның тыныч яшәве мәсьәләсенә әйләнеп кайтып, шуны әйтә алам: төрле конфессия һәм милләт вәкилләре арасында татулык берьяклы тәртиптә төзелә алмый, ул бары тик ике як теләге белән генә булырга мөмкин. Ул чакта җәмгыятьтәге мәдәниятара татулык икътисади үсешкә дә, халыкның иминлегенә дә йогынты ясаячак. Татарстанда без нәкъ менә шундый тәҗрибәне күзәтәбез. Диния нәзарәте һәм Татарстан митрополиясе, чыннан да, тыгыз элемтәдә тора. Без игътибарны төрле диннәрдәге аермаларга түгел, ә әхлаксызлык арту, рухи кыйммәтләр югалу, яшь буынны тәрбияләү һ.б. кебек гомумкешелек проблемаларына юнәлтәбез. Болар көн саен эшләнә торган эшләр. Меморандумга кул куйдың да таралыштың белән эш бетми... Уртак хәйриячелек эшләре, рәсми җыелышларда катнашу, бергәләп спорт чаралары уздыру, туристлык сәяхәтләренә чыгу, җәмәгатьчелеккә уртак мөрәҗәгатьләр бу балансны саклап тора. Әйтик, без былтыр беренче тапкыр православие динендәгеләр белән Эльбруска динара экспедиция ясадык. Без 10 көн буе бергә тауларда йөрдек. Без намаз укыдык, алар атакай белән үзләренчә гыйбадәт кылды. Без бергәләп иртәнге ашларны ашадык, бер-беребезгә булыша-булыша, төрле авырлыкларны бергә кичтек... Болар барысы да – тату күршелек үрнәге.

ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ– ХАЛЫКНЫ ҖӘЛЕП ИТӘЧӘК ЯҢА УРЫН

– 1100 еллыкны билгеләп үтү кысаларында кулъязма Коръән языла башлады, Җәмигъ мәчетенә нигез салыначак, башка чаралар узачак. Бу вакыйгаларның әһәмиятен бәяләсәгез иде.

– Кулъязма Коръән Россиянең Коръәнне өйрәнү белеме һәм илебезнең ислам дин тәгълиматын өйрәнү юнәлеше өчен фәнни кыйммәткә ия булачак. Ул каллиграфик сәнгать әсәре һәм Россия мөселманнарының Гыйлем-әл-Хатт ислам фәнендәге (гарәп хәрефләрен язу кагыйдәләрен өйрәнә) югалган традицияләрен торгызуда беренче адымга әйләнәчәк. Бүгенгә Коръәннең 1/30 өлеше язылган инде. Эш дәвам итә.

Җәмигъ мәчетенә килгәндә исә, Казан илебездә ислам үсешенең төп рәвешен билгели, ул мөселман дөньясының төньяк башкаласы, Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр башкаласы дип танылган, мөселман дөньясында беренче басма Коръән дөнья күргән шәһәр булып тора, биредә «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме химаясендә халыкара дәрәҗәдәге чаралар уза. Моннан тыш, быел Казан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан үтәчәк төп тантаналарның кунакларын кабул итәргә әзерләнә. Асылда, Казан – Россиянең мөселман илләренә капкасы ул, ислам дөньясы өчен илебезнең йөзен билгели торган кала. Шул ук вакытта Казан мөселманнарының зур бәйрәмнәребездә яки атна саен укыла торган җомга намазларында барлык теләүчеләрне үзенә җыя алырдай заманча Җәмигъ мәчете әлегәчә юк. Югыйсә мөселманнар өчен мәчет гыйбадәт кылу урыны гына түгел, ә рухи-агарту үзәге дә булып тора, шуңа күрә Казан мәчетләрендә төрле иҗтимагый, яшьләр, балалар өчен чаралар, хәйрия, уку-укыту һәм социаль әһәмияткә ия чаралар уза. Җәмигъ мәчетендә дә җәмәгатьчелек урыннары: галим-голәма җыелышлары өчен конференц-заллар, музейлар-күргәзмәләр, белем бирү өчен һәм башка максатлардагы мәйданчыклар урын алыр дип өметләнәбез. Җәмигъ мәчете Казанның яңа символына, халыкны җәлеп итәчәк яңа бер урынына әйләнергә тиеш.

РОССИЯДӘ ИСЛАМНЫҢ РОЛЕ ТУРЫНДА

– Татарстан Президенты бервакыт, болгарларның ислам динен кабул итүе татар халкының киләчәк гасырларга язмышын һәм, нигездә, тиңсез Россия цивилизациясе формалашуны билгеләде, дип әйткән иде. Россиядә исламның роле бүген шулкадәр зурмы?

– Беренчедән, ислам – күпмилләтле Россиянең төп халыклары тота торган дин. Димәк, Россиянең ислам динендәге өлешен исәпкә алмыйча, бүген илдәге күпконфессияле җәмгыятьнең асылына төшенеп булмый, чөнки бөек Россия халкын формалаштыруда мөсел-

маннар да катнаша. Без – күпчалымлы Россиянең тагын бер йөзе!

Икенчедән, Россиядә ислам тарихына мөрәҗәгать итсәк, без мөселман дин әһелләренең халык бердәмлеген һәм дини татулыкны саклау мәсьәләсендә һәрвакыт мөһим роль уйнаганын күрәчәкбез. Искиткеч авыр сәяси шартларда руханилар кешеләрне берләштерү, рухландыру һәм аларны хак юлга өндәүдә үзләренең гайре табигый сәләтләрен күрсәткән. Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте мөфтие, 1942 елда мөселманнарны фашизмга каршы бердәм көрәшкә чакырып фәтва чыгарган Габдрахман хәзрәт Рәсүлевнең бинаһая олуг гамәле бәяләп бетергесез. Тагын бер мисал – Иван Грозный гаскәрләре Казанны алган вакытта мәчет диварлары янында үз мөридләре белән ахыргача сугышкан имам Кол Шәриф.

Өченчедән, Россия мөселманнарының традицияләре гасырлар дәвамында күпконфессияле җәмгыять шартларында барлыкка килгән һәм ныгыган. Алар башка дин вәкилләре белән иңгә-иң яшәүнең уңай, алдынгы принципларын беренче урынга куя. Татарларның гасырлар дәвамында Көнчыгыш һәм Көнбатыш, Азия һәм Европа, рус-православие һәм төрки-мөселман дөньялары арасындагы чиктә яшәве бездә үзенчәлекле фикерле һәм күренекле гыйлемле затлар барлыкка килүгә, шулай ук күпконфессияле социумда ислам үсешенең уникаль, уңышлы, сыгылмалы моделен формалаштыруга һәм толерантлык белән тәкъвалыкны берләштерергә мөмкинлек бирә торган ислам кыйммәтләрен интеллектуаль аңлауга нигезләнгән яңа буын мөселманнар тәрбияләүгә китерде. Хәзер инде менә үзегез җавап биреп карагыз: Россиядә исламнең роле зурмы?

ИМАНГА КАЙТУ

– Советлардан соңгы чорда ислам динен торгызу турында сөйләгәндә, гадәттә бу елларда төзелгән һәм ачылган мәчетләрнең санын атыйлар. Бу чыннан да иманга кайтуны раслый торган объектив күрсәткечме соң?

– Татарстанда барлык мәчетләр дә халык акчасына яки аерым мөселманнарның теләк-нияте һәм иганәчелеге нигезендә төзелә. Ягъни бу – һәрвакыт иреклe игелеклелек гамәле, кешеләрнең Аллаһ ризалыгына омтылышы, ә ниндидер югарыдан күрсәтмә түгел. Мәчет һәм мәдрәсә төзүгә дәүләт акчалары җәлеп ителми. «Кол Шәриф» мәчетен бөтен дөнья белән төзегәнне хәтергә төшерегез әле. Аның төзелешенә һәркем үз өлешен кертергә ашыкты. Республикада һәр мәчет очрагында әнә шулай: кешеләр кулдан килгәнчә ярдәм итәргә ашыга. Ә бу татарларның дингә кайтуын белдермиме?

МӘҢГЕЛЕК МИССИЯ

– Сезнең фикерегезчә, бүгенге шартларда исламның төп миссиясе нинди? Дин халыкның үзенчәлеген, телен ни дәрәҗәдә саклап калырга сәләтле?

– Татар халкының бөтен асылы ислам белән сугарылган. Ислам татар милләтен зурлады, ул безнең дәүләтчелекнең, мәдәният һәм гореф-гадәтләрнең башында торды, милли тел формалашуга зур йогынты ясады. Габдулла Тукайдан башлап, Салих Сәйдәшев белән Бакый Урманчега кадәр татар халкының иң бөек уллары мәдрәсәдә белем алган! Аларның хезмәтләре дөньяга танылды, чөнки бу хезмәтләрнең тиңе юк иде. Бүген заманча дөньяви татар мәдәнияте никадәр тиңсез соң? Без еш кына аның үз йөзе булмавы турында ишетәбез. Ә татар-мөселман мәдәнияте – кабатланмас. Аңа 1100 яшь.

Һәм XX гасыр башында татарлар, алга киткән мөселман халык буларак, үзләренең мәдәни ренессансына ирешә. Ул вакытта татар милләте үсешенә мәгърифәтче дин белгечләре зур өлеш кертә. Беренче татар сәяси партиясе «Иттифакъ әл-Мөслимин» («Мөселманнар берлеге») дип атала. Һәм без Дәүләт Думасында мөселман фракциясе булганлыгын, Бөтенроссия мөселман съездлары үткәрелгәнлеген, аларның эшчәнлеге татарларның милли-мәдәни мохтәриятен булдыруга юнәлдерелгәнлеген беләбез. Ягъни XX гасыр башында татар-мөселман иҗтимагый хәрәкәте бик көчле булган һәм ТАССР оештырылуны большевиклар тырышлыгы гына дип карау дөрес түгел. Димәк, милләтнең үзенчәлеген саклап калуда һәм татар халкын үстерүдә исламның төп роль уйнаганлыгын тарих безгә үзе искәртә. Әлхәмдүлиллаһ, бүген татарларның үз диннәрен тотуына бернинди киртә-каршылык та юк.

МИНЕМ ӨЧЕН

Фәрит Мөхәммәтшин,
ТР Дәүләт Советы Рәисе:

– Минем бабаларымның дине, ата-ананың халык традицияләренә мөнәсәбәте. **Ул тынычлык һәм татар этногенезы нигезләренең берсе булган мәгърифәт дине. Ислам халыкның мәдәни традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен, милли характерын һәм менталитетын формалаштыруга зур этәргеч биргән**. Ислам татарларның Россия дәүләте составындагы үзтәңгәллеген саклап калырга ярдәм иткән, халыкның мәдәни һәм тел үзенчәлекләрен, традицион рухи һәм әхлак кыйммәтләрен ачарга һәм көчле мәгърифәт һәм ислахчылык идеяләрен гамәлгә ашырырга булышкан.

Радик Салихов,
ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры:

– Иң беренче нәүбәттә, минем яшәү рәвешем, фикер сөрешем, әхлакый принципларымның нигезе. **Ул минем көндәлек гамәлләремне һәм кешеләргә мөнәсәбәтемне билгели торган рухи кыйммәтләр.** Якыннарым һәм ерак бабаларым, туган нигезем, халкым тарихы турындагы изге хәтер.

Илдар Ягъфәров,
режиссер:

– **Ул гаиләм, нәселем традицияләре, ерак бабаларым авазы**. Ул минем туганнарым белән мөнәсәбәтләремне чагылдыра, гаилә бәйрәмнәрен үткәрүгә, авыр заманнарда бергә җыелуыбызга сәбәп булып торган кыйммәтләр. Ислам безне берләштерә. Ул минем эчке рухи традицион кыйммәтләремнең гәүдәләнеше дә.

Фото: Александр Ефремов, duma.gov.ru, Рамиль Гали, kpfu.ru, tatar-inform.ru, ru.wikipedia.org

ИСЛАМ – УЛ

ТАНЫЛГАН СӘЯСӘТЧЕЛӘР, ГАЛИМНӘР, МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ ҖАВАП БИРӘ

Марат Нуриев,
Россия һәм Татарстанның атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре, РФ Дәүләт Думасы депутаты:

– Ислам минем өчен – чисталык, пакълек, мәрхәмәтлелек, бер Аллаһы Тәгаләгә генә табыну. Туры юлдан тайпылмыйча ислам дине кануннарына буйсынып гомер итү. **Ислам дине туганлыкны, дуслыкны кадерләргә өйрәтүче, туган җиреңне яратырга өндәүче дә**. Әле менә күптән түгел генә «Апас» Якташлар җәмгыятендә бик зурлап ифтар үткәрдек. Гади укытучыдан башлап, район башлыгы, министрга кадәр бер өстәл артында утырып, ихластан дога кылдык. Аллаһы Тәгалә каршында барыбыз да тигез. Менә бу да исламның асыл нигезе...

Рәшит Байбиков,
Россия һәм Татарстанның атказанган табибы, балалар хирургы:

– Халкыбызның олы язмышы горурланырлык. Монда ислам диненең дә роле зур. Ислам ул дөрес юлга этәрүче зур көч! Ислам диненең бер кагыйдәсе – сөннәт. Балалар табибы буларак шуны да әйтәсем килә: соңгы елларда татар халкы улларын, оныкларын сөннәткә утыртуга зур әһәмият бирә, һәм бу безне бик сөендерә. **Чөнки сөннәт – сафлык, баланың саулыгы, аның киләчәге һәм булачак балаларының да исәнлеге. Сау бала – сау ир – сау ил!** Туган халкымны якынлашып килүче олуг вакыйга, зур бәйрәм белән чын күңелемнән тәбрик итәм!

Венера Ганиева,
Россия һәм Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:

– **Ислам дине минем өчен әтиемнән калган иң зур мирас: ул минем газиз җирем, телем, динем, кыйблам**. Быел Болгар җирендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тула. Шул дәвер эчендә күпме хакимият, сәясәт үзгәргән, ә менә ислам дине бер канун – изге Коръән нигезендә алып барыла. Зур сөенеч: бүген мөселман кардәшләребез мәдрәсәләрдә дин дәресләрен өйрәнә, мәчетләргә йөри, Аллаһы кушканнарны үти. Көн туды исә, кемгә булса да игелек кылырга, җирдә якты эз калдырырга тырышам, шул исәптән кулдан килгәнчә мохтаҗларга да булышам. Болар барысы да ислам дине кушканча яшәү. Бу минем тормыш кыйблам...

ИСЛАМ МӘГАРИФЕ: БЕЛЕМГӘ ОМТЫЛУ – ИЗГЕ БУРЫЧ

Гамир Дәүләтшин

Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы... Болар барысы да – мөселман дәүләтләре. Ислам доктринасында белемгә, гыйлемгә бик мөһим урын бирелә. Белемгә омтылу һәр мөселманның изге бурычы санала.

Ислам мәгарифе системасы бөтен мөселман дөньясын колачлый. Белем алуга шундый ихтирамлы мөнәсәбәт нигезендә ислам дине тора. Исәпләп чыгарганнар: Коръәндә «гыйлем» сүзе һәм аның төрле формалары 750 тапкыр очрый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) дә бу сүзне шактый еш кулланган.

ИДЕЛ БОЛГАРСТАНЫНДА НИЧЕК ҺӘМ НӘРСӘГӘ ӨЙРӘТКӘННӘР

Идел буе Болгарстанында укымышлылык һәм гыйлемнең таралуы болгар җәмгыятендә ислам диненең таралуы белән берүк вакытта барган. Коръәннең үзе кебек үк изге саналган гарәп хәрефләрен дога урынына ятлаганнар.

Фото: znanio.ru

X гасыр башында ук фарсы сәяхәтчесе Ибнә Рустә болгарларның «күпчелеге ислам динен тота, мәчетләр һәм мәдрәсәләр, мәзиннәр һәм имамнар бар», дип язып калдырган. Мәдрәсәдә гарәп графикасын өйрәнгәннәр.

Мөселман илләрендә IX гасырдан күпләп ачылган мәдрәсәләр югары һәм урта дини уку йортлары булган. Алар гадәттә башкалада һәм зур шәһәрләрдә урнашкан. Шәрыкның фән һәм мәдәният үзәкләре – Бохара, Сәмәркәнд, Нишапур, Балх, Мәрв, Газни, Багдадта белем эстәү Идел буе Болгарстанында мөселман мәгарифенең иң югары дәрәҗәсе саналган.

Соңрак Идел буе Болгарстанының бөтен Шәрыкка мәгълүм мәдрәсәле башкаласы үзе дә танылган фән үзәкләреннән берсенә әйләнә. Ул замандагы көнчыгыш илләре галимнәре арасында Идел буе Болгарстанында белем алучыларның күп булуы бер дә очраклы түгел.

Төп игътибар дин гыйлемен өйрәтүгә юнәлтелә, укыту Коръәнне тәфсирләү (тәдрис) һәм өлешчә әйтеп яздыру (имла) методы белән башкарыла. Моннан тыш, билгеле бер дәрәҗәдә дөньяви белем дә бирелә: математика, география, тарих, астрономия, медицина нигезләре укытыла. Болгар мәдрәсәләрендә белем алган болгар һәм көнчыгыш галим-медиклары, астрономнары, шагыйрьләре хакында безнең көннәргә кадәр килеп җиткән мәгълүмат та моңа дәлил булып тора.

Коръән, фән, шигърият теле булган гарәп телен, XI гасырдан Урта яки Якын Көнчыгышта төп әдәбият һәм шигърият теленә әйләнгән фарсы телен өйрәтүгә дә зур игътибар бирелә. Шәрык телләрен белү көнчыгыш илләре белән тыгыз сәүдә элемтәләре урнаштырган болгар сәүдәгәрләренә дә бик кирәк була. «Җиде йортның телен бел, җиде төрле белем бел» мәкале шул заманнардан бирле актуаль санала.

… АЛТЫН УРДАДА

Башкалада һәм башка зур шәһәрләрдә, гадәти башлангыч мәктәп һәм мәдрәсәләрдән тыш, махсуслашкан зур мәдрәсәләр төзелә. Алар гадәттә хан яки башка югары дәрәҗәле шәхесләр химаясендә эшли. Мәсәлән, Үзбәк хан Сарайда галимнәр өчен мәдрәсә төзетә. Табигый ки, бу мәдрәсәләр иң дәрәҗәле фән һәм мәгариф учагы була. Аларны хәтта ул заманның университетлары яки фәннәр академиясе дип тә әйтергә мөмкин. Бер үк галим илнең берничә шәһәрендә белем эсти алган.

Моңа мисаллар күп. Мәсәлән, Хәрәзмнең Кардар шәһәрендә туган Ибне Баззас (1343–1423), үз илендә башлангыч белем алгач, аннары Сарай, Болгар, Кырым, Хаҗитархан кебек калаларда укыган. Әш-шәйхел-имам Хуҗа Гомәр әл-Болгари Болгар, Тәбриз, Бохара, Ганҗә шәһәрләрендә укыган һәм укыткан. Әш-шәех Ногманетдин әл-Хәрәзми Сарай, Үргәнч һ.б. шәһәрләр мәдрәсәләрендә укыган, аннары Сүрия һәм Мисырда мөгаллим булган.

Чит ил мәдрәсәләрендә уку яки укыту Җучи Олысы зыялыларына бернинди кыенлык та тудырмаган, димәк, ул чактагы мәгариф системасы һәм укытыла торган фәннәр ислам дөньясының барлык илләрендә дә охшаш булган.

… КАЗАН ХАНЛЫГЫНДА

Казан ханлыгы халкының мәдәният дәрәҗәсе һәм укымышлылыгы турында чит ил вәкилләре язмаларыннан укып була. Шул дәвердә Казанда булып киткән Австрия илчесе, сәяхәтче Сигизмунд Герберштейн үзенең юлъязмасында: «Бу татарлар башкалардан белемлерәк, алар иген үстерә, үзләре салган йортларда яши һәм һәртөрле сәүдә белән шөгыльләнә», – дип язган.

Алтын Урдадан соң барлыкка килгән башка дәүләтләрдәге кебек үк, Казан ханлыгында да хан һәм бәк балаларын аксакаллар тәрбияләгән. Аларны «сөт атасы» дип хөрмәтләгәннәр.

Әлеге чорда бөтен ислам дөньясында «мөгаллим-шәкерт» институты киң таралган. Үз заманының югары белеменә тиң гыйлем алу укытучы-остазыңның кем булуыннан торган. Кайчагында лаеклы остаз эзләп күп йөрергә туры килгән. Мөгаллимнең исемен, аның титулларын гадәттә тирән ихтирам һәм горурлык белән хәбәр иткәннәр. Остазлар да үзләренең сәләтле шәкертләре белән горурланган.

Бигрәк тә Үзбәкстандагы Бохара популяр булган. Татарлар өчен ул XX гасырга кадәр төпле дини белем үзәге булып калган. Шул заманнардан бирле татарларда «Абына-абына Бохарага җитәрсең, яңлыша-яңлыша галим булырсың» дигән мәкаль дә яши.

Укымышлылыкка, белемгә хөрмәтне болгарлар үзләренең варисларына да тапшырган. Карл Фукс (1776–1846): «Биредә хәтта кайбер Европа илләрендәгедән дә укымышлырак халык яши. Укый-яза белмәгән татарны якташлары бер дә өнәми, граждан буларак хөрмәт итми», – дип язып калдырган.

ҖӘДИДЧЕЛЕК. ЯҢАРЫШ ЮЛЫ

Рәфыйк Мөхәммәтшин, Россия ислам институты ректоры

XIX гасыр азагында Россия империясе мөселманнары арасында ислам мәдәнияте һәм җәмгыятенең яңаруын дәгъвалаган иҗтимагый-сәяси һәм интеллектуаль хәрәкәт – җәдидчелек барлыкка килә һәм үсеш ала.

Тикшеренүчеләрнең күпчелеге раславынча, җәдидчелек идеяләре Исмәгыйль бәй Гаспринский эшчәнлеге һәм хезмәтләрендә аеруча тулы чагыла һәм ул башлаган мәгариф системасы реформасына бәйле. Чыннан да, илнең мөселман җәмәгатьчелегендәге идея-интеллектуаль трансформациянең нигезендә нәкъ менә мәгариф ята. Бу рухи яңарыш һәм җәмгыятьнең интеллектуаль потенциалын торызуның бердәнбер мөмкин формасы була.

РЕФОРМАЛАР ҮЗӘГЕ – МӘДРӘСӘ

1905-1907 еллар революциясенә кадәр мөселманнарның мәгариф системасыннан башка бернинди структуралары да гамәлдә булмый. Шунлыктан реформаның төп максаты яңа мәгариф технологияләрен кертү генә түгел, бәлки мөселманнарның җәмгыятьне яңартуга актив катнашырга сәләтле яңа буынын тәрбияләү дә була. Россия иҗтимагый-сәяси тормышын модернизацияләүгә кызыккан татар милли буржуазиясенең мөселман мәхәлләләрендәге попечительләр системасы, хәйрия оешмалары һәм фондлары аша ысуле җәдид – яңа метод яки саутия (аваз) ысулы белән белем бирә торган уку йортларын финансларга алынуы бер дә очраклы түгел.

Җәдидчелек идеяләрен гамәлгә кертү нәкъ менә яңа ысул белән укыта торган мәдрәсәләр булдырудан башлана. Мондый тәүге уку йортын Исмәгыйль Гаспринский 1884 елда Бакчасарайда оештыра. Укытуның яңа методикасын үз эченә алган җәдидчелек, традицион рәвештә мәдрәсә дип аталса да, төп игътибар дөньяви фәннәрне укытуга бирелә торган уку йортлары пәйда булуга китерә.

АЛГАРЫШ ЭТӘРГЕЧЕ БУЛАРАК ХОСУСЫЙ ИНИЦИАТИВА

Аңлашыла ки, Россия империясендә милли дөньяви мәктәпләр тыелу шартларында җәдидчелек мәдрәсәләре үзләренең статусы буенча бары тик конфессиональ гына була ала. Димәк, аларда дин тәгълиматына да зур урын бирелә. Һәр мәдрәсәдә диярлек Коръән, хәдисләр, ислам тарихы, иман нигезләре, ислам хокукы һәм башкалар төп фәннәр сыйфатында укытыла. Җәдид мәдрәсәләре аваз ысулы белән укыту, мәктәп җиһазларыннан файдалану, сыйныф-дәрес системасы кертелү һ.б. белән аерылып тора.

Мәгариф системасы кысаларында җәдидчеләр табигый һәм гуманитар фәннәр өйрәнү һәм үзләштерүнең киң спектрын тәкъдим итә, аларны «интеллектуаль фәннәр» төшенчәсенә берләштерә. Тарихны өйрәнүгә зур әһәмият бирелә.

Җәдидчелек мәктәп-мәдрәсәләре ачу тулысынча мөселманнарның хосусый инициативасы була һәм дәүләттән бер ярдәм дә алмый. Казандагы «Мөхәммәдия» һәм «Апанай», Уфадагы «Госмания», Оренбургтагы «Хөсәения», Вятка губернасы Сарапул өязендә «Буби», Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәләре Үзәк Россиядә төп җәдидчелек учакларына әйләнә.

КОРЪӘННӘН АЛЫП ФРАНЦУЗ РЕВОЛЮЦИЯЛӘРЕ ТАРИХЫНА КАДӘР

Җәдид мәдрәсәләренең мөгаллимнәр корпусы, Россиядәге мөселман уку йортларын тәмамлаучылардан тыш, чит илләрдә белем эстәгән олпат шәхесләрдән дә гыйбарәт булган. «Галия» мәдрәсәсен оештыручы З.Камали, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме К.Сәйфетдинов, «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме С.Галимов, танылган җәмәгать һәм дин әһелләре З.Кадыйри, Г.Баттал, М.Бигиев, И.Камалов һ.б. Каһирәдәге әл-Әзһәр университетында белем алган. Сорбонна тәмамлаган Йосыф Акчура «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә гомуми тарих, география һәм француз революцияләре тарихы курсларын укыган.

1905-1907 еллар революциясеннән соң гаммәви мәгълүмат чаралары җәдид-

Фото: islamnews.ru

челек идеяләре таралуның төп мөнбәренә әйләнә. Җәдидчелек юнәлешендәге көндәлек матбугатка бик күп газета-журналларны кертеп була, аларны, иң әүвәл, ысуле җәдид мәдрәсәләрен тәмамлаучылар чыгара, бу исә милли матбугатның әлеге басмаларын җәдидчелек реформаларының мантыйкый дәвамына әйләндерә.

МОДЕРНИЗАЦИЯ: СӘЯСИ АСПЕКТ

XX гасырның беренче унъеллыгында җәдидчелек, әкренләп мәгърифәтчелек юнәлеше кысаларыннан чыгып, интеллектуаль элита эчендә катламнарга аерылуны көчәйтеп, сәяси яссылыкка күчә башлый. Төрки-мөселман җәдидчелек интеллигенциясе эчендә мөселман җәмгыятен модернизацияләүнең төрле вариантларын күздә тоткан өч агым була.

Консерватив канат (И.Гаспринский, Г.Ибраһимов) мөселман халыкларын берләштерү, аларның мәдәният дәрәҗәсен күтәрү, мөселманнарның дини эшләре белән идарә итүне либеральләштерү һәм мәктәп реформасы хакында кайгырта. Аларның сәяси гамәлләре мөрәҗәгатьләр, югары хакимияткә петицияләр язу, дини-мәдәни мәсьәләләрне тикшерәчәк мөселман съездларын җыюга кайтып кала.

Мөселман либерализмын күбесенчә Европа белемле төркителле интеллигенция (И.Әхтәмов, С.Җантурин, С.Мәкъсүтов, Ш.Сыртланов, К.Тәфкилев һ.б.) алга сөрә, аларның сәяси максаты Россия мөселманнары өчен мәдәни-милли автономия төзү була. Әлеге юнәлеш вәкилләре «Иттифак әл-Мөслимин» партиясенең, Дәүләт Думасындагы мөселман фракциясенең төп оештыручылары санала.

Сәяси карашлары Беренче бөтендөнья сугышы, 1917 елгы революция һәм Гражданнар сугышы елларында формалашкан милли-демократик интеллигенция җәдидчелекнең сул канатына карый (И.Алкин, Ә.Вәлидов, Г.Ибраһимов һ.б.). Алар Россияне федерализацияләү идеясе белән чыга.

КОНСОЛИДАЦИЯГӘ ОМТЫЛЫШ

Төрле фикер каршылыклары булуга карамастан, Россия мөселманнарының прогрессив канаты идея-сәяси берләшү омтылышларын ясап карый. 1905 елның августында Россия мөселманнарының I съезды була. Исмәгыйль бәй Гаспринский рәислек итә, аның Россиядәге барлык төрки мөселманнарны үз мәнфәгатьләрен уңышлы яклау өчен бер оешмага берләштерү идеясе корылтайда тулы хуплау таба. «Иттифак әл-Мөслимин» фиркасен төзү турында карар кабул ителә.

Партия программасы иң әүвәл Россия мөселманнарын бердәм хәрәкәт кысаларында берләштерүне күздә тота. Дәүләт төзелеше мәсьәләләрендә фирка берпалаталы халык вәкиллеге системасы булган конституцион парламент монархиясен яклый, шулай ук хатын-кызларга сайлау хокукы бирүне дәгъвалый. Шулай ук Дәүләт Думасына сайлауларда катнашу хакында карар кабул ителә. Мөселманнардан барлыгы 36 вәкил сайлана, II Думада 34 депутат, ә III Думада инде 10 мөселман депутаты гына исәпләнә. Думадагы эшчәнлек хөкүмәтнең милли һәм дини сәясәтенә мөнәсәбәтне ачык белдерү, мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә мөселманнар мәнфәгатен яклау мөмкинлеген бирә.

ҮЗБИЛГЕЛӘНҮ ФОРМУЛАСЫН ЭЗЛӘП

Россия җәдидчеләренең сәяси иң актив чагы 1917 елга туры килә, бу вакытта мөселман руханиларының, укытучыларның, хәрбиләрнең съездлары үткәрелә. 1917 елның маенда Мәскәүдә Россиянең барлык төбәкләреннән 770 делегатны туплаган Бөтенроссия гомуммөселман съезды мөһим вакыйгага әйләнә. Россия мөселманнарының барлык күренекле сәяси лидерлары диярлек әлеге корылтай эшендә катнаша: Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Гаяз Исхакый, Шакир Мөхәммәдьяров, Гомәр Терегулов, Галимәрдан Тобчибашев, Гобәйдулла Хуҗа, Әхмәд Цаликов.

Мөселман халыкларының үзбилгеләнү формуласын эзләү корылтайның төп бурычына әйләнә. Кайбер делегатлар территориаль форма яклы була – милләтнең үзидарәсе билгеле бер территориядә тупланырга тиеш, дип саный. Икенчеләре милли-мәдәни автономия дәгъвалый, аларга бу Россия мөселманнары бердәм өммәтенең аерым милләтләргә таркалышына каршы торуның нәтиҗәле формасы булып тоела. Нәтиҗәдә съезд компромисслы карар кабул итә һәм «мөселман халыклары мәнфәгатенә аеруча җавап бирә торган дәүләт төзелеше формасы ул – территориаль автономияләргә нигезләнгән халык федератив республикасы; үз территориясе булмаган халыклар өчен исә – милли-мәдәни автономия», дип таный.

Җәдидчелек вәкиләре мөселман халыкларының дәүләтчелеген торгызу буенча сәяси акцияләрдә дә бик актив катнаша. Әйтик, 1917 елның 22 июлендә Казанда Гомуммөселман съезды була, ул «Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының милли-мәдәни мохтарияттен» игълан итә. Автономиянең Милләт җыенына сайлау үткәрелә, Садри Максуди аның рәисе була. Идел-Урал штатын игълан итү 1918 елның 1 мартына билгеләнә. 1917 елның декабрендә штат конституциясе проекты тикшерелә, параллель рәвештә аның территориаль чикләрен килештерү буенча эш бара. Әмма совет хакимияте органнары яңа властьны һәм социалистик идеологияне танудан баш тарткан милли дәүләт берәмлеге төзүне рөхсәт итми. 1918 елның апрелендә әлеге оешма эшчәнлеге тыела.



ТАРИХИ ШӘХЕСЛӘР

Барлык бу кешеләр төрле заманнарда яшәгән, әмма һәрберсенең исеме ислам тарихына кереп калган. Кемдер аларны фетнәче, иленнән сөрелгән дип атаган, кемдер гомерен үз халкын агартуга, гыйлем нуры таратуга багышлаган мәгърифәтче, рухи лидер дип олылаган. Шуңа күрә әлеге олуг шәхесләрнең исеме 100 елдан соң да, 1000 елдан соң да, 1100 елдан соң да онытыла алмый...

КОЛ ШӘРИФ.
КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ СОҢГЫ ИМАМЫ

ГАБДЕННАСЫЙР КУРСАВИ.
ТАТАР ДИНИ РЕФОРМАЛАРЫ КАРЛЫГАЧЫ

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ.
ТАТАР ТАРИХЫ АТАСЫ

ГАБДУЛЛА БУБЫЙ.
МӘГЪРИФӘТ ИСЛАХЧЫСЫ

ГАЛИМҖАН БАРУДИ.
ТАТАРНЫ ДӨНЬЯГА ТАНЫТУЧЫ

РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН.
БОЛГАНЧЫК ДӘВЕР МӨФТИЕ

МУСА БИГИЕВ.
ЯҢАРЫШ ТЕОРИЯСЕ ХАТЫЙБЫ

ТАРИХИ ШӘХЕСЛӘР

КОЛ ШӘРИФ.
КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ СОҢГЫ ИМАМЫ

Фаяз Хуҗин

Казан ханлыгының рухи лидеры, күренекле дин эшлеклесе, дипломат, шагыйрь – болар барысы да Кол Шәриф турында. Бөтен гомерен үз халкына хезмәткә багышлаган шәхес. Ватанының бәйсезлеген яклап, шәкертләре белән бергә һәлак була, әмма җиңелми.

Казан ханлыгының соңгы яклаучысы Кол Шәриф исемен татарлар буыннан буынга тапшырып килә. Кол Шәрифнең шәкертләре белән соңгы тамчы кангача көрәшкән соңгы бәрелеше турында риваятьләр яши. Ә аның үзе турында без нәрсә беләбез соң? Кызганычка каршы, бик аз: әлеге үзенчәлекле шәхес турында архивларда сакланып калган бик аз мәгълүмат аның тормыш юлын, иҗтимагый эшчәнлеген һәм иҗатын бары тик өстән-өстән генә күзалларга мөмкинлек бирә.

СӘЕТЛӘР НӘСЕЛЕННӘН БУЛГАН СӘЕТ

Кол Шәрифнең төгәл туган көне һәм урыны билгеле түгел. Галимнәр раславынча, аның чын исеме – Мөхәммәт Шәриф. «Кол» сүзе Аллаһ колы мәгънәсендә аның XII гасырда танылган шагыйрь, фәлсәфә һәм дин белгече Әхмәт Ясәви нигез салган суфыйчылыкка катнашы булуына ишарәли. Кол Шәриф Кырымда яисә Хаҗитарханда (Әстерханда) туган дип фаразлыйлар. Аның «Хаҗитархан» дигән тәхәллүсне йөртүе дә, мөгаен, очраклы гына булмагандыр: Кол Шәриф күпмедер вакыт Әхстерханда яши. Әтисе Мансур (икенче бер версия буенча – Хөсәен) сәетләр нәселеннән була. Нәсел шәҗәрәсе Мөхәммәд пәйгамбәрдән башланган дин әһелләрен сәет дип йөрткәннәр. Алар дәүләт идарәсендә мөһим урыннар били. Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән ханлыкларда берничә сәет булганлыгы билгеле. Шулар арасыннан берсен – иң укымышлы, абруйлы һәм хөрмәткә лаеклысын олуг сәет итеп сайлыйлар. Безнең көннәргә кадәр сакланып калган шәҗәрәләрнең берсендә Кол Шәрифнең әтисе Мансур Хаҗитархан сәете дип язылган. Казан ханлыгы чорында тутырылган архив документларында Кол Шәриф үзе 1545 елдан башлап сәет буларак күрсәтелә. Ә 1551 елның октябреннән ул олуг сәет вазыйфасын башкара. Бу ханлыкта ранг буенча ханның үзеннән кала икенче урындагы дәүләт эшлеклесе дигәнне аңлата.

СУГЫШ АЛДЫННАН УРНАШКАН ШОМЛЫ ТЫНЛЫК

Документлар да Кол Шәрифнең халык арасындагы һәм идарәче катламдагы абруе турында сөйли: ул, ак атына атланып, Казан урамнары буйлап йөрергә ярата. Гади шәһәр халкы аны баш иеп каршылый. Хәтта Сафагәрәй хан үзе дә сәет белән очрашканда, атыннан төшеп, аның чапан итәген үбә, хәл-әхвәл сораша һәм киткәндә саулык теләп саубуллаша. Рус кенәзләре исә илчеләре аша шәхсән аңа аталган хат һәм бүләкләр юллый.

Сакланып калган мәгълүматларга караганда, Кол Шәриф стратегик дәүләт мәсьәләләрен хәл иткәндә мөһим роль уйный. Өстәвенә, аңа Казан каласы һәм дәүләтнең киләчәк язмышы хәл ителә торган гаять катлаулы шартларда эшләргә туры килә. Күз алдына китерегез: рус гаскәрләре башкала капкасы янында ук тора, Зөя тамагында көтмәгәндә-уйламаганда ныклы кирмән – рус патшасы Явыз Иван гаскәрләре тупланган урын пәйда була. Шул ук вакытта Тау ягы халкы рус патшасына тугрылык турында ант бирә, аларның ханлык составындагы җирләре Мәскәү дәүләтенә күчә. Ә башкалада Сөембикә хөкүмәте таркалу алдында кала...

Килеп туган вазгыятьтә, 1551 елның июнендә, хөкүмәт Зөядә руслар һәм Казанның

Фото: ru.wikipedia.org

элекке ханы Шаһгали белән сөйләшүләр башларга ниятли. Илчелекнең җитәкчеләре итеп сәет Кол Шәрифне һәм бәк Бибарс Растовны билгелиләр. Казанлыларга ничек кенә аяныч булмасын, алар хан тәхетенә янә явыз Шаһгалине кайтару, ә ханзадә Үтәмеш белән Сөембикә-ханбикәне Мәскәүгә тоткын итеп җибәрү турындагы килешүне имзаларга мәҗбүр була.

БИРЕЛҮ ТУРЫНДАГЫ ТӘКЪДИМ КИРЕ КАГЫЛА

Шаһгали Казанда озак тоткарланмый: Явыз Иван аны хан дәрәҗәсеннән мәхрүм итә һәм «вакантлы» урынга үзенең наместнигы кенәз Микулинскийны җибәрә. Тик аны Казанга кертмиләр. Казанлылар Чапкын Отучев җитәкчелегендә үз хөкүмәтен төзи. Аның составына Кол Шәриф сәет тә керә.

Мәскәүдә Казанга һөҗүм итәргә әзерлек башлана. 1552 елның августына Явыз Иванның 150 мең кешелек гаскәре Зөягә килеп җитә. Рус патшасы шәхсән Кол Шәрифкә сугышсыз гына бирелү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итә. Тәкъдим кире кагыла.

4 сентябрь. Казанда беренче шартлау яңгырый – Нурали капкасы җимерелә, басып алучылар әлеге капка аша кирмәнгә үтәргә омтыла. Шәһәр оборонасы бер айга кадәр диярлек сузыла. Шәһәрне саклаучыларга ультиматум куела: каршылык күрсәтмичә генә бирелергә. Казанлылар: «Без буйсынмыйбыз, диварларда һәм манараларда руслар. Ләкин без башка диварларны торгызабыз, барыбыз да үләбез яисә качып утырып торабыз», – дип җавап бирә.

«КОТОЧКЫЧ КАН КОЕШТА БАРЫСЫ ДА БАШЫН САЛДЫ»

Шәһәргә соңгы һөҗүм 2 октябрьдә (иске стиль буенча) оештырыла. Кирмән эчендә, Кол Шәриф мәдрәсәсе һәм мәчете янында каты бәрелешләр бара. Шул вакыйгаларны күргән берәү болай дип язып калдыра: «шәкертләр, муллалар һәм абызлар, бөек епископлары (алар телендә Кол Шәриф-мулла атлы әмирләре) белән бергә, нәрсә бар шуның белән коралланып, һөҗүм итүчеләргә каршылык күрсәтте һәм коточкыч кан коешта барысы да башын салды».

Казан бирелергә мәҗбүр була, әмма Кол Шәриф, аның шәкертләренең батырлыгы-кыюлыгы бүген дә безнең йөрәкләрдә соклану хисләре уята.

Татар халкы күңелендә Кол Шәриф үзенең әдәби иҗаты белән дә ныклы урын алды. Аның берничә шигыре, «Кыйссаи Хобби Хуҗа» поэмасы һәм «Зафернам-и вилайет Казан» («Казан вилаятенең/иленең җиңүе») проза әсәре бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Заманалар зилзиләсендә Кол Шәрифнең күпме әсәре югалганын фаразларга гына кала.

Вакыт рәхимсез. Әмма ул да хәтер каршында көчсез. Казан Кремленә ямь биреп, яңадан калкып чыккан Кол Шәриф мәчете – исеме татар тарихы битләренә мәңгелеккә кереп калган каһарманга варисларыннан бүләк.

«Хан сарае янында соңгы сугыш». Россия сәнгать академиясе әгъзасы Фиринат Халиков картинасы. Уртада – кулына Коръән тотканы – Казан өчен сугышта һәлак булган Кол Шәриф сәет.

ГАБДЕННАСЫЙР КУРСАВИ.
ТАТАР ДИНИ РЕФОРМАЛАРЫ КАРЛЫГАЧЫ

Айдар Хәбетдинов

Һәр яңарыш хәрәкәтен үткән дәвердәге иң яхшы идеяләрне яңа заман таләпләре белән яраштырырга сәләтле шәхес кузгатып җибәрә. Аның карашларын замандашлары һәрвакытта да кабул итеп бетермәскә мөмкин, әмма киләчәкне кайгырткан бу идеяләрне сакларга һәм үстерергә әзер шәкертләре кала. Татарларда дини ислахчылыкка нигез салган Габденнасыйр Курсави эшен дә дәвам иттерүчеләр табыла.

Курсави дәверендә (XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы) икътисадый яктан көчле татар буржуазиясе динне ныгыту өчен акчасын кызганмый. Курсави ярдәмне тоеп эшли. Әтисенең вафатыннан соң 15 яшьлек үсмер апасы Мәрхабә – Мәчкәрә авылы иганәчесе һәм беренче гильдия сәүдәгәр, үз акчасына дистәләгән мәчет төзеткән Габдулла Үтәмешевнең хатыны тәрбиясендә кала. Башлангыч белемне мәдрәсәдә алганнан соң, Габденнасыйр Курсави укуын Бохарада дәвам итә.

БЕЛЕМ ЭСТӘРГӘ БОХАРАГА

Бохараны сайлауның ике сәбәбе мәгълүм. Беренчедән, Төркестан, бигрәк тә Бохара, ул вакытларда татарлар өчен төп сәүдә табышы китерә торган төбәк санала, шуңа күрә ханлык руханиларының йогынтысы көчле була. Мәдрәсә гарәп һәм фарсы телләрен, мөселман хокукы - шәригатьне һәм җирле теология традицияләрен белүче рухи һәм дөньяви элитаны әзерләүне максат итеп куя. Монда укып чыгу мәдрәсә ректоры – мөдәррис статусын алырга мөмкинлек бирә. Урта Азиядә Коръән һәм сөннәт кебек беренчел чыганакларга караганда, аларны кабул ителгән традицияләр кысаларында аңлатуга игътибар күбрәк бирелә: мәдрәсә, белемле элитаны әзерләү белән беррәттән, ислам кануннарына билгеле бер аңлатма да бирә.

Икенчедән, ул заманда татарларда Урта Азиядәге белән чагыштырырлык югары типтагы бер генә мәдрәсә дә булмый.

Өстәвенә, Урта Азиядә суфичылык тарикатьләре – гасырлар дәвамында интеллектуаль элитаның казанышларын, аң-белемен тапшыручы орденнар сакланып калган. Хәтта дәүләткә һәм руханиларга катгый буйсыну шартларында да суфилар рухи яктан иреклe, бәйсез була. Курсави югары рухи абруйлы хәлифә буларак хәтта армиягә дә шактый зур йогынтыга ия Нәкышбәндийә тарикате шәехе Ниязкули әт-Төрекмәнидә укый башлый.

ТЫНЫЧЛЫКНЫ БОЗУЧЫ

Туган ягына әйләнеп кайткач, Габденнасыйр хәзрәт Габдулла Үтәмешев ярдәме белән Югары Курса (бүген Татарстанның Арча районы) авылында мәдрәсә оештыра, аның беренче шәкертләре пәйда була. Әмма галимгә үз карашлары буенча фикер алышу өчен фәнни мохит җитми, һәм ул яңадан Бохарага юл ала. Курсави руханиларны мөселман хокукының төп чыганаклары булган Коръән һәм сөннәткә таянырга чакыра. Әмма ул дөньяның үзгәрүен дә аңлый. Әгәр хокукый карарларны узганнарда табып булмый икән, аларны иҗтиһад итеп, ягъни мөстәкыйль эзләнеп кабул итәргә кирәк диган фикергә килә.

Бохара әмирләре инде күптәннән Коръәндә бирелгән хаким сурәтенә туры килми. Бу күп очракта исламның беренче чорларына караган традицияләрдән читләшүгә китерә. Бохара муллала-

Фото: ru.wikipedia.org

ры әмир хакимиятен какшамас, илаһи, Аллаһтан бирелгән дип раслый һәм әйләнә-тирә дөньяның үзгәрешләр таләп итүен кире кага. Халык зарлана, хәерчеләнә, урта гасыр икътисады җимерелә, судларда акча һәм хакимият абруе өстенлек итә. Бохара Россия белән Британиянең уен картасына әверелә, ә дин галимнәре һәм әмир үз хакимиятен иң гадел һәм Аллаһ тарафыннан сайланган дип мактауларын дәвам итә.

Бохарада исламның беренче чорларына хас иҗади рухка кире кайтуны яклаучы кешеләр һәрвакыт була. Ләкин алар әлегә чынлап торып Европа дәүләтләренең көчен аңлап бетерми. Өстәвенә, бер яктан юмартланып бүләк өләшү, мактау, икенче яктан җәзага тартулар канәгать булмаганнарның авызын яба, дәшмәскә мәҗбүр итә. Төньяктан килгән Габденнасыйр Курсави гына тынычлыкны боза. Аның бәхәстәге осталыгы һәм ислам тәгълиматы белгече буларак даны еракларга тарала.

ХӨР ФИКЕРЛЕЛЕК ӨЧЕН ҖӘЗАЛАНА

Җавап озак көттерми. Хәйдәр әмир җиде мөфти һәм җиде казый ярдәме белән Курсавига каршы фәтва, ягъни мөселман хокукы акты чыгара. Аңа үлем җәзасы яный, китаплары законга каршы дип табыла һәм утка ягыла... Җавап йөзеннән Ниязкули ат-Төрекмәни әмиргә Бохара халкын фетнәгә күтәрү белән яный. Соңрак татар галимнәре өчен Курсави мисалы һәрвакыт сабак була, чөнки дин дәүләт статусына ия булган мөселман илләре белән чагыштырганда, Россиядә фикер хөрлегенә урын кала. Бохарадан аермалы буларак, акча һәм җәза чаралары белән ныгытылмаган Россия системасы шактый йомшак эш итә.

Курсави Бохарадан үз мәдрәсәсенә кайтып китә. Аның укучысы Шиһабетдин Мәрҗани соңрак Курсави турында «үзенең акылы-зиһене ярдәмендә Белем хәзинәсенең тылсымлы йозагын ачты, аннан фәннәрне алып, халык каршында кыйммәтле чәчкәләр үстереп, аларны халыкка таратты» дип яза. Мәрҗани Курсавиның үз әсәрләрен татар телендә язуына һәм балаларны ана телендә укытуына аеруча басым ясый.

Ләкин Бохара казыйлары Курсавины онытмый. Өч мөфти Казан һәм Каргалы муллаларына хат юллый. Анда галим «мөртәт», ягъни диннән язган дип игълан ителә. Замандашларының күпчелеге Курсави идеяләрен кабул итми, аның бәхәстәге осталыгыннан һәм үткен теленнән шүрли. Казан руханилары очрашуларына Курсави килгәндә, башка муллалар чыгып китү ягын карый.

ЧИТТӘ ВАФАТ БУЛА

Курсави заманында татарларда дини бәхәсләр өчен уңай шартлар тудырылган интеллектуаль атмосфера хөкем сөрми. Урта Азия базарлары белән сәүдә алып баручы байлар да Бохара хакимияте каргаган Курсавины чит итә.

Шулай да Курсавиның карашы дини нигезгә генә түгел, Россия коралының көчен, ил икътисадының куәтен, рус дәүләтенең алгарышлы потенциалын белүгә дә таяна. Ул һәр мөселман кешесе Аллаһ сүзенең асылына мөстәкыйль рәвештә төшенгәндә генә ислам кыйммәтләрен саклап булачак дип саный. Курсави Коръәнне мөстәкыйль аңлатырга, дин белгечләренең искечә аңлатуларыннан баш тартырга чакыра. Параллель рәвештә татар телендә беренче Коръән тәфсирен эшли башлый, ул Ногмани тәфсире буларак билгеле.

Бохарадагы дошманнары Курсавины үз ватанында да эзләп таба. Казан артындагы Оры авылы мулласы Фәтхулла бине Хөсәен мөфти Мөхәммәтҗан бине Хөсәенгә шикаять юллый. Анда ул Курсавины динсезлектә, укучыларга белем бирүне, вәгазьләрне хакимиятнең рөхсәтеннән башка алып баруда гаепли.

Бохарада үлем җәзасына хөкем ителгән, яла ягулар аркасында туган авылы мәдрәсен ташлап китәргә мәҗбүр булган Курсави бер төркем шәкерте белән үз карашларын вәгазьләү өчен күңеле тарткан урын эзләп хаҗга китә һәм Истанбулда чумадан вафат була. Курсави бик иртә дөньялыктан китсә дә, аның үлемсез идеяләре кала.

ИДЕЯЛӘРЕ ЯШИ

Аның вафатыннан соң 30 ел узгач, тагын бер бөек ислахчы Шиһабетдин Мәрҗани Бохарада яшерен юллар белән Курсави китабының бер данәсен таба һәм аның фикердәшенә әверелә. Мәрҗанине дә диннән язган дип чыгаралар. Әмма Россия гаскәрләренең Бохарага кадәр барып җитүе татар дөньясындагы икътисадый кризис һәм татарлар ассимиляциясенең яңа дулкыны фикерләргә сәләтле кешеләрне Курсави идеяләрен кабул итәргә этәрә. Мәрҗани беренчеләрдән булып Курсавины татар дөньясында дини яңарыш хәрәкәтенең атасы дип атый.

Узган гасыр башында Оренбург Диния нәзарәте казые Ризаэтдин Фәхретдин Курсави биографиясен мондый юллар белән башлый: «Аның вафаты Казан һәм Болгар мөселманнары өчен генә түгел, бөтен мөселман дөньясы өчен бөек галимне югалтуга тиң була». Ризаэтдин казый өчен галим үз хезмәтләре һәм гамәлләре белән үлемсезгә әйләнә, шундый үлемсезләргә Курсави да керә. Риза Фәхретдин сүзләренчә, бөтен чорларда да иң яхшы кешеләр иҗтиһад иткән, һәм бу акылның җиңүендә, аның өстенлегенә ирешүдә иң яхшы метод булып тора.

Курсави биргән төп сабак: кешене хакимият күрсәтмәләрен сукырларча башкаручы хокуксыз хайванга әйләндерергә ярамый. Әгәр кеше хокуксыз, аның фикерләүгә булган хокукы инкяр ителә икән, бу хакимияттәгеләр өчен бик уңай, ләкин мондый дәүләт җиңелүгә дучар булачак. Татарларда вөҗдан иреге принцибын игълан иткән шәхес – татар хөрлегенең беренче ислахчысы һәм карлыгачы Габденнасыйр Курсави була.

ТАРИХИ ШӘХЕСЛӘР

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ.
ТАТАР ТАРИХЫ АТАСЫ

Айдар Юзиев, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор

1870 елда Казанда «Назурател-хак...» («Хакыйкатьне күзәтү...») китабы дөнья күрә. Китап авторны үз ватанында гына түгел, бөтен мөселман Көнчыгышында таныта, чөнки әлеге хезмәттә үз заманы һәм даирәсе өчен яңа дини-реформаторлык идеяләре чагылыш таба. Шиһабетдин Мәрҗани күренекле дини ислахчылык идеологына әверелә. Әмма бөтен тормышының төп китабы әле язылмаган була...

Шиһабетдин Мәрҗани буларак билгеле Һарун бине Баһаутдин бине Сөбхан бине Абдулкәрим (1818–1889) башлангыч белемне Ташкичү авылы мәдрәсәсендә, үзенең этисендә ала. Бохарада укыганнан соң туган ягына кайта. 1850 елның 30 мартында Оренбург Мөселман диния нәзарәте Мәрҗанине Казандагы Беренче мәчетнең имам-мөдәррисе итеп билгеләү турында указ чыгара. Шиһабетдин Мәрҗани соңгы көннәренә кадәр шушы мәчеттә эшли. Тарихка бөек татар теологы, фәлсәфәчесе, тарихчысы, дини ислахчы һәм мәгърифәтче буларак кереп кала.

«КАЗАН ҺӘМ БОЛГАР ХӘЛЛӘРЕ ТУРЫНДА ФАЙДАЛАНЫЛГАН ХӘБӘРЛӘР»

1870-80 нче елларда Мәрҗани иҗаты һәм эшчәнлеге татарларның мәгърифәтчелек-агарту хәрәкәте белән кушылып китә. Мәгърифәтчелек эшчәнлегенең бер ягы педагогикага бәйле. Мәрҗани татар руханилары арасыннан беренче булып тугыз ел дәвамында Казан татар укытучылар мәктәбендә (1876 елның 13 сентябрендә ачыла) дин белеме укыта. Ул татар халкының этногенезы мәсьәләсенә мөрәҗәгать иткән беренче татар тарихчысы була. Аның «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») китабы әлеге проблемага багышланган.

Шиһабетдин Мәрҗани якты эз калдырган иң әһәмиятле белем өлкәсе дини фәлсәфә була. 70-80 нче елларда аның иң күренекле хезмәтләре басыла, алар арасында «Китаб әлхикмә әл-балига әл-җания фи шәрх әл-акаид әл-хәнәфия» («Хәнәфитләр догмаларын аңлатырга булышучы өлгергән фәлсәфә турында китап») дә бар. Мәрҗанинең дини-фәлсәфи карашлары спекулятив теология һәм ислам догматикасы нигезләрен аңлату мәсьәләләрен тәнкыйтьләүдә чагылыш таба.

«БАБАЛАРЫБЫЗ ҺӘМ АЛАРНЫҢ КИЛӘЧӘК БУЫННАРГА СӘЛАМНӘРЕ ТУРЫНДА ҖЕНТЕКЛӘМӘ»

«Вафияйәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Бабаларыбыз һәм аларның киләчәк буыннарга сәламнәре турында җентекләмә») – Мәрҗанинең кульъязма хезмәте, ул аны гомере буе яза. Мәрҗани Көнчыгышның күренекле шәхесләре турында энциклопедик сүзлек төзү эшенә алынган Россиянең беренче галиме була. Ул татар фәне, гомумән Россиядәге көнчыгыш белеме тарихын алга таба үстерү, халыкларның бер-берсе турындагы белемнәрен тирәнәйтү өчен мондый төр тикшеренүләрнең зарурлыгын аңлый.

Әлеге эшне Шиһабетдин Мәрҗани фәнни эшчәнлек алдында торган төп бурычларның берсе дип саный. Энциклопедия өчен материаллар туплаганда ул бик күп беренчел чыганакларга – борынгы тәңкәләргә,

Фото: © ummet.kz

ярлыкларга, телдән-телгә күчкән һәм язма риваятьләргә, кабер ташларындагы язуларга мөрәҗәгать итә, гарәп, фарсы, төрки, өлешчә рус чыганакларыннан мәгълүмат ала.

Хәзерге вакытта җиде кульязма том (җиденче том – алтынчысының дубликаты) Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана. Хезмәтләренең төп өлеше «вафийәт» дип аталган сүзлек рәвешендә эшләнгән, анда атаклы кешеләрнең биографияләре үлгән еллары буенча урнаштырылган, ә еллар эчендә – алфавит буенча. Энциклопедик сүзлекне төзүнең мондый методы мөселман Көнчыгышында күптәннән кулланыла (биографияләр – тәбәкат жанры).

Алтынчы том азагында колофон урынында: дата – хиҗрә буенча 1304 ел – «Ошбу түбәнчелекле Аллаһ колы Әбү Усман бине Абдаррафиа аш-Шибкави» дип китерелгән, моны мәгълүматны язуның тәмамланган көне һәм язучының исеме буларак карарга була. Язучының тулы исеме – Әбү Усман Борһанетдин бине Абдаррафиа аш-Шибкави – Мәрҗанинең «Мөкаддиму», «Мунтахаб әл-вафия» һәм «Әл-фаваид әл-мөхиммә» хезмәтләрен бастырган укучысы. Мәрҗани Мәккәгә хаҗга киткәндә Аш-Шибкави аны имам-хатыйб буларак алыштыра.

ЭНЦИКЛОПЕДИЯ ҺӘМ МӘРҖАНИ ФИКЕР СӨРЕШЕНЕҢ АСЫЛЫ

«Вафияйәт әл-әсляф» VII гасырдан алып XIX гасыргача чорны үз эченә ала (Мөхәммәд пәйгамбәрнең үлгән елыннан алып Мәрҗани яшәгән вакытка кадәр). Анда 6057 галим, язучы, фәлсәфәче һәм VII–XIX гасыр Көнчыгыш иҗтимагый-сәяси эшлеклесенең биографиясе тупланган. «Вафияйәт әл-әсляф...» хезмәтенең үзенчәлеге һәм әһәмияте шунда: Мәрҗани гарәп-мөселман материалларына гыйлемнең төрле өлкәләренә караган җирле мәгълүматны да өсти.

Татар фикер иясе урта гасыр тарихчылары тарафыннан табылган фактларны туплау һәм кәгазьгә төшерү белән генә чикләнми. Ул Шәрык дөньясы рухи мәдәниятенең бай материалын иҗади эшкәртә, теге яки бу тарихи вакыйга һәм фактларга үз бәясен бирә. Монда аның традицион мөселман белеме генә түгел, мәгърифәтче галим буларак эрудициясе һәм таланты да чагылыш таба. Энциклопедия шуның белән дә кыйммәтле: тарихи шәхесләрне сайлаганда, аларның тормыш юлын, эшчәнлеген яктыртканда, Көнчыгыш мәдәнияте күренешләренә бәя биргәндә, аның эчтәлеген ачканда Мәрҗани фикер сөрешенең асылы чагылыш таба.

Бу – оригинальлеге Идел буе, Урал төбәге, Урта Азия, Кавказ, Кырым – XVII–XIX гасыр төрки дөньясына караган һәм моңа кадәр фәнни әйләнешкә кермәгән материаллар белән билгеләнгән компилятив хезмәт.

«Вафияйәт әл-әсляф...» хезмәтендә автор үз хезмәт һәм эшчәнлекләре белән рухи мәдәниятнең теге яки бу өлкәсен бөтен мөселман дөньясына таныткан Көнчыгышның атаклы галимнәре, җәмәгать эшлеклеләрендә тәрәккыяткә илтүчеләрне күреп, аларның тормыш юлын сурәтли. Бу турыда әл-Фараби, Бахманйара, Әбүгалисина, Ибнә Рустә кебек исемнәре мөселман дөньясында да, Европада да билгеле булган атаклы Көнчыгыш перипатетикларының биографияләре дә сөйли.

ТАТАР ҺӘМ ГАРӘП-МӨСЕЛМАН МӘДӘНИЯТЕ ҺӘЙКӘЛЕ

Үзе язган биографияләрдә Мәрҗани, кагыйдә буларак, кешене җәмгыятьтә билгән социаль хәленә карап түгел, бәлки акылы, белеме, гыйлеме буенча бәяли. Шул ук автор үзе яшәгән җәмгыятьтә шәхеснең урыны еш кына белем дәрәҗәсе буенча түгел, ә байлыгы һәм билгән вазыйфасы буенча билгеләнгәнен дә аңлый. Әйтик, берәүнең биографиясен Мәрҗани аның гыйлемле, фәндә эз калдырганы өчен түгел, ә мал-мөлкәте, байлыгы белән күренекле булганы өчен бирелүен әйтә.

Мәрҗани хезмәтенең структурасы аның тарихны фән буларак аңлавы белән тыгыз бәйләнгән. Галим тарихны Коръәнне тәфсирләү, аны уку кагыйдәләре, хәдисләр һәм сөйләүчеләр турында фән, фикъһ кебек традицион фәннәргә кертә һәм урта гасыр мөселман мәдәниятендә әлеге дисциплина (тарих жанры) турында формалашкан карашларга таяна. Мәрҗани тарихка кайчандыр булган вакыйгаларны теркәү-беркетү ролен генә бирми, бәлки ул, фән буларак, теге яки бу хәлләргә китергән шартларны, сәбәпләрне өйрәнергә тиеш дип саный. Берүк вакытта тарихи күренешләрнең социаль аспектын аерып күрсәтеп, татар халкы тарихын аңлатуда новатор буларак та ачыла.

Мәрҗанинең «Вафияйәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Бабаларыбыз һәм аларның киләчәк буыннарга сәламнәре турында җентекләмә») татар, тулаем гарәп-мөселман мәдәнияте һәйкәле булып тора. Әлеге энциклопедик хезмәт Якын Көнчыгышта яшәгән мөселманнарның гына түгел, Урта Көнчыгыш, Россия төбәкләре: Идел һәм Урал буе, Кавказ һәм Кара диңгез буе халыклары арасында мәдәни бәйләнешларның көчәнлеге, үзара йогынтысы үрнәгенә әйләнә һәм әлеге халыкларның тарихын өйрәнүдә әһәмиятле чыганак булып тора.

ГАБДУЛЛА БУБЫЙ. МӘГЪРИФӘТ ИСЛАХЧЫСЫ

Әскәр Сабиров

Иж-Бубый. Ерак татар авылы, Казанга кадәр – өч йөз чакрымнар тирәсе. Ләкин нәкъ менә әлеге авыл XIX–XX гасырлар чигендә Габдулла Бубый тырышлыгы белән ислам дөньясында мәгърифәт үзәгенә әверелә, һәм бирегә гыйлем эстәргә хәтта Россия империясеннән генә түгел, чит илләрдән дә киләләр.

Иж-Бубый мәдрәсәсе XIX гасырның 90 нчы еллары уртасына кадәр башка кадими авыл мәдрәсәләреннән артык аерылып тормый. Әмма күзгә күренеп үзгәрә баручы дөнья көтеп тормый: заманнан артта калмас өчен какшамас, үзгәрмәс саналган догмаларны яңадан карарга, яңа белем һәм фикерләрне үзләштерергә кирәк. Иж-Бубыйда үзгәрешләрнең инициаторы Габдулла Бубый мулла була. Аның мәсләктәше һәм фикердәше – абыйсы Гобәйдулла.

МИЛЛӘТ АЛГАРЫШЫ ХАКЫНА

Ният-максатлар гади, ләкин берүк вакытта гаять зур да: милләтнең алгарышын тәэмин итү өчен мәгариф системасын үзгәртеп кору. Мәдрәсәдә акрынлап барысы да үзгәртелә: укыту ысуллары, остазлар белән шәкертләр арасындагы мөнәсәбәтләр, белем бирү программалары. Хәзер биредә татар, рус, гарәп, фарсы телләрен, әдәбият, математика, физика, химияне укыталар... Дөньяви предметларның саны арта бара, ә дини фәннәрне укыту кабатлау һәм догмаларны ятлауга гына кайтып калмый…

Мәчет имамнары, кадими мәдрәсә мөгаллимнәре шок хәлендә кала: берәүләре ярсый-ярсый ләгънәт укыса, икенчеләре җавапка тартуны таләп итә. Ләкин ислахчыларның тылы нык: ата-анасы тулысынча алар ягында. «Әлеге сигез ел дәвамында без мәрхүм әтиебез ярдәме аркасында ээзәрлекләүгә һәм реформа дошманнары каргышларына дучар ителмәдек, – дип язачак Габдулла Бубый үзенең истәлекләрендә. – Чөнки ул безнең якта булып, җәдидчелекнең һәм мәктәпләрне үзгәртеп коруның зарурлыгын исбатлап торды, бу темага кагылышлы бәхәсләрне ул алып барды, тирә-яктагы бөтен муллаларның остазы һәм белеме буенча аларның барысыннан да өстен булганга, ул аларга авыз ачарга да ирек бирмәде». Аналарының ярдәме дә зур була: «Ул безнең эшләрне яклады, диндарлыгы һәм тәкъвалыгы аркасында караңгы халык тарафыннан гына түгел, тирә-яктагы муллалар тарафыннан да изге саналганга, без аның яклавыннан һәм игътибарыннан нык файдаландык», - дип яза Габдулла Бубый.

Күп кенә яңа идея һәм киләчәктәге даһи ачышларның орлыгы гаилә тәрбиясе нәтиҗәсендә салына, алар шытып чыгып күркәм уңышка китерә. Габдулла Бубыйның ислахчылык идеяләре дә буш урында гына пәйда булмый.

«ШӘРИГАТЬ БУЕНЧА БУЛМАСА, УЛ ИРЕК КУЙМАС ИДЕ»

Габдулла – Иж-Бубый авылында яшәгән Габделгаллән мулласы белән Бәдрелбәнат абыстайның хөрмәткә лаек гаиләсендә төпчек бала. Туган нигездә мәхәббәт һәм татулык хөкем сөрә, ир белән хатын Иж-Бубый мәдрәсәсендә авыл балаларына сабак бирә, берсе – малайларны, икенчесе кызларны укыта. Гаиләдә ислам кануннары буенча яшиләр. Барысы да башка татар руханилары гаиләләрендәге кебек. Хәер, алай дип әйтү дөреслеккә туры килеп бетмидер. Күпчелек гаиләләрдәге ир-атның һичсүзсез өстенлеге биредә бөтенләй юк.

Әниләре, Бәдрелбәнат абыстай, акыллы һәм укымышлы хатын, гарәп һәм фарсы телләрен белә. Кече күңелле һәм гадел ире белән үзен тиң тота. Ихтимал, тиң булганнан да күбрәктер. Һәм аның авылдагы абруе бәхәссез, дип әйтергә була. Бертуган Бубыйлар ата-анасы мәдрәсәсен җәдидчелек рухында үзгәртеп корырга хәл иткәч, ул тулысынча уллары ягына баса. «Аңламаучы һәм шуңа күрә безнең яңалыкларга каршы килүче кешеләрне без болай дип туктатабыз: «Безнең эшебезнең башында анабыз торды, әгәр эшебез шәригать буенча булмаса, ул ирек куймас иде», – ди Габдулла Бубый.

Ләкин болар барысы да бераз соңрак булачак, ә әлегә Габдулла әтисенең мәдрәсәсендә белем ала. Гадәти авыл мәдрәсәсеме? Шулай ук бигүк дөрес түгел. «Безнең иске мәдрәсә чит җирләрдә дан казанмаса да, – дип искә ала ул истәлекләрендә, – анда үз заманы өчен атаклы Түнтәр, Кшкар, Казан мәдрәсәләрендә

Фото: wikipedia.org

укытылган бар нәрсәгә дә өйрәтәләр иде. Бу хәтта мәдрәсәләрдә укытылмый яисә бик аз өйрәнелә торган Коръән тәфсирләре һәм хәдисләре безнең мәдрәсә программасына кертелгән иде».

Туган нигездә хөкем сөргән белем культы, мәгърифәткә хезмәт итү үрнәге булган ата-ана, фәлсәфә белән җитди кызыксынучы абыйсы Гобәйдулла, ниһаять, бернинди дә тыю куелмаган фикер хөрлеге – болар барысы да, табигый ки, Габдулланың шәхес булып өлгерүенә зур йогынты ясый. Ул Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрен өйрәнә, җәдидчелек идеяләрен таратучы Ибраһим Гаспринскийның «Тәрҗеман» газетасын укый.

«АКЫЛГА СЫЙМАСЛЫК КАРШЫЛЫКЛАРНЫ ҖИҢЕП»

1895 елда Габдулланы указлы мулла итеп билгеләгәндә ул инде Гаспринский идеяләрен кайнар яклый торган була. Шул ук елда Бубый, этисенең хәер-фатихасын алып, Иж-Бубый мәдрәсәсен үзгәртеп коруны башлап җибәрә. Берничә айдан соң, Истанбулда алдынгы «Мәктәбе мулькиеи шахане» югары гимназиясендә укуын тәмамлап, абыйсы Гобәйдулла кайта, ул дәртләнеп яңа эшкә тотына.

Кыз туганы Мөхлисә, ир туганнарының хатыннары белән бергә, шулай ук әлеге гаять зур проектны тормышка ашыруда бик күп көч түгә. Аларга бертуган Бубыйлар тарафыннан эшләнгән укыту ысулларын үзләштерергә, хатын-кызлар мәдрәсәсен реформалауны үз кулларына алырга туры килә. Габдулла истәлекләренә караганда, хатын-кызлар бөтен күңелен биреп эшли. «Алар өчәүләп кичләрен бездән сабак алды, көннәр буе мәктәптә укытты, акылга сыймаслык каршылыкларны җиңде. Россия хатын-кызларын мәгърифәт юлыннан җибәрү хакына бик күп бәла-каза һәм авырлыкларны үз өсләренә алды, бер тиен хезмәт хакы алмыйча, бары тик милләт хакына бөек кешеләргә генә хас гаять зур хезмәт һәм тырышлык куйды».

«УЛ ЯШЬЛӘРНЕ ТАҢ КАЛДЫРДЫ»

Әлеге фидакарь хезмәтне, бөек үзгәрешләрне, ниһаять, ислахчыларның үзләрен һәм яңа идеяләрне чордашлары ничек кабул иткән соң? Менә Җамал Вәлидинең яшь буынга язып калдырган сүзләре: «Ул башларында фикер уяна гына башлаган яшьләрне дини мәсьәләләрдәге кыюлыгы белән таң калдыра иде. Белмим, искелек яклы руханиларның абруен югалтуга һәм кадими мәдрәсәләрнең җимерелүенә этәрүдә моннан да көчлерәк тагын берәр әсәр булдымы икән? Иж-Бубыйга укырга дип килүчеләрнең күбесе, шул исәптән мин дә, «Хакыйкать» не укыган һәм әлеге фикерләрне авторның үз авызыннан ишетергә омтылган затлар идек».

Полемик өслүбтә язылган «Хакыйкать» әсәре – Бубыйның иң танылган дини хезмәте. Бубый фән алгарышы һәм белем ышанычсызлык тудырмый дип раслый, ислам мөселманнардан гыйлемне һәркайдан туплауны таләп итә дип тә үгетли. Ул үзенең укучыларын фәнгә фанатикларча дошманлык кылудан кисәтә, мәдрәсәдә географияне һәм башка табигать фәннәрен укытырга өнди. Шиһабетдин Мәрҗани кебек үк Бубый да исламны кешеләр арасындагы тигезлек һәм туганлык принципларына аеруча туры килә торган идеология дип саный.

Табигый ки, яшьләр мәгърифәт учагына тартыла башлый! Сарапул өязе халык училищесы инспекторы Николай Меньшиков, 1903 елда яңа ысуллы уку йорты белән танышып йөргәндә: «гомуми тәртип буенча Иж-Бубый шактый югары тора, шуңа күрә рус-татар мәктәбе укытучылары аны мөселман академиясе белән чагыштыра», – дип билгеләп үтә. Бу вакытта инде яшьләр ерак Иң Бубый авылына Мәскәүдән һәм Уфадан, Сембер һәм Әстерханнан белем эстәргә агыла...

ҮРНӘК МӘДРӘСӘ ӨЧЕН – ТӨРМӘ

Тагын биш елдан бирәдә татар хатын-кыз мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү хокукы алалар һәм рәсми таныклыклар бирә башлыйлар. Хәзер Иж-Бубый мәдрәсәсе – башка мәктәпләр өчен реформалау үрнәге, һәм империянең Европа өлеше өчен генә түгел. Ә хатын-кызлар мәдрәсәсен җитәкләүче Мөхлисә Бубый мәгърифәтле ислам дөньясында абруйлы шәхес санала (1917 елда ул ислам дөньясында беренче хатын-кыз казыя итеп сайланачак – ред. иск.).

Ләкин империягә аның черек асылын аңларга сәләтле гыйлемле халыклар кирәк түгел... 1908 елда Халык мәгарифе департаменты уку округлары попечительләренә түбәндәге күрсәтмәне бирә: «халык училищелары инспекторлары аша урыннарда бик яшерен һәм сак тәртиптә соңгы елларда туган шәхси мөгаллимнәр сыйныфлары турында мәгълүматны тупларга».

Өч елдан соң хәлләр үзгәрә. 1911 елның 30 гыйнвары төнендә Иж-Бубыйга йөз атлы сакчы белән жандарм ротмистеры килә. Тентү-туздыру өч көн дәвам итә. Ирләр мәдрәсәсен ябалар (хатын-кызларныкы әле тагын бер ел эшли), Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйларны, ирләр мәдрәсәсенең бөтен укытучыларын Сарапул төрмәсенә илтәләр, алар анда 16 ай суд хөкемен көтеп ята.

1912 елның 28 маенда мәхкәмә Бубыйны хакимияткә хөрмәт күрсәтмәүдә һәм фетнәгә чакыру характерындагы әдәбият таратуда гаепли: «Хакыйкать» очеркларында хөкүмәткә каршы фикерләр табалар. Габдулла Бубыйны алты айга төрмәгә ябу турында карар чыгаралар.

Төрмәдән чыккач, ул Кулҗәгә (Кытай Төркестаны) китеп, җәдиди хатын-кыз укытучылар семинариясе ача. Патшаны бәреп төшерү турындагы хәбәрне бик дәртләнеп каршы ала, чөнки ирекле Россиядә татар халкының якты киләчәгенә өмете зур була. Туган ягына кайтканда туберкулез белән авырый торган була, гомеренең азагына кадәр Иж-Бубыйда укыта.

ГАЛИМҖАН БАРУДИ.
ТАТАРНЫ ДӨНЬЯГА ТАНЫТУЧЫ

Разыя Сәхипова

Фото: ru.wikipedia.org

Без аны кем дип атасак та ялгышмабыз – дин галиме, мәгърифәтче, реформатор, язучы, журналист, сәясәтче һ.б. Барудиның сәясәттә үз юлы булган. Ул каршылыкларны, проблемаларны мәҗбүриләү, көч куллану ысулы белән түгел, ә тыныч юл белән хәл итү ягында торган.

ҖИҢҮ ҺӘМ ҖИҢЕЛҮЛӘР

Галимҗан Барудиның татар халкы тарихына керткән иң зур хезмәте яңарту-җәдидчелек хәрәкәте белән бәйле. Ул мәгариф системасының нинди булырга тиешлеген, киләчәк буынны укыту-тәрбияләүне алдан күрә белгән. Яңача укытуны Россиянең татарлар яшәгән төбәкләренә дә таратуны максат итеп куйган. Шуңа күрә дә Троицк, Чиләбе, Кызылъярда (Казахстандагы Петропавел шәһәре) җәдидчелек нигезендә эшләячәк мәктәп-мәдрәсәләр ачуны дәлилләп, аңлатып йөргән. Эшне ул җирле ишан, мулла, күренекле кешеләрдән башлаган.

1905 ел вакыйгалары Галимҗан Барудиның иҗтимагый активлыгын яңа югарылыкка күтәрә. Ул гыйльми-педагогик эшчәнлеге белән беррәттән социаль-иҗтимагый хәрәкәтләрдә катнаша. Нәтиҗәдә, татар җәмәгатьчелеге арасында олы абруйга ия җитәкчеләрнең берсенә әверелә.

Галимҗан Баруди Россия мөселманнарының II һәм III корылтайларында катнаша. «Иттифак әл-Мөслимин» партиясенең актив оештыручыларыннан берсе була. 1906 елның 16-21 августында узган Бөтенросиия мөселманнарының III корылтаенда Диния нәзарәтен үзгәртеп кору буенча комиссия төзелә. Аның рәисе итеп Галимҗан Баруди билгеләнә. Комиссия 13 пункттан торган доклад тәкъдим итә. Анда мөфтиләрне 5 елга сайлау, Диния нәзарәтләренә мәктәп-мәдрәсәләр ачу өчен акча табу бурычын йөкләү, имамнарга дәрәҗә бирү, бәхәс, никах мәсьәләләрен алар карамагына күчерү кебек проблемалар күтәрелә. Үз вакыты өчен бу бик алдынгы документ була. Ләкин мөселманнарның теләгенә хөкүмәт битараф кала. Документта каралган гамәлләр тормышка ашмый.

Ни кызганыч, бу күңелсезлекләрнең башы гына була: ниндидер шикаятьләр нигезендә Барудины 1907 елның 17 мартында 2 елга Вологда губернасына сөргенгә сөрәләр. Аның белән бер вакытта Гаяз Исхакый, Салихҗан Галиев (энесе), мулла Габдулла Апанаев һәм Казан сәүдәгәрләре Казаковлар да хөкемгә тартылып сөргенгә озатыла. Аларны азат итүне сорап, абруйга ия күп кенә кешеләр хөкүмәт җитәкчеләренә мөрәҗәгать итә, тиздән сөрген срогын чит илгә китеп үткәрергә рөхсәт бирелә.

Галимҗан Баруди башка хәзрәтләр белән илгә 1910 елда кайта. Аларны киң җәмәгатьчелек шатланып каршы ала. Ләкин 1911 елда, «панисламчылык» белән көрәш сылтавын табып, татар активистларына каршы яңа эзәрлекләүләр башлана. Галимҗан хәзрәт губернаторга аңлатма-хат белән мөрәҗәгать итә. Шуңа да карамастан, тынычсызлау, яла ягулар дәвам итә. Ул, төшенкелеккә бирелмичә, бик авыр булса да, туры юлдан баруын дәвам итә. Һәм янә ил гизәргә чыгып китә.

Галимҗан Баруди Төркестанда вакытта, 1917 елның маенда, Мәскәүдә I Бөтенроссия мөселман корылтае уза. Анда 800 ләп делегат катнаша. Милли мәсьәләләрне карау белән беррәттән, мөфти сайлау да уздырыла. Оренбург Диния нәзарәте мөселманнарның Үзәк диния нәзарәте итеп үзгәртелә. Мөфти урынына алты кандидатура тәкъдим ителә. Алар арасын-

да Муса Бигиев, Габдулла Бубый, Зыя Камали, Садри Максуди, Хәсәнгата Габәши, Галимҗан Барудилар күрсәтелә. Күпчелек тавыш белән Галимҗан Баруди сайлана.

Бу карар аның өчен көтелмәгән яңалык була. Төркестаннан кайткач, туганнары белән киңәшә, үз мәхәлләсе кешеләренең фикерен өйрәнә. Аларның хуплавын, ярдәмен тоеп, ризалыгын бирә. 1917 елның 17 июнендә рәсми сайланган мөфти буларак Уфага килә.

Совет власте урнашканнан соң, 1917 елның 20 ноябрендә Уфада Эчке Рәсәй һәм Себер төрки-татар мөселманнарының Милләт мәҗлесе җыела. Мәҗлес Идел-Урал штатын оештыру хакында карар кабул итә. Ләкин Милли идарә озак яшәми, 1918 елда таратыла.

1918 елның маенда Галимҗан Баруди, Россия мөселманнары җитәкчесе буларак, рәсми хакимият органнары белән сөйләшү өчен Мәскәүгә килә. Анык нәтиҗә ала алмый. Соңрак Сталиннан «Диннең дәүләттән тулысынча аерылу шартын катгый үтәгән хәлдә, Диния нәзарәтенең эшен дәвам итәргә рөхсәт» кәгазе ала.

Баруди акрынлап динне сәясәттән аеру ягына авыша. Бу чорда мөселман уку йортларында дини предметларны укыту тыела. Галимҗан Барудиның мәктәп, мәдрәсәләрне дини рухта үзгәртеп коруга, имамнарның хәлен үзгәртеп, аларның белемен арттыруга юнәлтелгән реформаларын тормышка ашыру мөмкин булмый. Әйе, ул бик авыр чорда мөфти хезмәтен алып бара. Шулай булса да халкы өчен җан атып яшәвен дәвам итә. Моның янә бер ачык мисалы: Идел буенда 1921 елгы ачлыкның масштабын бәян итеп Сталинга һәм кайбер илләргә хат яза.

Әнә шулай милләттәшләре өчен тырышып йөргәндә, 1921 елның 6 декабрендә, Мәскәүдәге Боткин хастаханәсендә аның йөрәге тибүдән туктый. Аны Казанга алып кайтып, зур хөрмәт белән татар зиратында җирлиләр.

БАРУДИНЫҢ БАЙ МИРАСЫ

Галимҗан Барудиның дини идарә җитәкчесе булып эшләгән чоры бик катлаулы, авыр сәяси-иҗтимагый чорга туры килә. (Октябрь революциясе, чех-словак күтәрелеше, Колчакның үзен Россия хакиме дип игълан итүе һ.б.). Менә шул шартларда Галимҗан Баруди көрәш сафында кала. Моны без аның «Кызылъяр сәфәре» исемле беренче әсәре буенча беләбез. Бу аның дөньяви әсәрләреннән берсе. Аның тормыш һәм хезмәт юлларын өйрәнгәндә, иң яхшы чыганак булып нәкъ менә үзе язган мәкаләләр, дәреслек һәм язмалар тора. «Кызылъяр сәфәре» әсәре тирән эчтәлекле, мәгълүматка бай. Баруди төрле сәфәрләре вакытында үзе яшәгән һәр шәһәрнең тарихи үзенчәлегенә кыскача кагылып уза. Бу «Кызылъяр сәфәре»ндә дә күренә. Чиләбе, Троицкидагы хәлләр нигезендә ил, мәдәният, мәгариф, дингә шомлы, авыр хәлләр янаганын аңлый һәм шушы әсәре, чыгышлары, хезмәтләре белән халыкны кисәтә. Ул каршылыклар белән актив көрәш позициясендә кала.

Моңа кадәр дә Баруди көндәлек матбугат битләрендәге язмалары белән халыкка таныш була. Ә «Кызылъяр сәфәре» 1917 елдан соң татар әдәбиятында нәшер ителгән беренче зур әсәр була. Бу зурлык аның күләмендә түгел, ә җанлы тормыш, халыкларның милли-тарихи яшәешен тасвирлавында. Соңрак әдәбият галимнәре әсәрне «яңа этап әдәбиятының чишмә башы» дип атый.

Шул яңа агымны дәвам итеп, Баруди «Хатирә дәфтәре» әсәрен яза. Ул да татар әдәбиятында яңа юнәлеш була. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары нәтиҗәсендә туган җимереклек, ачлык, фәкыйрьлек әлеге язмага нигез итеп алына. Авторның революцияне, хакимият алышынуын да кабул итүе күрсәтелә. Яңа хакимияттән, яңа тормыштан ул ирек, уңайлыклар көтә. Шул дәһшәтле елларда ул, халык белән аралашып, бер урыннан икенче урынга йөреп, тормыш казанында кайнап, туктаусыз иҗат итә.

Галимҗан Баруди – утызга якын дәреслек авторы да. Ул яңа ысул белән укыту өчен беренче әлифбаны язган. Аның 12 басмасы дөнья күргән. Гарәп теле грамматикасы, өч телдә чыккан сүзлеге бүген дә кулланылышта бар.

Аның дәреслекләре методик яктан отышлы, эчтәлекләренә җанлы әңгәмә элементлары кертелгән. Алар материалны аңлап, фикер йөртеп үзләштерергә этәргеч ясый.

Баруди үзенең бай китапханәсен дәүләткә тапшырган. Бу зур мирас бүген Казан федераль университетының фәнни китапханәсендә – шәрык бүлегендә саклана. Әлеге китаплар, кулъязмалар бөртекләп өйрәнүне көтә.

Әйе, бу олпат шәхеснең исемен бүген дә беләбез, ишетәбез. Казанда Галимҗан Баруди исемен йөрткән урам бар. Киров районында ул. Галиев мәчете һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе әлеге нәселгә һәйкәл булып эшләп килә. Заманында ул мәдрәсәне көнбатыш илләренең классик гимназиясе дәрәҗәсенә күтәрә. Бу хакта хәтта Англиянең газета-журналлары да язып чыга.

«Ватандашлар» циклында Галимҗан Барудига багышланган «Җәзага икеләтә тартылган» исемендә документаль фильм дөнья күрде. «Иман», «Хозур» нәшриятлары Баруди хезмәтләрен һәм аның турында булган язмаларны хәзерге татар графикасында һәрдаим нәшер итә. Киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итәр өчен Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте 2017 елны «Галимҗан Баруди елы» дип игълан иткән иде. Биектау районының 4 нче мәктәбенә дә әлеге олуг шәхеснең исеме бирелде. Шулай булгач ышана: тагын йөз, ике йөз елдан соң да Галимҗан Баруди исеме һаман яңгырар әле.

РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИН. БОЛГАНЧЫК ДӘВЕР МӨФТИЕ

Айдар Кәрибуллин

Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936) татар иҗтимагый фикере тарихында уникаль урын алып тора. Ул XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы яңарыш хәрәкәтендә мөһим фигура санала һәм тарихка күренекле тарихчы, педагог-мәгърифәтче, дин эшлеклесе, язучы буларак кереп кала.



Ризаэтдин Самара губернасы Бөгелмә өязенең Кичүчат (бүген – Татарстанның Әлмәт районы) авылында, нәсел җепләре борынгы Болгарга барып тоташкан мулла Фәхретдин Сәйфетдинов гаиләсендә туа. Шулай ук Риза Фәхретдиннең әтисе ягыннан бабасының туган ягында белем алганнан соң, Төркиягә киткәнлеге һәм Кара диңгез яры буендагы шәһәрләрнең берсендә губернатор дәрәҗәсенә кадәр үскәнлеге билгеле.

21 ЕЛ УКУ ҺӘМ МӘРҖАНИ БЕЛӘН ОЧРАШУ

1867 елда Фәхретдин Чистай мәдрәсәсендә белем ала, ике елдан соң әтисе аны Түбән Чыршылы авылындагы (бүген – Татарстанның Лениногорск районы) Абдулфәттах бине Абдулкаюм остазга укырга бирә. Бу авылда Ризаэтдин егерме елга якын яши. Шуның ун елы дәвамында ул белем ала, ә калганы дистә елында хәлфә ярдәмчесе буларак укытучылык итә.

Мәдрәсәдә Фәхретдин гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә һәм беренче мәртәбә Шиһабетдин Мәрҗани мирасы белән таныша. Аның карашлары Ризаэтдингә көчле йогынты ясый. 1886 елда Фәхретдин бөек галим белән танышырга һәм, форсат чыкса аралашырга дип, Казанга да килә. Кызганычка каршы, очрашу бик тиз була, алар берничә җөмлә белән генә аралашырга өлгерә...

Фәхретдиннең укуы 21 елга сузыла. Ул белемен бары тик Россиядәге мәдрәсәләрдә генә ала, шуңа да кара-

мастан чит ил мөселман галимнәренең идеяләрен, хезмәтләрен шактый яхшы өйрәнә. Ризаэтдиннең белем дәрәҗәсе һәм иҗади мөмкинлекләре турында әле шул вакытта ук чит ил журналларында (мәсәлән, «Әл-Манар») аның язмаларының еш басылуы да раслый.

1888 елда Фәхретдин Россия империясе башкаласы һәм шәрык белеме үзәге Санкт-Петербургка юнәлә. Биредә ул ике айга якын яши, күренекле дини реформатор Җамалетдин әл-Әфгани (1839–1897) белән таныша. Әлеге очрашу Ризаэтдиннең фикер сөрешенә шактый зур йогынты ясый.

«АСАР» ТАРИХИ ХЕЗМӘТЕНЕҢ ДӨНЬЯ КҮРҮЕ

1891 елның февралендә Риза Фәхретдин Уфага килә. Аны Оренбург Мәхкамәи шәргыя казые итеп сайлыйлар. Ул актив фәнни эшчәнлек алып бара, бер үк вакытта Мәхкамәи шәргыянең архивын өйрәнә, аны тәртипкә китерә. Әлеге бай фонд материаллары аның «Асар» фундаменталь тарихи хезмәтенең нигезенә салына. Хезмәт 1900-1908 елларда дөнья күрә. Шушы елларда «Сәлимә» һәм «Әсма» повестьлары языла: авторның игътибар үзәгендә – хатын-кызлар, ирләр белән хатын-кызларның тигез хокуклыгы мәсьәләләре.

Фәхретдин иҗатында шәхес тәрбияләү проблемалары, әхлак, эстетика мәсьәләләре зур урын алып тора. Моңа ул тулы бер китаплар сериясен багышлый.

ДИНИ РЕФОРМАЛАР ИДЕОЛОГЫ

1906 елда Фәхретдин татар сәнәгатьчеләре – бертуган Рәмиевләр чакыруы буенча Уфадан Оренбургка күченә. Аның фәнниагарту эшчәнлегенең иң уңышлы чоры башлана. Галим Оренбургта мөгаллимлек эшен дәвам итә һәм атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсен җитәкли башлый.

Оренбургта яшәвенең беренче ике елында Фәхретдин заманының танылган журналисты Фатыйх Кәрими җитәкләгән «Вакыт» газетасында мөхәррир урынбасары булып эшли, соңрак, 1918 елга кадәр, «Шура» журналында баш мөхәррир була. Әлеге басма битләрендә фәлсәфә, тарих, әдәбият һәм тел белеме, география, педагогика буенча язмалар басыла.

Нәкъ менә шул чорда Фәхретдин, Шиһабетдин Мәрҗани традицияләрен дәвам итеп, татарларда динне реформалау буенча төп идеологларның берсенә әверелә. Оренбургта эшләгән вакытта аның дини-теологик эчтәлеккә ия иң әһәмиятле хезмәтләре дөнья күрә. Дини-ислахчылык карашлары чагылыш тапкан әлеге хезмәтләр арасында «Җәвәмигъ әл-Каләм шәрхе» һәм «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» бар.

МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕНДӘ

1922 елда Ризаэтдин Фәхретдин Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк диния нәзарәтенә мөфти итеп сайлана. Үзенең фәнни тикшеренүләрен һәм тарихи «Асар» хезмәте буенча эшен дәвам итә. Күп кенә чыганакларны өйрәнеп, «Болгар тарихы» хезмәтен яза.

Мөфти буларак, Ризаэтдин Фәхретдин Россия мөселманнарының һәм дин эшлекләренең мәнфәгатьләрен актив яклый, мәчетләр каршында китапханә, архивларны саклауга ирешә. Аның тырышлыгы һәм үҗәтлеге нәтиҗәсендә мөселманнарының Үзәк диния нәзарәтендәге гаять бай архивы сакланып кала: Фәхретдин инициативасы буенча архивны 1935 елда дәүләт саклавына тапшыралар.

1926 елда Хиҗазда (Согуд Гарәбстаны) совет делегациясе җитәкчесе сыйфатында Ризаэтдин Фәхретдин мөселманнарның Беренче бөтендөнья конгрессында катнаша, шунда конгрессның вице-президенты итеп сайлана. Бу тагын бер мәртәбә галимнең ислам дөньясындагы югары абруен раслый.

Шул ук 1926 елда мөселманнарның Диния нәзарәте чираттагы съездын үткәрә, корылтайда Ризаэтдин Фәхретдинне яңадан мөфти итеп сайлыйлар. СССРда диннең киләчәктәге язмышы нинди буласын алдан ук сизеп, ул чордашлары булган дин эшлекләре турындагы мәгълүматны саклау юнәлешендә эш башлый. Кыска гына биографияләре язылган анкета тутырып җибәрүләрен сорап, барысына да циркулярлар юллый. 1932 елда кыйммәтле кульязма һәм китапларны архивка саклауга тапшыру максатында СССР Фәннәр академиясенә хат яза. Үз кульязмалары һәм хезмәтләренең бер өлешен академик Александр Самойлович үтенече буенча Ленинград Фәннәр академиясенә җибәрә.

Совет дәүләте тарафыннан дингә каршы алып барылган кырыс сәясәткә дә карамастан, Риза хәзрәт Фәхретдин хакимияткә лояль мөнәсәбәтен сакларга тырыша. Нәкъ менә шул позиция аңа вафатына кадәр мөселманнарның Диния нәзарәтен ябылудан саклап калырга булыша.

Ризаэтдин Фәхретдин 1936 елның 12 апрелендә 77 яшендә бакыйлыкка күчә, ул татар зиратында күмелгән.



Фото: zen.yandex.ru

МУСА БИГИЕВ.
ЯҢАРЫШ ТЕОРИЯСЕ ХАТЫЙБЫ



Айдар Хәйретдинов

Фәлсәфәче, җитди дини хезмәтләр авторы, бөтендөнья ислам форумнарында СССР мөселманнары вәкиле булган әлеге данлыклы шәхес гомеренең соңгы егерме елын горбәттә үткәрергә мәҗбүр ителә. Муса Бигиев – XX гасырның беренче яртысы татар һәм гомуммөселман дини-яңарыш теориясе вә практикасы күгендәге иң якты йолдыз ул.

Ул үзен иҗтимагый тормышның күп өлкәсендә таныта: Коръән-хафиз һәм Коръән гыйлеме остасы, дин тәгълиматчысы, шәригать белгече, дини фәлсәфәче һәм дин тарихчысы, мәгърифәтче, педагог, публицист, табигатьне өйрәнүче галим, әдип, татар милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, бастырылган берничә дистә хезмәт авторы.

АЛЛАҺНЫҢ РӘХМӘТЕ ЧИКСЕЗ

Муса Бигиев беркайчан да укудан туктамаучы кешеләр токымыннан була. Казан һәм Бохара мәдрәсәләрендә дини белем алгач, ул Истанбул, Каһирә, Дәмәшкъ, Бәйрутта һәм хәтта Британия Һиндстанында (Деобанд) белем эстәвен дәвам итә. Әмма үзенең беренче университетларын Муса өендә үтә – ул 1875 елда Ростов-на-Дону шәһәрендә дини татар гаиләсендә дөньяга килә.

1904 елдан 1930 елга кадәр Муса Бигиев Россиядә яши. Ул дини һәм гыйльми хезмәтләр язып бастыра, мөселман сәяси форумнары эшчәнлегендә катнаша, «Хөсәения» (Оренбург) мәдрәсәсендә укыта.

Фото: tatarica.org

Биредә ул Аллаһ рәхмәтенең чиксезлеге турында фикерләрен дөньяга тарата – милләтенә һәм диненә карамастан, тәмуг халкының барысы да ахыр чиктә һичшиксез оҗмахка эләгәчәк, дип игълан итә.

Үзенең хаклылыгын дәлилләүдә Бигиев урта гасыр суфилары мирасындагы шундый идеяләргә таяна, шулай ук Коръән аятьләрен мисалга китерә һәм аларны шул күзлектән чыгып шәрехли. Үз фикерләрен «Рәхмәте илаһийә борһаннары» («Аллаһының рәхмәтлелегенә дәлилләр») һәм «Инсанларның гакыйдәм илаһийәләренә бер нәзар» («Кешеләрнең дини ышануларына бер караш») китапларында аңлата.

МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕН УКЫТУ

Бигиев ислам цивилизациясе инкыйразы сәбәпләрен тарихи-социаль яссылыкта өйрәнә. Әлеге сәбәпләрне атап, һәркайсын тәнкыйтьли. Ислам хокукы системасындагы җитешсезлекләрне фаш итә, үз ислам юриспруденциясе системасының теоретик һәм практик аспектларын эшли. Мөселман мәгарифенең бик җитди кимчелекләрен күрсәтә һәм мөселман яшьләрен укытуның «дини һәм дөньяви фәннәрне» (куштырнаклар шуның белән аңлатыла – Бигиев өчен мондый бүленеш булмый) үз эченә алган принципиаль башка программасын тәкъдим итә.

Ул күпгасырлык теология доктриналары эчтәлеген яңача аңлата һәм күбесенең уйдырма булуын дәлилли – чөнки Коръән һәм хәдисләрнең эчтәлеген бозып аңлатучы теолог-схоластлар аларны җәмгыятькә һәм мөселманнарның коллектив аңына ирексезләп сеңдерә, нәтиҗәдә мөселман социумының акыл үсеше дә, рухи үсеше дә акрыная һәм бөтенләй туктап кала.

Һәр мәсьәләдә Бигиев проблеманы хәл итү буенча үз ысулларын тәкъдим итә. Борынгы авторитетлар фикеренә карап (тәкълид) эш итүче үз элгәрләреннән һәм замандаш мөселман теолог-динчеләрдән аермалы буларак, Бигиев абсолют иҗтиһад яклы була, ягъни мөселман, Коръәнгә, сөннәткә, гакылга һәм йөрәккә таянып, тормыштагы мөһим проблемаларны үзе хәл итәргә хокуклы, дип саный.

ПРОБЛЕМА ИСЛАМДА ТҮГЕЛ, БӘЛКИ МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ҮЗЕНДӘ

Бигиев иҗтиһад турында фикерләрен шулкадәр дөрескә саный ки, мөселман кешесе нинди изге, бәхәссез кабул итәргә күнеккән гамәлдәге Коръән тәфсирләрен мөселман дөньясының инкыйразга якынлашуы һәм көндәшлеккә сәләтсез булуы сәбәпләреннән берсе булып тора, дип белдерә.

Моннан тыш, Бигиев ислам тарихында беренче буларак хатын-кызлар проблемасына багышланган трактат яза, анда ул мәсьәләне лингвистика, мәдәният-тарих, социаль-фәлсәфә һәм дин ягыннан тикшерә. Галимнең моңа игътибар итүенең сәбәбе җәмгыятьнең цивилизацион халәте анда хатын-кызның нинди урын тотуына турыдан-туры бәйле, дип инануыннан килеп чыга.

Күп кенә замандаш дини интеллектуал-модернистлардан аермалы буларак, Бигиев мөселман дөньясының артта калуында исламны һич кенә дә гаепләми. Ул, проблема исламда түгел, бәлки мөселманнарның үзендә, дип белдерә, чөнки алар билгеле бер, шул исәптән объектив сәбәпләр аркасында исламны аңламый. Әлеге җәһәттән ул исламга һәм аның кыйммәтләренә карата Төркия Республикасы дәүләт эшлеклеләре сәясәтенә йогынты ясарга да маташа.

КӨНБАТЫШНЫҢ КӨНЕ САНАУЛЫ

Бигиевнең Көнбатыш казанышларына да мөнәсәбәте кызыклы: беренчедән, цивилизация казанышларына нииндидер уңай өлеш керткән һәркем мөселман (ягъни Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүче) булып чыга, дип, ул исламның мәгънәсен искиткеч киңәйтә. Икенчедән, ул Көнбатышның проблемаларын бик яхшы аңлый һәм иртәме-соңмы гакыллы кешелек аңлы рәвештә исламның гади, ачык, гадел һәм нәтиҗәле принципларына һәм тормыш кагыйдәләренә өстенлек бирәчәк, дип фаразлый.

1930 елдан 1949 елда вафатына кадәр Бигиев мөһаҗирлектә яши, күп сәяхәт итә, гарәпчә хезмәтләр яза. Гомеренең соңгы елында үзенең төп хезмәте – Коръәннең төрекчәгә тәрҗемәсен бастырып чыгарырга тагын бер талпынып карый. Коръәнне татар-госманлы теленә ул 1912 елда ук тәрҗемә итә, әмма фанатик кадимче муллалар әлеге хезмәтен Россиядә бастырып чыгаруга комачаулый.

1948 ел азагында үз тәрҗемәсе өчен Коръәннең гарәпчә текстын җыю максатыннан ул Истанбулдан Каһирәгә күченә, әмма инде гомере бик аз калган була: ниятен тормышка ашырырга өлгерми. Муса Җаруллаһ Бигиев 1949 елның 24 октябрендә бакыйлыкка күчә, һәм зур хөрмәт белән Мисыр хакимнәре күмелгән комплекста – Афифи территориясендә җирләнә.

PRESSA

ХАКЫЙКАТЬКӘ ХОКУК БИРГӘН ДИПЛОМ

Олеся Бондаревская

Татарстан дини традицияләрне дәвам итүне яңадан торгыза. Бөек Болгарның нәкъ үзәгендә төп миссиясе илебездәге мөселман өммәтенең кадрлар һәм интеллектуаль элитасын әзерләүдән гыйбарәт булган академия урнашкан.

2000 нче еллар башында Татарстаннан бер яшь галим-тел белгече кадрлар алмашу программасы буенча стажировка үтәргә АКШка юл тота. Проектта катнашучы россиялеләрне төрле штатларга бүләләр, анда кунаклар университетларда белем ала, курслар алып бара, америкалыларның көнкүреше һәм үсешкә омтылган чит ил белгечләре өчен бу дәүләтнең мөмкинлекләре белән таныша.

Беркөнне ул АКШта уку, аспирантурада белем алу шартлары турында сөйләшергә дип Америкадагы танышларына чәйгә бара. Тик нниндидер бер протестантлык агымы тарафдары булып чыккан танышлары егетне үз диннәренә кабул итүнең театральләштерелгән тамашасын оештырган булып чыга. Аның мөселман булуы турында ишетәселәре дә килми. Егет качып китәргә җай таба. Танышлары соңыннан гафу үтенә. Яктащыбыз үз юлыннан тайпылмый. Ул җирле халык белән аралашуны татар телен һәм мәдәниятен пропагандалау өчен файдалана, шул рәвешле үз иленең мәнфәгатьләрен яклый. Хәтта яңа танышларын туган авылына үзенең туена да чакыра. Саба районына килгәч кенә, кунаклар егетның үз милли традицияләренә тугрылыгын бәяләп бетермәүләрен аңлый башлый кебек.

Язмабыз герое **Айнур Тимерханов** лингвистика юнәлешендә берничә, шул исәптән чит илдә дә белем алып, егерме елга якын инглиз теле укыта, гарәп теле дәресләре алып бара, Татарстанда америкалыларга, кытайларга тел өйрәтә, Россия һәм Американың югары уку йортларында лекцияләр укый. Россиядә ислам фәннәре докторларын әзерли торган бердәнбер югары уку йорты – Болгар ислам академиясе ректоры вазыйфасында галим төрле илләр, төрле дөньяви караш, төрле инану, төрле конфессия вәкилләре белән аралашу нәтиҗәсендә тупланган искиткеч бай тәҗрибәсенә таяна.

Фото: Александр Ефремов

КОРЪӘН АЧКЫЧЫ

– Мин Татарстанны шулкадәр матур урын дип уйламаган идем, – ди **гарәп теле укытучысы, Сүриядән килгән Әхмәд Шәех-Мостафа**. Академия турында ул моннан зур тәэсирләр белән кайткан коллегаларыннан белеп ала. Аңа бөтенләй ят озын кышны санамаганда, Шәех-Мостафага монда барысы да бик ошый. Бигрәк тә республиканың милли телләр һәм мәдәниятләрне саклау юнәлешендә максатчан эшчәнлегенә игътибарын җәлеп итә. Бик сирәк төбәкләр генә үзләренең милли үзенчәлекләрен саклап калу өчен шулкадәр көч куя, дип саный мөгаллим.

Күпмедер дәрәҗәдә бу Шәех-Мостафага эшендә ярдәм дә итә. Гарәп теле – Коръән ачкычы ул, аннан башка ислам нигезләрен аңлау мөмкин түгел. Ә төрки тел мохите гарәп телен аңлауны җиңеләйтә. Бу – академиядә белем алуның беренче баскычы. Өч еллык магистратура һәм тагын өч еллык докторантурада академия укучылары сөнни догматиканы, Коръән һәм хәдис гыйлемнәрен, исламның гыйбадәт тәртипләрен, ислам тарихын, ислам хокукы һәм фәнни-дини тикшеренүләр методологиясен һәм башка фәннәрне өйрәнә. Чыгарылыш эшләрен дә алар гарәп телендә әзерли һәм яклый. Бу – принципиаль таләп: академия халыкара ислам фәне һәм мәгарифе мохитендә лаеклы урын алырга омтыла.

– Яңа кагыйдәләр буенча докторантура тәмамлаучыларның эшләре экспертлар тарафыннан берничә этапта тикшерү уза. Шуннан соң гына кандидатларга диссертация советы каршында яклауга рөхсәт бирелә. Россия өчен бу – уникаль күренеш. Илебезнең башка уку йортлары ислам фәннәре өлкәсендә белгечләр әзерләүнең мондый югары дәрәҗәсе белән мактана алмый, – ди **фәнни эшчәнлек буенча проректор Руслан Сәяхов**. – Ләкин безнең өчен дәвамчанлык гаять мөһим. Ул уку йортларыннан килгән көчле студентлар, чит илгә китмичә, белем туплауны бездә дәвам итә ала.

Шул ук вакытта гарәп теле милли хәзинәбез – татар, төрки һәм илебездәге башка дин галимнәренең дини һәм фәнни текстларын өйрәнүгә дә ишек ача.

ЯҢА ИСЕМНӘР МӨНБӘРЕ

– Бездән еш кына: «Академия кайчан яңа Мәрҗанилар үстереп чыгара инде?» – дип сорыйлар. Чөнки белгечләребезне әзерләүгә бик күп көч һәм акча сарыф ителә бит. Мин: «3–4 ел эчендә фән күген яктыртырлык йолдыз галим үстерергә мөмкинме?» – дигән сорау белән җавап бирәм. Минемчә, бу хыял берничә буыннан соң гына чынга ашачак. Академия үзенең аякка басу һәм үсеш юлын узарга тиеш.

– Мин Татарстанны шулкадәр матур урын дип уйламаган идем, – ди гарәп теле укытучысы, сүрияле Әхмәд Шәех-Мостафа.

– Илебезнең башка уку йортлары ислам фәннәре өлкәсендә белгечләр әзерләүнең мондый югары дәрәҗәсе белән мактана алмый,– ди фәнни эшчәнлек буенча проректор Руслан Сәяхов.



Яхшы белем алу гына түгел, ә менә шушы традицияләрдә тәрбияләнеп үскән, бу мохит һавасын сулаган кешеләр генә алдынгы, оригиналь фикер йөртү сәләтенә ия дин белгечләре була ала, – ди Руслан Сәяхов.

Татар-башкорт төбәгенең, Россия, Кавказ ягының, Казахстан, Үзбәкстан, Таҗикстанның дини мирасын өйрәнү – студентларның фәнни-тикшеренү эшләрендә мәҗбүри юнәлеш. Чыгарылыш эшләрнең 60%ы диярлек шушы темаларга багышланган.

– Кулыбызда фарсы, гарәп, төрки, иске татар телләрендәге XVIII гасыр – XIX гасыр башларына караган, бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек биниһая зур материал катламы бар. Академиядә без әлеге фәнни хезмәтләрдәге фикерләрне тәфсирләргә, галимнәрнең нәрсә турында язганын аңларга тырышабыз. Чит илләрдәге коллегаларыбыз бу хезмәтләр бик тирән эчтәлекле һәм үзенчәлекле дигән фикердә. Без бу хакта бөтен дөньяга сөйләргә телибез, – ди Руслан Сәяхов. – Әлеге максатларда дөньяви югары уку йортлары белән элемтәләрне дә җайга салырга тырышабыз. Хәзерге вакытта кулъязмаларны өйрәнү өчен, академиянең Ислам мирасы үзәге базасында Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты белән бергә фәнни-тикшеренү лабораториясе оештыру турында сөйләшүләр алып барабыз.

Бу эш Курсави, Мәрҗани, Баруди һәм башка шундый дәрәҗәдәге яңа галимнәрне дөньяга ачарга мөмкин. Академиягә Иорданиядән килгән күренекле галим Сәед Фуда академия фондында үзенә билгеле булмаган авторның кулъязмасын тапкач, шаккатып, бик сөенгән иде. Әлбәттә, академиядә тупланган кулъязмаларның бай коллекциясен әле җентекләп өйрәнергә кирәк. Әмма мондый кулъязмаларның саклануы, дөньяда булуы факты – үзе үк ачыш.

НӘСЕЛДӘН КИЛГӘН МЕНТАЛИТЕТ

Дөрес, беренче карашка, бу эш махсус белгечләр генә шөгыльләнә торган тар юнәлеш кебек тоела. Йөз, ике йөз ел элек язылган хезмәтләрне өйрәнүгә нигә шулкадәр тырышырга, чыгымнар тотарга кирәк соң?

– XX гасырда илебездә хасил булган рухи бушлык хәзер бик тиз тулып бара. Тик аны дөрес тутырырга кирәк, – дип аңлата Руслан Сәяхов. – Без дә, мөгаен, ата-бабаларыбызга хас менталитет вәкилләредер. Аларның исламны ни рәвешле аңлавын, ничек кабул итүен никадәр тизрәк ачыкласак, үз урыныбызны, юнәлешебезне дә шулкадәр тизрәк билгеләячәкбез.

Бушлыкны дөрес тутыру, ягъни төбәгебез һәм илебезнең ислам тарафдарлары яшәгән республикалары өчен традицион исламны торгызу, аны Россия, Татарстан мөселманнары арасында тарату темасы – академия өчен беренчел әһәмияткә ия. Бу эштә илебез белгечләренә дә, без алга сөргән кыйммәтләрне югары бәяләүче чит ил мөгаллимнәренә дә зур роль бирелә. Әлеге юнәлештә академия традицион

Профессор, әл-Әзһәр университетының шәригать факультеты укытучысы, шәех Әдһәм Таммам Фәрраж секталарның нидә ялгышуын, аять тәфсирләрен бозуын, җәмгыятькә нинди зарарлы йогынты ясавын аңлата.

ислам фикере үзәкләре – әл-Әзһәр университеты (Мисыр), Димәшкъ университеты (Сүрия) һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Марокко, Йәмән, Иордания кебек илләрнең алдынгы ислам югары уку йортлары белән актив хезмәттәшлек итә.

– Без билгеле бер җирлеккә караган сорауларны тикшерәбез, әйтик, Россия законнары һәм шәригатьнең аерылышу очракларына мөнәсәбәте; яки Мәрҗани дә шөгыльләнгән мәсьәлә – ястү намазы вакытын билгеләү; яисә кешегә имплантатлар куллану рөхсәт ителәме-юкмы икәнлеге, – дип сөйли **әл-Әзһәр университетының шәригать факультеты профессоры, шәех Әдһәм Таммам Фәрраж**. Аның җитәкчелегендә студентлар фикъһе фәнен, шул исәптән заманча ислам хокукын өйрәнәләр. Ул тышкы сәяси тотрыксызлык шартларында бик мөһим предмет – исламдагы агым һәм төркемнәр турында да укыта. Шәех секталарның нидә ялгышуын, адашуын, аять тәфсирләрен ничек бозуын, җәмгыятькә нинди зарарлы йогынты ясавын аңлата.

БАШКАЛАРГА ЮЛ ЯКТЫРТУ

– Хәзер шактый четерекле чор, шуңа күрә без үз ватаныңны сөю кебек темаларга да фикер алышабыз. Студентларыбыз – солдатлар кебек, алар үз өлкәләрендә ватаннарын экстремизм һәм террорчылык кебек куркынычлардан саклый белергә тиеш, – ди шәех.

Аның күбесе – Россия төбәкләренең диния нәзарәтләре хезмәткәрләре яки гамәлдәге имамнар, ягъни мәхәллә халкының борчумәшәкатьләре, ихтыяҗлары турында иң күп белгән кешеләр.

– Мондый белем бик кирәк. Без бит психолог та, педагог та, бер яктан караганда, хәтта тәртип сакчылары да. Эшебезне дөрес алып бару өчен, һөнәри квалификацияне гел тиешле югарылыкта тотарга кирәк.

Дөнья даими үзгәрештә, без ул яңалыкларны ислам күзлегеннән аңлата белергә тиеш. Мәсәлән, менә коронавирус белән бәйле бер сорау. Бу чирдән үлгән кешенең җәсәден ничек юарга? Аңа кагылырга ярыймы? Аны кәфенгә төрергәме? Фикъһе китапларында бу хакта әйтелми бит, – ди **Яшел Үзән (Татарстан) Җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Гатауллин**. – Мин кешеләрнең рухи ярдәмгә бик мохтаҗ булуын күрәм. Минем яныма кайчак аерылышырга теләгән яшь парлар килә. Без вазгыятьне тикшерә башлыйбыз, һәм нәтиҗәдә аларның Коръәндә ир белән хатынга йөкләнгән бурычлар турында укымаганлыгы яки бу бурычларны үтәмәгәнлеге ачыклана. Күпләр этисез үскән – ата кеше йә үлгән, йә гаиләдән киткән. Ә бит ислам безгә андый афәттән котылу өчен бөтен мөмкинлекләрне бирә. Академиядә алган белемнәрдән, хакыйкатькә якынлыктан илһамланам. Аннары,



– Академиядә алган белемнәрдән, хакыйкатькә якынлыктан илһамланам. Аннары, мәхәлләмә кайткач, мин шушы гыйлем нурын халыкка тарата алам, – ди Яшел Үзән Җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Гатауллин.

– Бу белем миңа туган ягыма кайткач ислам динен үстерергә-җәелдерергә ярдәм итәчәк, – ди магистратураның 2 нче курс студенты Йосыф Корбанов.

мәхәлләмә кайткач, мин шушы гыйлем нурын халыкка тарата алам.

– Дагыстанда исламны балачактан ук өйрәнәләр. Бүген аның өлкәннәрне хөрмәт итү, кечкенәләрне яклау, югары әхлак, чит кешенең кайгы-хәсрәтен уртаклаша белү кебек кыйммәтләре бик мөһим. Бирегә укырга китәр алдыннан, эти-әнидән рөхсәт сорадым. Алар китүемә каршы килмәде, һәм мин моңа бик шат, чөнки аларның хәер-фатихасы белән уку да җиңел һәм кызыклы. Бу белем миңа туган илемә кайткач ислам динен үстерергә-җәелдерергә ярдәм итәчәк, – ди **Дагыстаннан килеп магистратураның 2 нче курсында укучы Йосыф Корбанов**. – Хәзер мин Дагыстанның танылган галиме һәм хокук белгече Хәсән Әлкадәри мирасын өйрәнәм. Ул мантыйк, математика, гарәп теле фәннәре белән шөгыльләнгән, шигырьләр язган, дворян статусына ия булган. Тамбов губернасында сөргендә чакта Әлкадәри татар галимнәре һәм дин әһелләре белән бик күп аралашкан, бу хакта истәлекләр китабы язган. Кайткач, туган авылында мәктәп ачып, ул үзе дә шунда укыткан. Мине аның бер кеше гомере өчен дип караганда гаҗәеп бай тәҗрибәсе илһамландыра. Әлкадәри хезмәтләре турында күп дөньяви эшләр язылган, әмма дини юнәлештәге тикшеренүләр юк диярлек. Минеке шундыйларның берсе булачак.

Йосыфның якташы, академиянең дини-гуманитар фәннәр кафедрасының өлкән методисты Мөхәммәд Шаһрединов биредә ислам фәннәре өлкәсендә магистр дәрәҗәсен ала һәм укуын докторантурада дәвам итә.

– Монда укырга кереп, төрле шәһәр, төбәк, илләрдән килгән кешеләр белән танышкач, үзем өчен тулы бер дөнья ачтым. Минем белән Таҗикстан, Үзбәкстан, Казахстан, Кыргызстан, Ингушетия, Чечня студентлары укыды. Мин бу төбәк һәм илләрнең мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре турында бик күп нәрсә белдем, – ди Мөхәммәд Шаһрединов. – Ә Россиядән читкә чыкмыйча, диссертация яклап, ислам фәннәре докторы дәрәҗәсен алу мөмкинлеге – чыннан да уникаль форсат. Теләк булганда һәм, әлбәттә, беркадәр тырышлык куйганда, теология буенча магистрлык дипломы да алырга мөмкин. Нәтиҗәдә бик зур өстенлек – дини һәм дөньяви белем турында берьюлы ике дипломга ия була аласың. Академияне тәмамлаучыларның күбесенә бу өстенлек эшкә урнашканда бик булыша.

ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘДӘГЕ БИШ ЕЛ

Быел Болгар ислам академиясе үзенең беренче юбилеен билгеләп үтә. Югары уку йорты өчен бу әле бик гыйска гомер. Әмма Айнур Тимерханов сүзләренә караганда, киләчәктәге казанышларга инде нигез салынган. Ислам мәгарифе өлкәсендә ислам фәннәре докторларының Россиядә беренче ике чыгарылышы булды. Бу белгечләр дини учреждениеләр системасында, дәүләт структураларында, дини һәм дөньяви югары уку йортларында эшли.

– Академиядә белем алу дәрәҗәле, популяр була бара, аның белән кызыксыну арта. Биредә киләчәктә зур абруй һәм йогынтыга ия булачак кешеләр укый, – ди Айнур Тимерханов. – Алар үз белемнәрен башкаларга тапшырачак, һәм шул рәвешле эшебезнең нәтиҗәлелеге үсәчәк. Россиядә ислам мәгарифе системасының барлык баскычлары да, ә шуның белән бергә аның иң югары баскычы – Болгар ислам академиясе дә ныклы үсеш ала, дип өметләнәм.



ИСЛАМ ЭСТЕТИКАСЫ

Ольга Туманская

Ислам мәдәниятендә «сәнгать» төшенчәсенең үзенә бер мәгънәсе бар. Юк, бу рәссамның үзенең иҗади потенциалын күрсәтүе генә түгел, бу аның дөньяны танып-белүе дә. Анда осталык һәм иҗат, һөнәр һәм белем бар.

ТАНЫП БЕЛҮ ОСТАЛЫГЫ

– Икесе дә бер үк нәрсә түгелмени болар? – дип ихластан гаҗәпләнәм мин

– Шулай да, юк та. Менә... сөтле каһвәне күз алдына китерегез әле! – дип гади кешегә дә аңлаешлы образларда аңлата ислам сәнгате белән мөселман сәнгате арасындагы үзара бәйләнеш һәм аерманы **сәнгать фәннәре докторы, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова.** – Биредә нинди дер кушылу турында сөйләп булмый. Югары ислам (дини) сәнгате һәм синкретик мөселман сәнгате (дөньяви, әмма ислам эстетикасы кануннарында) бар. Кеше, мөселман, каһвә кебек – ул баштан ук дөньяда бар, һәм ул сөт – исламны кабул итә. Хәзер инде аларны аерып булмый.

Классик гарәп телендә рәссам һөнәрен аңлаткан сүз юк, дип сөйли Гүзәл Фуад кызы. Әмма «сәни» сүзе бар, ул «куллары белән эшләүче кеше, үз хезмәтендә һөнәр һәм иҗатны куллан учы кеше» дип тәрҗемә ителә. Мөселман рәссамы өчен сәнгать – сәләт түгел, бәлки тырышып үзләштерелергә тиешле белем ул. Менә шуңа күрә дә аларның күбесе аноним иҗат иткән, чөнки үзеңне танып белү алар аңлавында данга бәйле булмаган.

Ислам традициясе фаразлавынча, чынбарлыктан күчермә алып булмый, чөнки аны Аллаһы Тәгалә яраткан. Һәм аны Аллаһы Тәгалә яратканнан яхшырак итеп булмый, бары тик танып белергә, уйланырга һәм үз белемеңне ниндидер махсус символик тел – бизәк, орнамент, каллиграфия аша чагылдырырга була...

Фотолар Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова архивыннан

БИЗӘК ТЕЛЕНДӘ

Бу гүзәлнең чәчен – калфак, муенын – муенса, кулын балдак бизи. Артында кояш чыгып килә. «Көзге каршындагы татар кызы» рәсеме күзне иркәли һәм, аклы-каралы гына булса да, нигәдер бик җете төсле тоела. Аның авторы – Строганов училищесында белем алган, татар хатын-кызлары арасында беренче профессиональ рәссам Хәдичә Акчурина.

Рәсем беренче тапкыр 1915 елда «Аң» журналында басыла һәм прогрессив татар тамашачыларын сокландырып кына калмый, консерватив дин әһелләренең тәнкыйтенә дә дучар була, чөнки мөселман сәнгатендә Аллаһны гына түгел, кешене дә сурәтләү күп гасырлар буена тыела. Пәйгамбәр (с.г.в.) нең сурәте шигыйләрнең миниатюраларында сирәк кенә очраштыргалый, ул аларда да һәрвакыт йөзен каплап һәм алтын нур белән сурәтләнә.

– Кешене һәм җан ияләрен сурәтләү Коръәндә турыдан-туры тыелмый, – дип аңлата Гүзәл Фуад кызы. – Әмма әлеге тыю Пәйгамбәребез (с.г.в.) нең әйткән сүзләре һәм кылган гамәлләре теркәлгән хәдисләрдән аңлашыла. Бу тыю мәҗүсилеккә, потларга табынуга каршы көрәш сыйфатында гаммәви дини аңга сеңдерелгән.

Исламда җан ияләрен сурәтләү Аллаһка охшарга тырышу буларак кабул ителгән. Әмма исламга кадәрге чор болгар сәнгатендә хайван һәм кош образлары шактый еш очрый. Аларның кайберләре бик озын гомерле булып чыга һәм татар бизәкләрендә безнең көннәргә кадәр килеп җитә. Мәсәлән, каз яисә үрдәк сурәтләре. Соңгысының болгар чигә асма бизәгенә күчүе дә мәгълүм. Бәхеткә, зәркән сәнгатенең әлеге җәүһәрләре Эрмитаж, Мәскәүдәге Тарих музее һәм ТР Милли музеендагы археология коллекцияләрендә сакланып калган. Бүген исә кош мотивларын без хәзерге татар авылларындагы йортларның тәрәзә йөзлекләрендә күрә алабыз. Әлеге образлар күп гасырлар дәвамында ничек сакланып калган соң?

– Чөнки алар миф һәм әкиятләр белән бәйле, – дип җавап бирә бу сорауга Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Дөнья яратылу турында риваятьне хәтерләсәгез, анда үрдәк дәрья төбенә чумып, томшыгында туфрак алып чыга, шул рәвешле коры җир барлыкка килә. Алай гына да түгел, мифлар кеше аңында генеалогия, димәк, нәсел тотемнары белән дә бәйле була. Һәркем үз тотемын белә, соңрак бу тамгаларда үз чагылышын таба.

Әмма вакыт үтү белән татарларда нәсел элгәрләрен хөрмәтләү культурасы юкка чыга. Ул күп очракта күчмә халык традицияләренә һәм нәсел-ыру җырларенә бәйле була, тик боларның барысын да шәһәр цивилизациясе кысрыклап чыгара, һәм исламны кабул итү бу очракта мөһим роль уйный, чөнки ул нәкъ менә калаларда гөрләп үсә бит. Әйе, нәкъ менә шәһәрләрдә югары ислам мәдәнияте формалаша – мәчетләрдә һәм мәдрәсәләрдә. Әкренләп, әлеге мәдәният йогынтысында, нәфис әдәбият телендә үзгәрешләр барлыкка килә – чынбарлыктагы образлар шартлысына алыштырыла, шул рәвешле бизәк сәнгатьтә төп сурәтләү чарасына әйләнә.

– Ул Идел болгарлары матди мәдәниятенең барлык төрендә диярлек кулланылачак, – дип сөйли Гүзәл Фуад кызы. – Һәм зооморф, үсемлекләр, геометрик һәм эпиграфик (хәрефле) мотивлардан гыйбарәт булачак. XVIII–XIX гасырларда сурәтләрнең схемалылыгы, үзен христианнарның икона язуларына каршы куеп, көчәячәк кенә.

«Көзге каршындагы татар кызы» рәсеме беренче тапкыр 1915 елда «Аң» журналында басыла. Аның авторы – Строганов училищесында белем алган, татар хатын-кызлары арасында беренче профессиональ рәссам Хәдичә Акчурина.

Кош мотивларын без хәзерге татар авылларындагы йортларның тәрәзә йөзлекләрендә күрә алабыз.

Үрдәк сурәте чагылыш тапкан болгар чигә асма бизәге.

«Аллаһ гүзәл һәм гүзәллекне ярата» шәмаиле. Авторы – Бакый Урманче.

«Кәгъбә» картинасы. Рәссам Вәкил Шәйхетдинов эше.

Манаков йорты (Казан ш., Мәскәү ур., 42) фасады бизәлешендә кулланылган милли татар бизәкләре.

Ихтимал, каллиграфияне исламга хас үзенчәлекле сәнгать төрләренең берсе дип атарга буладыр, дип сөйли безнең экспертыбыз. Аны рәссамга бирелгән үзенә бертөрле талант, дип бәялиләр. Изге Коръән аятьләрен, Аллаһ Тәгаләнең һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.) нең, гадел хәлифәләрнең исемнәрен кулъязмаларда язалар, диварларга уялар, кабер ташлары, тукыма һәм келәмнәр, керамика һәм металл эшләнмәләр бизәкләренә кушып үрәләр...

Һәм, әлбәттә инде, шәмаилләр! Аларны хаклы рәвештә ислам сәнгатенең феномены дип атыйлар. Гадәттә Коръән аятьләре язылган панно майлы буяулар белән пыялага төшерелә, кәгазьгә языла, тукымага чигелә, литография ысулы белән бастырыла... Тексттан тыш, анда мәчет сурәтен дә очратырга була. Шуны билгеләп үтү зарур: нәкъ менә татарларда әлеге сәнгать беркайчан да юкка чыкмый. Дин эзәрлекләнгән совет чорында да шәмаил сәнгате авылларда сакланып кала. Аларда еш кына Коръән текстлары татар халык мәкаль һәм әйтемнәренә, Тукай шигырьләренә алыштырыла. Сирәк кенә рәсемле шәмаилләр дә очраштыргалый! Аларның барысын да үзлегеннән өйрәнгән осталар ясый. Ислам сәнгатенең әлеге төрен торгыза алган профессиональ шәмаил осталары исә Татарстанда узган гасырның 90 нчы елларында гына пәйда була.

АВАНГАРДТА

«Безгә үзебезнең тормышны сурәтләгән картиналар язарлык рәссамнар кирәк», – дип хафаланган Габдулла Тукай. Җәдидчелек – ислам мәгърифәтчелек модернизмы, мөселманнарның реформаторлык хәрәкәте дәвере житә. Дөньяви Европа сәнгате гөрләп үсә башлый – аның скульптура, сынлы сәнгать, графика кебек төрләре пәйда була. Шулай ук газета һәм журналларда чынбарлыкны чагылдырган иллюстрацияләр басыла башлый. Бу урында Хәдичә Акчуринаның «Көзге каршындагы татар кызы» рәсемен кабат искә алыйк.

– Билгеле, болар барысы да әкренләп гамәлгә керә, – дип сөйли Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Баштарак әлеге эшләрдә реализм шактый шартлы була. Кайбер сурәтләрдә кешеләр, ниндидер сюжетлы күренешләр чамалана. Тәүге татар рәссамнары үз хезмәтләрендә Идел-Урал төбәге мөселманнарының тормышын милли элементлар кертеп чагылдырырга тырыша. Аларда – халык иҗаты традицияләре, шуңа хас төсләр гаммасы, әлеге әсәрләрне мөселман сәнгатенә кертерлек шартлы тел саклана.

Революциядән соң ислам мәдәнияте тыела. Шулай булса да, ул, су ташлар арасыннан юлын тапкан шикелле, бөтен тыюлар аша барыбер үтеп чыга ала һәм совет чоры сәнгатендә теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш таба. Бу модернизм һәм югары татар сәнгате туу вакыты була, анда мөселман традицияләре ислам сәнгатенә хас образлылык һәм символизм, яссы композиция, төсләр, кайвакыт исә каллиграфия аша да гәүдәләндерелә. Без боларның барысын да 1920 нче еллардагы татар графикасында күрә алабыз.

Әлеге алымнар егерменче елларда Маяковский җитәкләгән яңа революцион иҗат берлеге – «Левый фронт искусств» (ЛЕФ) нигезенә салына. Авангард, конструктивизм – сәнгатьтәге татар рәссамнары үзләренең кабатланмас шәркый өслүбендә иҗат итә алган прогрессив юнәлешләр. Әлеге өслүб исә күп гасырлар буе ислам мәдәнияте йогынтысында формалаша. Һәм менә безнең каршыбызда ул вакытлар өчен новаторлык булган Бакый Урманче иҗаты, Шакир Мөхәммәтҗановның китап графикасы, Фаик Таһиров плакатлары...

Бүген ислам традицияләрен Казандагы Әлфия Ильясова, Рөстәм Шәмсутов кебек модернистларның һәм үз картиналарында ислам мифологиясе образларын актив файдаланучы башка күп рәссамнарның әсәрләрендә очратырга була.

МУЗЫКА ГАСЫРЛАРНЫ ТОТАШТЫРА

Борынгы тәнбур бик заманча да яңгырый ала икән. Һәрхәлдә, Алмаз Әсхәдуллин кулында ул әйтерсең лә җанлана, безнең заман белән урта гасырларны тоташтыра торган күпергә әйләнә. Алмаз – Идел буендагы борынгы музыкаль-инструменталь сәнгатьне торгызу ниятеннән оештырылган «Алпар» этно-төркеменнән. Тәнбурдан тыш, алар арсеналында башка төрки уен кораллары – думбра, курай, кубыз, дәф тә бар. Егетләр борынгы көйләрне заманча аранжировкалар белән бизи, һәм мәдәни мирасны болай үзгәртеп яңгырату бик мавыктыргыч килеп чыга.

– Идел буенда ислам кабул ителү төбәгебезгә күп яңалык, шул исәптән шәрык поэзиясен дә алып килә. Шигърият булган җирдә исә һичшиксез музыка да була, – дип минем ислам музыкасы мәдәнияте белән танышуымны дәвам иттерә Геннадий Макаров. Ул музыка белгече-фольклорчы, Казан консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы педагогы гына түгел, традицион уен коралларын ясаучы оста һәм аларда уйнаучы буларак та танылган шәхес.

Күп төрки халыклар өчен мәдәнияттә мода чыгаручы булып Бохара саналган. Яшьләр анда укырга киткән, аннары туган якларына кайтып әлеге белемне файдаланган. Урта гасырлар әдәбияты безнең өчен шул вакыттагы мәдәни тормыш энциклопедиясе булып тора – без аларны өйрәнеп ул чактагы шигырь язу системасы, көйләр ритмы һәм җирле музыка уен кораллары хакында белә алабыз. Әлбәттә инде, гармун яки фортепиано түгел, ә бәлки думбра, курай, дәф булган алар...

– Шигърият ритмнары аеруча нык булып чыккан һәм халыкта хәзергә кадәр сакланган, – дип сөйли Геннадий Макаров. – Инде 40 елдан артык авыллар буйлап экспедициядә йөрим һәм әлеге әсәрләрне – касыйдә, газәл, робагый, мөнәҗәт, бәетләрне язып алам. Музыкаль-поэтик сәнгатьнең

«Җимеш өзүче Мәрьям» картинасы. Рәссам-модернист Әлфия Ильясова эше.

Музыка белгече-фольклорчы Геннадий Макаров 1994 елда ясалган тәнбур музыка уен коралында уйный.

барлык бу жанрлары халык шигърияте һәм борынгы музыкаль традицияләр нигезендә ислам йогынтысында формалашкан.

Шунысы гаҗәп: совет чорында бөтенләй игътибар бирелмәгән нәрсәләр халыкта яңа идеология белән параллель рәвештә яши алган. Татар мәдәниятен өйрәнүчеләр мәгълүм сәбәпләр аркасында дини поэзия феноменына кагылмаска тырышкан. Шулай булса да, язып алган. Нәкъ менә шуңа күрә безнең әбекәйләребезнең җырлары күп институтларның тавыш архивларында сакланып калган.

Әлеге әсәрләргә нәрсә хас соң? Алар шәркый ритмнарда көйләп башкарыла һәм аларда татар этник җырларына хас мелизмнар юк. Башкаручыга билгеле бер метрик үлчәмне саклау мөһим. Текстлар нигезендә үгет-нәсихәтләр, пәйгамбәрләр тормышыннан сюжетлар ята. Шулай да, мөселман музыкасы эталоны юк, ди Геннадий Михайлович. Шунлыктан еш кына төрекләр, татар музыкасын тыңлаганда: «Бу бит кытай көеме?» – дип сорый.

Җәдидчелек пәйда булу җирле мөселманнар мәдәниятендә дә чагылыш тапкан. Суфилар Идел буенда тамыр җәйгән Урта Азия традицияләрен саклауны дәвам итсә, Европа яңалыкларына каршы булса, җәдидче реформаторлар «яңару» яклы булган. Татар мәдәниятенең яңа катламы туа. Музыканың сәхнә варианты пәйда була, дини канунннардан читләшү омтылышы сизелә. Мелизмнар белән җырлау өслүбе ныгый, бүген без моны «Кара урман» яки «Тәфтиләү» кебек җырларда ишетә алабыз. Скрипкалы, мандолиналы, гармоникалы яңа татар музыка сәнгате пәйда була – һәм бу инде бөтенләй башка музыка дәверенең башы булып тора. Дини поэзияне башкаруның борынгы традицияләре исә җуела торган сәнгать сыйфатында көнкүрештә барлык бу еллар буе сакланып кала.

– Бүген күп кешедә әлеге шәрык поэзиясенә бәйле урта гасырлар мәдәниятен, аның ритм һәм көйләрен торгызу теләге бар, – дип сөйли Геннадий Макаров. – Фольклор экспедицияләр нәтиҗәләре һәм борынгы китаплар буенча мин думбра, тәнбур, шөлдерле барабан, дәфне ясарга өйрәндем. Моны бөтен кеше аңламый, билгеле. «Безгә нәрсәгә кирәк бу? – диләр. – Әйдә, үзебезчә, гармунда уйныйк!» Шулай да, бүген бу юнәлеш заманча этномәдәни хәрәкәттә зур урын алып тора.

Идел буе мөселманнарының борынгы сәнгате үрнәкләре белән Казандагы «Бәрәкәт» фольклор ансамбле (аның илһамчысы Геннадий Михайлович), Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының «Җомга көн» ансамбле, һәм, әлбәттә инде, экспериментлар ятучы «Алпар» этнотөркеме концертларында хозурланып була.

«БЕЗГӘ РУХИ ЯКЫНРАК»

«Кирпеч фасадлар силуэтында Казан Кирмәненең ак таш диварлары образы гына түгел, бер үк вакытта суфичылык фәлсәфәсе дә, формалар төгәллегенә омтылган совет модернизмы эстетикасы да яшеренгән. Бу турыдан-туры өземтә китерү түгел, бәлки тикшеренүгә өндәү...»

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры яңа бинасының үз концепциясен Bespoke җитәкчелегендәге консорциумда катнашучылар шулай тасвирлый. Әмма архитектура конкурсында ул җиңмәде. Гәрчә, Казан мэры Илсур Метшин әйтүенчә, жюри вәкилләре нәкъ менә аның җиңүен көтсә дә: «Bespoke проекты безгә рухи якынрак...» – дигән алар. Җиңүне исә архитектор Кенго Куманың япон бюросы да кергән «Ваухаус» ҖЧҖ җитәкчелегендәге башка консорциум эше яулады. Әлеге проектны инде боз сарае дип йөртәләр. Әйдәгез, ул төзеләчәк шәһәр буйлап сәйран кылып кайтыйк әле.

– Безнең архитекторлар нигездә көнбатыш мәдәнияте йогынтысында иҗат итә, – дип бәяли Казанның хәзерге йөзен Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Әмма кайбер биналарда булса да милли бизәкләрне күрә алабыз әле. Бу үткән гасырның һәм бүгенге көннең татар мәчетләренә һәм дөньяви биналарына һәм хәтта рус хуҗалар заказы буенча төзелгән биналарга да (бигрәк тә эклектика өслүбендәге) кагыла. Мәсәлән, Манаков йорты (Мәскәү урамы, 42) фасады бизәлешенә. Кремль һәм Кави Нәҗми урамнары чатындагы (10/15) архитектурасы европача булган заманча йортның декорында да татар милли орнаменты файдаланылган.

Әлеге җәһәттән тагын М. Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры бинасын күзәтү кызыклы. Бу Сталин чоры ампиры кемгәдер бөтенләй яңа яктан ачылырга мөмкин: моның өчен аның фасадларына – колонналары, кәрнизләре, тәрәзә формалары, скверадагы фонтанына бераз игътибарлырак күз ташлау да җитә. Барысында да «формасы буенча милли, эчтәлеге буенча социалистик» сәнгать шигаренә җавап бирә торган совет архитектурасы идеясе ярылып ята.

– Элек күп казанлыга үзендә урнашкан «Ноталар» кибете буенча таныш Пушкин урамындагы 58 нче йорт танылган архитектор Рәшид Мортазин проекты буенча салынган. Игътибар белән карасагыз, архитекторның фасадны бизәү өчен үрнәк итеп Болгардагы Җәмигъ мәчете колонналарын алуын күрерсез, – дип мөселман мәдәниятенең хәзерге заман архитектурасына йогынтысына мисаллар китерүен дәвам итә Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова. – Әйе, инде узган гасыр уртасында ук рәссам-мигъмарлар үз проектларында татар мөселман архитектурасы мотивларын чагылдырырга омтылган.

Тагын да кызыклырак күренеш – әлеге тенденцияне өр-яңа хай-тек проектларда табу. Әйе, хәтта нәкъ менә Камал театрының конкурста җиңгән яңа бинасы концепциясендә дә. Булачак театрның интерьерларында һәм кече формаларында татар сәнгатенә хас төсләрне, орнамент стилистикасы элементларын күрә безнең экспертыбыз.

Сүз уңаеннан, мөселман архитектурасы образы гәүдәләндерелгән Bespoke җитәкчелегендәге консорциум проекты икенче урын алды. Анда архитектура формаларының суфичылык аскетизмына хас төгәллеге һәм кырыслыгы да, татар мәчетләрен төзегәндә бик еш файдаланыла торган, сафлыкны чагылдырган ак төс символикасына да акцент бар. Әмма бу, аңлавыбызча, инде бөтенләй башка тарих...

– Ислам сәнгатенә карата «эстетика» термины европача шәрехләнүендә кулланылмый, – дип сөйли миңа Гүзәл Фуад кызы. – Коръән дә, Сөннәт тә сәнгать формаларын ачмый. Шулай да, аларның икесеннән файдаланып, мөселманнарга үзләре өчен нәтиҗәләр ясау бер дә катлаулы түгел. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): «Аллаһ гүзәл һәм гүзәллекне ярата» хәдисен мөселман эстетикасының нигезе дип санап була, ул рәссамга иҗат итү өчен җитәрлек ирек бирә.

Г. Камал театрының яңа бинасы концепциясендә мөселман архитектурасы образы. Bespoke җитәкчелегендәге консорциумның әлеге эше конкурста икенче урынны алды.

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

ЭНҖЕ НАРМАЕВАДАН БӨТЕН ИНТЕРНЕТНЫ ШАУЛАТКАН ҖЫЛЫ САЛАТ

Татьяна Вафина

Бүген без блогер Энҗе Нармаевада кунакта. Димәк, ризык әзерләү бик күңелле булачак – Энҗенең гаиләсе зур, күпчелеге исә эреле-ваклы бала-чага. Энҗенең дүрт баласы да безгә хәлкадәри ярдәм күрсәтергә әзер: кайсыдыр яңа футбол тубы белән мактана, кемдер самокатта йөрүе белән шаккатырырга тели, өченчесе әнисенең аягын кочаклап тора, иң кечесе исә, тирә-юньдәге шау-шуга исе китмичә, әтисенең кулында изрәп йоклый... Менә дигән эш мохите, кыскасы. Башлыйбыз.

ДҮРТ МАЛАЙГА БЕР КЫЗ ДА ЮК

Нармаевлар гаиләсе белән танышкан һәркем диярлек «Бер капчык алма» мультфильмыннан атаклы: «Четыре сыночка и лапочка-дочка» гыйбарәсен сорау интонациясе белән әйтми калмый – янәсе, Энҗе, кайчан кыз да алып кайтасыз соң инде? Социаль челтәрдә танылган әни-блогер исә инде һәркайсына бер үк җавапны бирергә күнеккән: «Бу бездән тормый шул, барысы да Аллаһ ихтыярында. Әйе, кызым тууын да теләр идем, әмма иң мөһиме – балаларның барысының да сау-сәламәт булуы бит», – ди.

Малайлар отряды белән танышабыз.

– Балалар, килегез монда! – дип чакыра әниләре.

– Җегетләр! Килегез тизрәк! – дип команда бирә этиләре.

Буйлары буенча сафка тезелеп басып, исемнәрен әйтәләр:

– Әмирхан, Тамерлан, Арслан!

– Гыйммран, – дип өсти этиләре кулында рәхәтләнеп йоклап яткан сабыена ишарәләп. – Үземнең футбол командасын үстерәм! – ди аннары горурланып.

Энҗе исә бәхетле елмая гына.

– Шулкадәр малай-шалайны ничек тыңлатасың?

– Ирем булыша. Алар аны тыңлый, миннән исә әллә ни курыкмыйлар.Чөнки этиләре кырысрак, мин йомшаграк.

Нармаевлар гаиләсендә «тыңлыйлар» сүзенең нәрсә аңлатуын төшендерер өчен, хәзер сезгә бер тарих сөйлибез. Стоматология турында. Малайларның барысы да рәхәтләнеп тешләрен дәвалата. Беренче тешләре чыкканнан соң ук. Курыкмыйлар да, еламыйлар да. Киресенчә, әлеге процесс бик ошый икән үзләренә.

– Әтиләре дә, әниләре дә стоматолог булгач, нәрсәдән курыксыннар соң? – дип көлә этиләре.

– Әбиләре белән бабайлары да теш табибы, бездә шундый стоматологлар династиясе бит, – дип өсти әниләре.

– Әйе шул. Курыксаң да, курыкмасаң да, барыбер дәвалаячаклар. Яисә суырып алачаклар...

– Аның өчен түгел. Балачактан өйрәтелгәнгә күрә. Хәзер бит авыртуны баса торган төрле гельләр бар, мәсәлән, җир җиләге тәме килә торган, һ.б. Шунлыктан безнең гаиләдә бөтен кешенең теше сәламәт. Һәм елмаюы да матур, – дип искиткеч тешләрен күрсәтеп елмая Энҗе. Ике айлык Гыйммранның елмаюы гына әлегә башкалардан калыша...

– Балаларын теш табибына алып барырга җыенган ата-аналарга үзегезнең стоматологик киңәшегезне бирегез әле.

– Баланы стоматологка йөрергә әзерләргә кирәк. Ягъни теш сызлый башлаганчы күнектерү хәерлерәк – югыйсә аның теш табибына беренче тапкыр барудан алган тәэсире бөтен калган гомере буена авырту белән бәйле булачак.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Тавыкның түш ите – 500 г;
- Помидор – 4 данә;
- Суган – 2 баш;
- Тозлы вак сохари («Кириешки») – 2 кап (80 г);
- Майонез – 4 аш кашыгы;
- Аджика – 1 чәй кашыгы.

Фото: Александр Ефремов

1 Кыздырабыз

2 Кызартып алабыз

3 Салабыз

4 Өстибез

5 Тезәбез

6 Сылыйбыз

7 Сибәбез

Профилактикадан, чистартудан, мәсәлән, авыз куышлыгын тикшерүдән башлау яхшы. Ихтимал, бу очракта теш сызлауга кадәр барып та җитмәячәк.

МӘХӘББӘТ БУ

– Сез ничек икегез дә стоматолог булып чыктыгыз соң?

– Бик гади бу. Медицина университетында бергә укыдык, бер-беребезгә гашыйк булдык...

– Өйләнештегез инде аннары...

– Тиз генә өйләнешеп булмады әле, – дип искә ала Энже. – Мин Женяга үземнең динле гаиләдән икәнемне, әти-әниемнең мөселман булмаган кешегә кияүгә бирмәячәген әйттем. Бездә шундый мәзәк тә бар бит: «Кызым, милләте мөһим түгел, татары гына яхшы гына булсын!» – диләр.

– Сез әти-әниегезне тыңламыйча кияүгә чыктыгызмы инде?

– Юк, бездә алай ярамый. Женя ислам динен кабул итте һәм 2012 елда безнең никахыбыз булды.

– Мәхәббәт бу!

– Бу сөюем миңа исламны өйрәнергә һәм аңларга ярдәм итте, – ди Евгений. – Миңа әлеге дин бик ошады, чөнки мин Коръәндә үземне кызыксындырган бөтен сорауга да җавап таптым. Аны рус телендә укыйм.

АКТИВ ТОРМЫШ ПОЗИЦИЯЛЕ МӨСЕЛМАН ХАТЫНЫ БЛОГЫ

– Без өйдә нигездә русча сөйләшәбез һәм мин блогымны да рус телендә алып барам, чөнки бу очракта исламның нинди дин булуын күбрәк кеше аңлаячак, – дип дәвам итә Энже. – Башта татарча алып барып карадым, күп кеше аңламый иде, мөселманнар татар гына түгел бит. Язылучыларым да Татарстаннан гына түгел. Тәрҗемә итәргә, кабат-кабат аңлатырга туры килә иде. Хәзер исә һәркем аңлый. Һәм мин моңа бик шатмын. Чөнки мин үз блогымда язылучыларыма күп нәрсәне аңлата, Коръән аятьләренең мәгънәсен төшендерә, традицияләр, шул исәптән гаилә горефләре хакында да сөйли алам.

– Блог өчен нигә нәкъ менә шул юнәлешне сайладыгыз?

– Тыныч, уңышлы, бәхетле мөселман хатынын, бәхетле әнине күрсәтәсе килә. Безнең җәмгыятьтә шундый стереотип бар – янәсе, әгәр син мөселман хатыны икәнсең, син хокуксыз, изелгән бер мескен, көннәр буе балалар белән өйдә утырасың, сиңа каядыр барырга, эшләргә, бизнес белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирмиләр... Ни өчендер без тормышта бернигә дә ирешмибез, дип санала. Шунлыктан мин үз блогым аша актив тормыш позицияле мөселман хатын-кызлары да булуын күрсәтергә телим: алар сәяхәт итә, матур яши, үз максатларына ирешә, үз эшен алып бара һәм боларның барысын да ана вазыйфаларына бер зыян да китермичә башкара ала. Алар эшләргә дә өлгерә, шул ук вакытта яхшы хатын да – мин үзем, һәрхәлдә, яхшы хатын булырга тырышам. Кем өчендер минем тормышым үрнәккә әйләнергә мөмкин. Миңа язылып, постларымны укып баручы кешеләр еш кына: «Сез безгә үрнәк, без дә шулай, берничә баласы булып та, барысына да өлгерә торган әни булырга телибез», – дип яза. Әгәр мин кемгә дә булса булыша, хәйриячелеккә, игелек эшләргә рухландыра алам икән, үз миссиямне үтәлгән дип санаячакмын.

Ягъни мин чын мөселманлыкның нинди икәнен күрсәтергә тырышам. Күпләр үзләрен ниндидер кысаларга куып кертә. Гәрчә безнең заманда үз-үзеңне үстерү, белем алу өчен мөмкинлекләр гаять күп булса да. Бөтен нәрсә кешенең үзеннән тора. Мөселман хатын-кызлары өйдә утырырга тиеш дип беркайда да язылмаган. Бик телисең икән, хәтта космоска да очарга була. Иң мөһиме – ниндидер кануннарны бозмау.

ТУГЫЗ ЕЛГА СУЗЫЛГАН ДЕКРЕТ

– Гаиләдә исламның нинди кануннарын тотасыз?

– Иң мөһиме, намаз укыйбыз. Мамадышта яшәүче әти-әнием дә намазда. Бергә җыелган вакытларда исә бергәләп укыйбыз, бу бик дулкынландыргыч, бигрәк тә рамазанда. Бөтен зур гаилә бергә җыелганда, җан сөенә. Шулкадәр рәхмәт хисе туа! Хәзер ураза тотабыз. Дөрес, бер Женя гына тота булып чыга. Калганнар «балалар һәм бала имезүче аналар» категориясенә керә – безгә исә әлегә тотмаска рөхсәт ителә.

– Сезнең блогерлык тормышы ничек башланды?

– «Әниләр» төркеменнән башланган иде – анда бала тәрбияләп өйдә утыручы әниләр бер-берсенә сораулар бирә, киңәшләре белән уртаклаша. Аннары SMM-белгеч булып эшләдем, иремнең клиникасында стоматология блогы алып бардым, башка төркем, блогларны популярлаштырдым. Боларның барысына да өйрәнеп беткәч, үземнең блогыма да вакыт җиткәнен аңладым. Башта яулык бәйләү буенча видеодәресләр яздырдым. Аларны аудитория бик яхшы кабул итте. 2017 елдан бирле инде мин – чын блогер. Минем «Инстаграм»да 133 мең язылучым бар иде, «ВКонтакте» челтәрендә – 13 меңгә якын. Хәзер «Телеграм» каналын үзләштерәм. Бу минем эшем дә, бизнесым да, тормышым да. Үзләрен гел төшергәнгә балалар күнекте инде, алар моңа игътибар да итми...

– Мондый эшкә һәм мондый тормышка ничек вакыт җиткерәсез?

– Башта авыр булды, күңелгә ятмады. Видеога төшәргә, экраннан нәрсәдер сөйләргә ояла да идем... Аннары күнектем, телефон гел кулда, хәзер инде баш миеннән сигнал турыдан-туры кулга килә: «Моны һичшиксез төшерергә

кирәк!» – дип уйлауга, кул төшерә дә башлый. Барысы да үзеннән-үзе эшләнә.

– Ирегез сезнең блогерлыкны хуплыймы соң?

– Башта: «Син тагын телефонда!» – дип ачулана иде. Әмма кешеләр язылa, реклама бирүчеләр табыла, ниндидер табыш керә башлагач, ул моның чыннан да эш икәнен аңлады. Хәзер инде аның да, улларыбыз кебек үк, үзен төшереп челтәргә куйганга исе китми. Гомумән, мин бармактан суырып чыгарганны күрсәтү белән шөгыльләнмим бит. Нәкъ менә чынбарлыкны күрсәткәнгә күрә ул халыкка ошады да. Өстәвенә, мин барысын да бик гадел алып барырга тырышам. Тере аудиорияле блогерлар күп түгел, алар шундук күренә.

НЕГАТИВТАН ПОЗИТИВ КҮБРӘК

– Төрле усал комментарийлардагы негативны ничек кабул итәсез? Сезнең блогка да бәйләнүчеләр бармы? Аларга нәрсә ошамый?

– Кайвакыт мөселманнардан тәнкыйть эләгә, гәрчә минем аларның ачуын чыгарырлык постлар язганым юк, дип уйлыйм... Әмма, әгәр мин кемнеңдер фикере белән килешмим икән, бик явыз комментарийлар да була. Баштарак мин бик кайгыра, елый, һәрбер шундый гаепләүне йөрәгемә якын ала идем. Хәзер исә андый комментаторларны блокка гына җибәрәм. Алар белән ызгышырга да, бәхәсләшергә дә җыенмыйм. Бәйләнмәвең яхшырак. Әгәр кеше тискәре фикердә, тиргәшәсе килә икән, аны берничек тә җиңеп булмаячак.

Әмма позитив мизгелләр күбрәк. Күптән түгел дус кызларым клип төшерде һәм җыр башланганда миннән «Фатиха» сүрәсен укуымны үтенделәр. Бу җырны Татарстандагы бөтен каналларда, радиостанцияләрдә әйләндерделәр. Миңа бик рәхәт булды. Язылучыларым әйтүенчә, минем арттан кабатлап, шактыенең баласы сүрәнең сүзләрен ятлаган икән. (Сүрәне «Татарстан» журналының социаль челтәрләрендә тыңлап була.) •

«СЕЗНЕҢ ТЕГЕ ТӘМЛЕ САЛАТНЫ КАЙДАН ТАБАРГА ИКӘН?»

Шулай сөйләшә-сөйләшә салат әзерләнеп тә бетте.

– Минем әниемнең рецепты, – дип, Энҗе башта кыздырылган тавык кисәкләрен, аннары суган, помидорны катламлап җәя дә, өстенә майонезлы аджика сылап, тозлы сохари (кириешки) сибә. – Бу шактый калорияле салат. Әмма ул бик туклыклы да, тиз дә әзерләнә, ингредиентлары да күп түгел. Бервакыт мин аны үземнең блогымда әзерләгән идем, һәм ул бөтен Интернетны шаулатты – күп кешегә ошады, бик күп кеше үзенә саклап куйды, хәзер дә кабатлап күрсәтүемне сораучылар байтак.

– Хәзер алар аны «Татарстан» журналыннан табачак!

Шул арада футбол командасы да ашханәгә кереп, тәртипле генә табынга утыра һәм..һәркайсы үзенә торт кисеп бирүне үтенә.

– Алар безнең баллы ашарга ярата, – дип һәркайсына берәр кисәк торт кисеп бирә Энҗе.

– Тешләрен гел тикшертеп торгач, рәхәтләнеп сыйлана алалар шул. Ә сез нәрсә яратасыз?

– Минем әнием бик тәмле пешерә. Бигрәк тә татар халык ашларын – өчпочмак, бәлеш, өлеш, кыстыбый... Һәм инде әни янында без бөтенесен дә авыз итәргә тырышабыз. Бик үк дөрес туклану булмаса да, рәхәтләнеп сыйланабыз.

Ә хәзер, әйдәгез, салат ашыйбыз. Ул да дөрес туклану категориясеннән түгел, әмма хәләл һәм бик-бик тәмле! Т

1 Шул арада футбол командасы да ашханәгә кереп, тәртипле генә табынга утыра һәм... һәркайсы үзенә торт кисеп бирүне үтенә.

ИФТАР – ИҢ КАДЕРЛЕ СЫЙ

Руфия Фазылова

Мөселманнар өчен Ураза ае чын мәгънәсендә бәйрәмгә тиң. Изге гамәлләр кылу, начар уй-ниятләрдән тыелып торудан кала, ай дәвамында кардәшең белән очрашу-аралашу өчен дә бер дигән форсат ул. Соңгы елларда күмәк ифтарлар үткәрү күркәм гадәткә әйләнде. Моның ачык мисалы – башкалабызның һәр зур мәчетендә быел да ифтарлар узды. (Кайбер җирләрдә ланч-бокслар белән кайнар ризык тарату оештырылган иде.) Иң зур ифтарлар, гадәттәгечә, Казанның «Ярдәм» мәчетендә булды.

Фото: Александр Ефремов

КӨН САЕН ӨЧ КАЗАН РИЗЫК

Сүзне шуннан башларга кирәктер: Казанның «Ярдәм» мәчете ел әйләнәсе мохтаҗлар өчен кайнар ризык тарату белән шөгыльләнә. Авыр хәлдә калган гаиләләр, яшәү урыны булмаган кешеләр, пенсияне аз алган әби-бабайлар даими рәвештә көндез кайнар ризык алырга килә. (Милләткә, дингә бүлү юк.) Гадәти көннәрдә 200–250 кешегә ризык әзерләсәләр, Ураза ае башлангач, 1 мең 500 кешегә пешерәләр. Көн саен өч казан кайнар ризык әзерлиләр.

– Беренче күмәк ифтарларны әле Левченко бистәсендәге «Сөләйман» мәчетендә уздыра башлаган идек, – диде «Ярдәм» мәчетенең имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов. – 2002 ел иде ул. Ул вакытта ун-унбиш кенә кеше җыела иде. Ел саен ифтарга килүчеләр саны арта барды. Нәтиҗәдә, санаулы еллар эчендә бөтен ишегалдын тутырып,урамга чатырлар куеп, 300–350 кешелек табын кордык.

«Ярдәм» мәчете 2013 елда, изге рамазан аенда ачыла. «Сөләйман»да башлаган изге эшләрне Илдар хәзрәт биредә дә дәвам итә. Иң кызыгы – 2013 елның 18 июлендә «Сөләйман»да 350 кешегә ифтар уздырсалар,икенче көнне инде «Ярдәм» мәчетендә 600 кешегә табын әзерлиләр. Киләсе елда ифтарга килүчеләр саны тугыз йөздән, аннан меңнән артып китә...

– Бүген 500 кешене табынга утыртабыз, ә 1 мең кешегә ланч-бокслар әзерлибез, – диде Илдар хәзрәт Баязитов. – Без Киров һәм Мәскәү районы мөхтәсибәтенә карыйбыз. Шушы ике районның мәчетләренә көн саен ланч-бокслар таратабыз. Ризык пешерү белән проблема юк. Пандемия вакытында бөтен Казан шәһәре буйлап 2 мең кешегә ланч-бокслар тараттык. Алты зур казан тора, берьюлы 2 мең 500 кешелек кайнар ризык әзерли алабыз. Штатта пешекчеләр бар, ярдәмгә мәчеттә эшләүче башка хезмәткәрләр дә килә.





Илдар хәзрәт белән яңа салынган спорт комплексын карап чыктык. Мөмкинлеге чикле кешеләр өчен дип махсус эшләнгән ул. Шаккаттык дию генә аз, таң калдык! Россиядә әлегә кадәр мондый спорт комплексы юк икән.

– Аллаһы боерса, май азагында спорт үзәген ачачакбыз, – диде Илдар хәзрәт. – Барысы да әзер инде, кәгазь эшләре генә калды. Ураза ае кышка таба бара бит. Шуның өчен дә күп кеше сыйдырышлы зур зал булдырасы килде. Комплексның спорт залына берьюлы 1 мең 500 кеше сыячак. Шулай булгач, мәчетебездә киләчәктә дә күмәк ифтарлар зурлап узачак.



БӘЙРӘМ

Биредә ифтарлар ашап-эчүгә генә кайтып калмый. Табынны алып баручы Гамил Нур килгән халыкка сүз бирә. Төрле уеннар, котлаулар белән бергә үрелеп барган күңелле мәҗлескә әйләнә ул.

Без килгәндә авыз ачу вакыты җитеп килә, чатырга инде халык җыела башлаган иде. Яшь кызлар, егетләр тиз-тиз генә табын әзерләп йөри. Ифтарга килгән халык белән итагатьле генә елмаеп исәнләшәләр... Кызларның берсе – **Алия Хәлиуллина** белән аралашып алдык. «Ярдәм» мәчетенең никах үзәгендә эшли икән.

– Башта ланч-бокслар тутырабыз, аннан соң табын әзерлибез, – диде ул эштән бүленми генә. – Без монда иртән килеп, төнлә генә кайтабыз. Кунаклар китеп, табыннарны җыештыргач, янә җыелышып чәй эчәбез. Шулай итеп сәхәр дә монда уза. Өйгә кайтып йоклыйбыз да яңадан бирегә киләбез.

– Меню көн саен төрлеме? – дим.

– Әйе, мисал өчен, кичә карабодай иде, бүген пылау. Камыр ризыклары да үзгәрә. Яшелчә, җиләк-җимеш исә көн саен бар.

Чатырга бөтен кеше сыеп бетми, әлбәттә. Ләкин мәчеткә килгән бер кеше дә ач калмый – табын артында урын җитмәгәннәргә ланч-бокслар тараталар. «Ярдәм» мәчетенең үзендә кичке намаздан соң һәркем кайнар ризык, салат, ипи, пәрәмәч салынган тартмаларны ала китә. Гыйбадәтханәнең ишек төбендә торучы балалар, хатын-кызларны үз күзләребез белән күрдек. Алар әнә шулай көн саен ланч-боксларны алырга килә икән. Әйткәнемчә, берәүне дә ризыксыз җибәрмиләр.

– Монда өстәлләр бүленгән, ахры? – дидем «Ярдәм» фондының җитәкчесе Мәликә ханым Гыйльметдиновага.

– Әйе, өстәлләргә төркемләп утыртырга тырышабыз. Мәсәлән, беренче өстәлдә үзебезнекеләр, ягъни мәчеттә реабилитация узучы күрмәүче ир-атлар, хатын-кызлар. Ураза аенда тернәкләндерү курсларына фәкать ислам кануннары буенча яшәүчеләрне чакырабыз. Ә башка айларда дингә, милләткә карап бүлмибез. Икенче өстәлдә – Левченко бистәсеннән килгән апалар, әбиләр. Алар инде тугызынчы ел шулай ифтарга килә. Өченче өстәлдә – мәчеткә даими йөрүче ир-атлар. Дүртенче өстәлдә дусларыбыз – күрмәүчеләр җәмгыяте вәкилләре. Бишенчедә – Казанның «Эмоция» театры артистлары. Аларның кайберләре бездә реабилитация курслары узган иде, әнә шуннан дуслашып калдык. Көн саен шулай кунакка төрле җәмгыятьләрне чакырабыз. Кемнәр генә булмады инде. Тагын чакырыгыз әле, диләр.

ЛЕВЧЕНКО ӘБИЛӘРЕ

Левченко бистәсеннән килгән ак яулыклы апалар янына барып таныштым:

– Пандемия вакытында гына килмәдек, мәчетләрдә ифтарлар булмады бит. Ә болай «Ярдәм» мәчете ачылганнан бирле ел саен авыз ачарга бирегә киләбез, – диде Гөлсирә апа Бикмөхәммәтова. – Ундүртләп кеше без. Арабызда алтмыш яшьлек хатын-кыз да, туксанга җиткән дә бар. Бер тирәдә яшибез, Левченко мәчетенә йөреп гарәп хәрефләрен укыдык. Аллага шөкер, барыбыз да Коръән укыйбыз.

– Монда ничек киләсез? – дим.

– Автобус белән Левченкодан килеп алалар. Илдар хәзрәт оештырды, зур рәхмәт яусын үзләренә. Без монда мәчет төзегәндә дә килеп булыштык. Шуңа да әлеге иман йорты күңелгә бик якын.

Ак яулыгын таратып бәйләгән мөлаем әби белән дә таныштык – Гайшә исемле икән, 89 яшен тутырган. Ураза тота алмаса да, әбекәй көн саен ифтарга килә.

– Икенче төркем инвалид мин, – диде Гайшә апа. – Чирләрем бик күп, шуңа күрә ураза тота алмыйм. Фидия сәдакамны мәчеткә бирдем. Бирегә исә ашау өчен дип түгел, мөслимәләр белән аралашып, вәгазьләр тыңларга дип киләм. Бик рәхәт монда, җанга да, тәнгә дә шифа алып кайтам.

...Мондый ифтарларның бер көне якынча 400 мең сумга төшә. Белгәнебезчә, Ураза аенда мөселманнар ничек тә күбрәк игелек кылырга тырыша. Шуңа күрә болай зурлап табыннар кору проблема түгел – «Ярдәм» мәчетендә алдан исемлек төзелә. Берничә кеше җыелып та ифтар уздыра ала. Т



КАРЛЫ ИЛДӘ ИСЛАМ: ДӘВЕРЛӘР АША СӘЯХӘТ

Ольга Туманская

Без дөньядагы иң матур мәчетләрнең берсендә. Кол Шәрифнең архитектурасы белән әсәрләнеп, аның эчке бизәлешенә – Рим мозаикасы, уеп төшерелгән бизәкләр, мәчетнең витражлары, керамика һәм төсле пыялаларга карап сокланабыз. Күзәтү балконына күтәрелеп, гыйбадәт залының нурына һәм мәһабәтлегенә хәйран калабыз... Дөньяда тәүлек әйләнәсе Коръән яңгырап торган икенче урын бу: 26 хафиз, бер-берсен алыштыра-алыштыра, изге сүрә-аятьләрне укый. Ислам мәдәнияте музееның нәкъ менә биредә ачылуы бер дә гаҗәп түгел.

– Безнең төбәк мең ел дәвамында мөселман дөньясының төньяк форпосты буларак үсте. Бүген дә мәдәниятебезнең тотрыклы образы бар – карлы илдә ислам, – дип сәяхәтне башлый музей директоры Илнур Низамиев. – Безнең музей ислам турында бөтен кешегә сөйләп бирү өчен оештырылды, һәм күп кенә кунакларыбыз мөселман дине белән беренче тапкыр монда таныша.

Бу музейда борынгы артефактлар һәм югары технологияләр бер-берсенә ярашлы рәвештә кушылып китә. «Терелә торган» цифрлы экспонатлар карап йөрергә генә түгел, тыңларга да мөмкинлек бирә, шул рәвешле ерак дәверләргә сәяхәт максималь дәрәҗәдә чынбарлыкка якыная.

КОРЪӘН АВАЗЛАРЫ

Бу музейның иң төп экспонаты кайсы икәнен бик тиз аңлап аласың. «Интерактив Коръән» биредә үзәк урынны алып тора – калган экспозиция ярымай шәкелендә аның тирәли тезелгән. Коръән безне Изге китапның Госманлы дәүләте һәм хәзерге Төркия, Иран, Андалузия, Һиндстанда эшләнгән кульязмаларының сирәк күчермәләре белән таныштыра, биредә шулай ук тиңсез Казан басмасы – Коръәннең мөселманнар әзерләгән беренче басма вариантын да күрергә мөмкин.

Электрон идарә ярдәмендә Коръәннең битләрен күчерергә һәм цифрлы сәхифәләрнең кыштырдавын тыңлап ләззәтләнергә була. Ул әле җырлый да! Бу опцияне кушуга, мөселманнар тарафыннан турыдан-туры Аллаһ сүзләре дип кабул ителә торган изге аятьләр аһәңе зал буйлап тарала башлаячак. Ә экранда аларның гарәп теленнән инглиз, рус, татар телләренә тәрҗемә рәвешендәге басма версиясе күрсәтелә.

Фото: Александр Ефремов

УРТА ГАСЫРЛАРДА ХАЛЫКНЫ ҖӘЛЕП ИТКӘН ҮЗӘК

Археологларның табылдыклары арасында төрле бизәнү әйберләре, савыт-саба, бик юка пыяла һәм хәтта кура җиләге орлыгы да бар. X йөзьеллыкта борынгы Биләр шәһәрлеге урынында урта гасырлардагы иң зур шәһәрләреннән берсе гөрләп торган. Кала административ һәм икътисади үзәк генә түгел, ә фән кешеләрен, шул исәптән дин галимнәрен дә җәлеп иткән урын булган.

Әлеге шәһәр музей витриналарының берсендә каршыбызда мираж кебек пәйда була. Моңа хәзерге заман галимнәре һәм рәссамнары эшләре ярдәм итә. Биредә аеруча кадерле экспонат – архитектура тарихы өлкәсендәге күренекле белгеч Нияз Халитов ясаган макетта Биләр җәмигъ мәчетенең тышкы күренешен күрергә була. Һәм менә үзеңне сәяхәтче итеп күз алдына китерәсең дә юлъязмаларында Идел буе Болгарстанын – шәһәрләр иле, ә Биләрне бөек кала дип атыйсың, чөнки ул искиткеч зур, матур һәм анда бик күп кеше яши.

1100 ЕЛЛЫК ТАРИХ БАШЫ

11 ай һәм 4,5 мең километр – Багдадтан габбасилар хәлифәсе әл-Мокътәдир илчеләре делегациясенең төньяктагы ерак җирләргә сәяхәте шундый озын һәм катлаулы була. Бу вакыйга моннан нәкъ 1100 ел элек чынга аша һәм Идел буе Болгарстаны дәүләте тарафыннан ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүен хисаплый башлау ноктасы санала. Әлеге вакыйгага музейда аерым витрина бирелгән. Аңа карап, урта гасырлардагы шундый куркыныч та, матур ачышлар да алып килгән сәяхәтне ачык күз алдына китерергә мөмкин.

Өенә кайткач, илчелек сәркатибе Әхмәд ибн Фадлан сәяхәтнамә рәвешендә хисап язачак. Соңгы күчермәләрендә бу көндәлек безнең көннәргә кадәр килеп җитәчәк һәм шул мөһим вакыйгаларны реконструкцияләү өчен төп документларның берсенә әвереләчәк. Аннан без бүгенге Россия территориясендә яшәүче халыкларның көнкүреше, көндәлек тормышы һәм гореф-гадәтләре турында беләбез. Әмма безне аеруча төп очрашуның тасвирламасы кызыксындыра.

– Бүген бу вакыйганы Идел буе Болгарстаны халыклары тарафыннан ислам динен кабул итү көне дип саныйбыз, әмма шуны да билгеләп үтәргә кирәк (сүз уңаеннан, бу хакта Фадлан да искәртә): ул вакытка ислам бу җирләрдә инде тамыр җибәргән була, – дип төгәллек кертә Илнур Низамиев. – Биредә мәчет-мәдрәсәләр төзелгән, делегация вәкилләре биредә бергәләп җәмәгать намазы укыган.

АЛТЫН УРДА: ШӘРИГАТЬ КАНУННАРЫ КУШКАНЧА

Җете кызыл кием, очлы сакал, монголларга хас кысыграк күзләр... Каршыбызда – Бәркә хан үзе. Казан рәссамы Рушан Шәмсетдинов ясаган миниатюрада ул изге Коръәнгә кулын сузган. Һич ялгышлык юк. Бу экспозициядә Җучи Олысының (Алтын Урданың) бишенче хөкемдары урын алу очраклы түгел, чөнки нәкъ менә Бәркә хан монгол ханнарыннан беренче булып ислам динен кабул итә. Шул вакыттан бирле бинһая зур дәүләтнең икътисады, сәясәте, иҗтимагый тормышы һәм көнкүреше шәригать кануннарына туры китереп корыла.

Бәркә хан портрет янәшәсендә каш йолку өчен эскәкне хәтерләткән ниндидер сәер коралга күз төшә.

– Бу чыннан да корал, тик медицина коралы. Аны Болгарда казу эшләре вакытында археологлар таба, – дип серне ача Илнур Низамиев. – Мондый пинцет һәм скальпельләр ярдәмендә XIII–XIV гасырларда катлаулы операцияләр ясыйлар, шул исәптән офтальмология операцияләре дә. Яхшылабрак карасагыз, янәшәдә тагын бер артефакт күрерсез. Бу – XIV гасырда гарәп галимнәре төзегән кеше организмы атласы. 300 елдан соң безнең төбәктә аның күчермәсе эшләнә – мәдрәсәдә шуның буенча укыйлар. Әйе, фән, белемнәр бик ерак араларны уза, һәм бу процесста ислам мөһим рольләрнең берсен башкара.

БОРЫНГЫ АНСАМБЛЬ – ЮНЕСКО МИРАСЫ

Архитектура – туктальп калган музыка ул, диләр. Борынгы Болгарга багышланган витринага карагач, моның чыннан да шулай икәнлегенә ышанасың. Арткы планда – Җәмигъ мәчете һәм манаралар, мавзолей һәм төрбә, мунчалар, мәктәпләр, базар... XIII–XIV гасырдагы егермедән артык таш корылма, образлы рәвештә булса да, каршыбызга килеп баса. Һәм син урта гасырлардагы мөселман каласының авазларын ишетә башлыйсың. Ә алда – Болгар архитектурасының иң яхшы сакланып калган һәйкәле – Кара пулат бинасының киселеше. Кайчандыр монда өч кешелек шура белән бергә хан үзе хөкем чыгара торган судлар уздырылган. Бу дүртлектән һәркайсының үзенең махсус ишеге булган – һәр дөнья тарафына караган бер ишек. Хөкемдар исә һәрвакыт көнбатыштагы ишектән кереп йөргән, диләр.



ШИГЪРИ КАЗАН

Казан тарихына һәм аның Кремленә багышланган экспозициянең көтелмәгән борылышы хәтта җирле халыкны да гаҗәпкә калдыра ала. Миниатюрада – Казан ханлыгы башкаласында яшәгән Мәхмүд хаҗи углы Мөхәммәдьяр. Аның рәсми вазыйфасы – Казан ханнары төрбәсе сакчысы. Әмма бүген ул күбрәк шагыйрь буларак билгеле. Аның поэмалары безгә тарихи артефактлар рәвешендә килеп җитеп кенә калмыйча, хәзерге телләргә дә тәрҗемә ителә, һәм алар белән киң катлам укучылар таныша ала. Әлеге поэмаларда мөселман нәфис сәнгате һәм әдәбияты үсешенең тулы бер чоры чагылган. Сәнгать тарафдары буларак танылган Казан ханы Мөхәммәд Әмин әсәрләрендәге кебек үк. Аның 2015 елда 500 яшь тулган «Могҗизанамә»се шигъри формада язылган хикәятләр җыентыгыннан гыйбарәт. Тарихчылар раславынча, гарәп хәрефләре белән язылган әлеге юлларда хөкемдарның хыял-омтылышлары һәм хәтта яшерен уйлары чагыла.



ИМАН МИСТИКАСЫ

Менә бу кульязма документ исә гаять зур күләмле. Гарәп язулары бер-берсе белән тоташтырылган әйләнәләр рәвешендә тәкъдим ителгән, әйтерсең, монда зур блок-схема ясалган...

– Бу силсилә-генеалогия, ләкин рухи силсилә, – дип сөйли Илнур Низамиев.

Безнең төбәктә исламның мистик юнәлеше саналган суфичылыкның йогынтысы зур була. Ул рухи һәм физик гамәлләр ярдәмендә Аллаһка якынаю аша кешенең җанын камилләштерүне һәм аскетизмны алга сөрә. Рухи камилләшү өчен тиешле әдәбиятны уку һәм остаз – шәехләр белән махсус тәрбия эше алып бару таләп ителә.

Без җентекләбрәк карарга теләгән силсилә – нигездә, Урта Азиядән (Бохара, Сәмәрканд) килгән һәм безнең төбәктә XV–XVI гасырларда таралган суфыйчылык феномены ядкәре артефакты. «Силсилә» сүзе «чылбыр» дип тәрҗемә ителә. Силсиләдә буыннар алмашы, нәкъ менә белем күчеше мөһим, төгәлрәге – суфыйчылык юлында шәех туплаган рухи тәҗрибәләр беренче планда. Силсилә тышкы яктан шәҗәрәне хәтерләтә һәм аның шәҗәрәгә охшавы өлешчә дөрес тә: силсиләгә карап, бу нәсел кешесенең кемнән белем-тәҗрибә туплаганын тикшереп була. Аның исеме югарыда язылган, ә аска таба остаздан остазга төшә барган саен, иң ерак гасырларга – ислам мәдәнияте формалашкан борынгы Урта Азия үзәкләренә кереп китәбез.

МУЗЕЙ САННАРДА ҺӘМ ДАТАЛАРДА

2006 елның 21 феврале. Бу көнне, Кол Шәриф җәмигъ мәчетен ачу тантанасыннан соң бер ел узгач, музей тәүге тапкыр үз ишекләрен ача.

Бу – Россиядә Идел-Урал төбәге татарлары тарихында ислам роленә һәм мөселман мәдәниятенә багышланган **беренче** һәм бердәнбер мирасханә.

Ел саен музейга **120 меңнән артык** кеше килә.

Музейның **2 бүлеге** кунакларны Идел буе төбәгенең Болгар дәүләтеннән башлап Казанга кадәр һәм ислахчылык чорыннан алып хәзерге көнгәчә яшәгән мөселман цивилизациясе белән таныштыра.

Музейның хәзерге экспозициясе **2014 елда** оештырылган иде. Аны туплау-әзерләүдә көч керткән ислам белгечләре тарихи материалны дөрес, җентекле һәм ачык итеп күрсәтергә тырыша.

Музейда **50 дән артык** вакытлы күргәзмә узды һәм кунакларны ислам мәдәнияте белән таныштырды.

Бүген музей коллекциясендә Коръәннең **700 берәмлектән артык** борынгы һәм заманча басмасы исәпләнә.

МӘГАРИФ ДӘВЕРЕ

Гади бер борынгы фото кебек тоелса да, чынлыкта алай түгел. Сюртук һәм милли баш киемнәре кигән бу ир-атлар – мәгърифәт һәм эксперименталь өчен ачык мөселман мәктәбе булган атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең химаячеләре һәм укытучылары. Илнур Низамиев игътибарыбызны кадрның урта өлешенә юнәлтә. Кара кием, ак чалма, күзлек... Танылган Галимҗан Баруди менә нинди кыяфәттә булган икән! Ә фото янында уку программасы ята – аңа күз салу сезгә бик кызыклы булачагына ышанабыз.

Музейның икенче каты XX гасыр башына кадәр булган соңгырак чор вакыйгаларына багышлана. Биредә мөселман-хәйриячеләр, мөселман мәгарифе фәненең прогрессив юнәлеше – җәдидчелекнең барлыкка килүе турында җентекле мәгълүмат алырга мөмкин. Димәк, дини мәгърифәт һәм хәтта анда хатын-кызның роле турында да... Әйе, кечкенә генә бу музей Идел буе төбәгендә исламның гаҗәеп тирән тарихын үз эченә сыйдыра алган.

ҖҮКӘТАУ – ЧУЛМАН ЯРЫНДАГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ

Серле болгар шәһәре. Ул борынгы рус елъязмаларында телгә алынган, шул замандагы Европа карталарында билгеләнгән. Ә аннан соң вакыт туфанында эзсез югалган. Хәер, нигә әле эзсез? Шактый артефакт табылган Чистай янындагы шәһәрлек – нәкъ шул Җүкәтау ул.

Рус елъязмаларында бу шәһәрне Жукотин дип язганнар. Көнбатыш Европада, борынгы карталарда үзләренчә – Sacetim дип билгеләгәннәр. Чулманның сул як ярындагы биек борынында салынган Җүкәтау (Юкәтау – юкәле тау) иң көчле чорында һичшиксез шау-шулы һәм абруйлы булгандыр. Археологлар тикшерә торган шәһәрлек урынында басып торганда үзеннән-үзе биредә моннан мең еллар элек кайнаган тормыш күз алдына килә. Менә өч биек туфрак өеме, калкулык һәм ике тирән чокырның сакланып калган фрагментлары – алар абруйлы морзалар яшәгән кирмәнне саклау өчен хезмәт иткән. Ә анда, бераз ерактарак, һөнәрчеләр яшәгән, эшләгән, иҗат иткән бистә. Биредә тимер эреткәннәр, корал чүкегәннәр, зәркән бизәнү әйберләре, үзенчәлекле Җүкәтау керамикасы ясаганнар.

Археологлар, туган якны өйрәнүчеләр әлеге урыннарны XIX гасырда ук өйрәнә башлый. Ә менә бүгенге Чистай шәһәре янында нәкъ шул Җүкәтауның табылуы күпкә соңрак, галимнәр җитди казу эшләренә керешкәч кенә аңлашыла. «Нәкъ менә шул» диюебез шуңа: X-XV гасырларда Җүкәтау Идел буе Болгарстанында төп шәһәрләрдән берсе була, иң гөрләгән чорында Биләр, Болгар, Сувардан бер дә калышмый. Дәүләтне монгол яулары басып алганчыга кадәр үк (1236) Җүкәтау Гарәп хәлифәте, Византия һәм Рус дәүләте белән сәүдә итә.

Идел буе Болгарстанының зур үзәкләре җимерелү һәм әкренләп сүнүгә барган Алтын Урда хакимияте вакытында Җүкәтау, исән калу гына түгел, икътисадый һәм сәяси йогынтысын шактый арттырып, үзенең иң уңышлы чорына аяк баса. Әгәр XII гасырда Җүкәтау 12 гектар мәйдан биләсә, ике гасырдан соң аңа 150 гектар да кысан була. Ул чорда кала зур тимерчелек һәм чүлмәкчелек бистәләре булган эре һөнәрчелек үзәге санала. Бу шулай ук Кытай һәм Һиндстан сәүдәгәрләре килә торган сәүдә үзәге дә. Җүкәтауның икътисадый-сәяси йогынтысы көчәю ахыр чиктә Җүкәтау кенәзлеге пәйда булуга китерә – ул Идел буе Болгарстанының көнчыгыш җирләрен тулысынча контрольдә тота һәм турыдан-туры Алтын Урда ханнарына буйсына.

Археологик табылдыклар Җүкәтауның XIII-XIV гасырлардагы үсеш дәрәҗәсен ачык күрсәтә. Җүчи (Алтын Урда) тәңкәләре, һинд солтаннарының 1340-1341 елларга караган алтын динарлары, алтын, энҗе, бәллүр һ.б.лардан эшләнгән зәркән әйберләр моны бигрәк тә ачык чагылдыра. Алтын Урда чорында Җүкәтауның сәяси-икътисадый һәм мәдәни әһәмияте турында тагын язма чыганаклар да сөйли. Шәһәр XIV гасыр рус елъязмаларында Жукотин шәһәре буларак телгә алына, шул ук чордагы Европа карталарында да әлеге кала билгеләнгән була.

Фотолар: drevnosti.archeogeo.ru, Н. Нәбиуллина китабы, Александр Ефремов. РЕКЛАМА

ЧИСТАЙДА ҺӘМ АНЫҢ ТИРӘ-ЮНЕНДӘГЕ БОЛГАР ҺӘЙКӘЛЛӘРЕ

«Жукотин» (Җүкәтау) шәһәрлеге – федераль әһәмияттәге археология һәйкәле. Төрле елларда галимнәр биредә ныгытма фрагментларын, хуҗалык корылмалары нигезләрен, болгар эретү миче калдыклары, бизәнү әйберләре, акчалар, керамика кисәкләре таба. Шәһәрлек Чистай үзәгеннән якынча сигез километр ераклыкта, Данауровка авылына якын җирдә урнашкан.

Нарат-Елга авылы янындагы шәһәрлек (XI–XIII гасырлар). Чистайдан көньяк-көнбатышка таба 10 километр ераклыкта урнашкан. Галимнәр биредә катлаулы саклагыч системага ия хәрби кирмән торган дип исәпли.

Иске Роман шәһәрлеге. Туфрак өемнәре һәм чокырлар белән әйләндереп алынган шәһәрлектә тимерчелек эшчәнлеге эзләре калган. Шәһәрлекнең ныгытылган өлеше чикләрендә галимнәр зур һөнәрчелек бистәләре булуын да ачыклый. Биредә «ханнар зираты» да урнашкан, анда XIV гасырга караган дистәдән артык эпиграфия һәйкәле (кабер ташы) бүгенге көнгә кадәр сакланып калган. Шәһәрлек Чистайдан көньяк-көнбатышка таба 15 километр ераклыкта, «Казан – Оренбург» юлына якын җирдә урнашкан.

Чистай шәһәр тарихы музее (К.Маркс ур., 8). Биредә сезгә Җүкәтау тарихы турында сөйләрләр һәм әлеге борынгы чорларның кыйммәтле ядкәрләре – 800 еллык көбә кием, Болгар һәм Алтын Урда уклары очлыкларын һәм башкаларны күрсәтерләр.



<u>Чистайда шулай ук музей-тыюлыкның түбәндәге объектлары белән танышырга мөмкин:</u>

Музей-күргәзмә комплексы (К. Маркс ур., 15), Борис Пастернакның мемориаль музее (Ленин ур., 81), «Укытучылар йорты» Әдәби-мемориаль музее (К. Маркс ур., 28), Гаяз Исхакыйның тарихи-мемориаль һәм этнография комплексы (Яуширмә авылы).

1924 елда Җүкәтау урынында хәзинә табыла. Анда алтын беләзекләр, брошка, бөти футлярлы, сөрмә савыты (капкачы ныклап ябыла, челтәрләп бизәлгән), энҗе бөртекләре, киемгә тегелә торган алтын тәңкәләр, ике алтын кадак, тау бәллүрен шомартып ясалган ташлар, һинд солтаннарының 1340–1341 елларга караган ике алтын динары була.



Әлеге мәчет үзенең тыйнаклыгы һәм гадилеге белән аерылып тора – ак таштан, чатыр түбә астында төз манара, ярымай...

ТҮБӘН БӘРӘСКӘДӘГЕ ТАШ МӘЧЕТ

1769 ЕЛГЫ ТӨЗ БИНА

Таш мәчетләр архитектурасы шул заманның рус архитектурасы йогынтысында формалаша. Түбән Бәрәскәдә 1769 елда салынган мәчет Казандагы әл-Мәрҗани мәчетен хәтерләтә. Икесе дә татар архитектура традицияләре белән Петербург барокко кушылмасыннан гыйбарәт. Авылның калкулыклы ачык урынында төзелгән мәчет бик матур булып күренеп тора. Аның кырыс матурлыгы белән кызыксынучылар бирегә ераклардан килә.

Фото: Александр Ефремов





ҖИМЕРЕРГӘ ЯРАМЫЙ

Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылындагы таш мәчетне җимерү өчен, совет чорында тракторлар һәм авыр техника җәлеп ителгән, дип сөйлиләр. Ләкин омтылышлар барып чыкмый. Мәчетнең борынгы катына җиткәч, аны сүтә алмыйлар: кирпечне берәм-берәм алып булмый – бары тик ишәргә генә кала. Ләкин, бәхеткә, әлеге өметсез эшне ташларга тәкъдим итүче табыла. Шуңа мәчетнең төп өлеше сакланып кала.

ПАТШАБИКӘ РӨХСӘТЕ БЕЛӘН

Күз алдына китерегез: әлеге диварлар 250 ел тора – төзелешкә ныклык бирү өчен төзүчеләр измәгә чи йомырка салган, аны Борнаевлар заводына авыл кешеләре җыеп китергән. Нәкъ менә шул сәүдәгәрләр династиясенә нигез салучы Ибраһим Борнаев патшабикә Екатерина II дән үзенең туган авылында ике катлы таш мәчет салырга рөхсәт алуга ирешкән.

Казанда тагын бер елдан соң салынган әл-Мәрҗани мәчетенә исем биргән Шиһабетдин Мәрҗани үзенең бер хезмәтендә болай дип яза: «Авыл уртасындагы таш мәчетне әлеге авыл кешесе Ибраһим бине Йосыф бине Аснай бине Исәнкол бине Борнагол 1183 (1769) ел ахырында камил һәм бик яхшы халәттә, чуен баскычлар белән салдырган».



ҖИРЛЕ МӨСЕЛМАННАРНЫҢ КӨЧ ТУПЛАУ УРЫНЫ

Татарстанның иң борынгы таш мәчетенең үзенең беренчел кыяфәтенә никадәр дәрәҗәдә якын булуында, әлбәттә, авыл кешеләренең өлеше бик зур, реставрация идеясен алар күтәреп чыга. Мәчетне 2018–2020 еллар дәвамында төзекләндерәләр. Яңартылганнан соң мәчет мәхәллә халкы һәм мөсафирлар өчен бик уңайлы урынга әйләнә, алар бирегә намазга йөри, аралаша һәм үзләрен борчыган мәсьәләләр турында сөйләшә башлый. Мәчет тарихи дини объект кына булып калмый, бәлки кабат җирле мөселманнарның көч туплау урынына да әйләнә.

Нәкъ менә шул сәүдәгәрләр династиясенә нигез салучы Ибраһим Борнаев патшабикә Екатерина II дән үзенең туган авылында ике катлы таш мәчет салырга рөхсәт алуга ирешкән.



КАЗАНДА ӘЛ-МӘРҖАНИ МӘЧЕТЕ

Шәһәрнең иң борынгы мәчете 1770 елда беренче дин тотучылар өчен ишекләрен ача – бу хәл төзелешкә рөхсәт биргән Екатерина II патшабикәнең Казанга сәфәреннән соң дүрт ел узгач була.

Фото: ru.wikipedia.org, putidorogi-nn.ru

Казанда чагында патшабикә бай сәүдәгәр һәм эшмәкәрләрдән торган татар делегациясен кабул итә һәм аларның мөселманнарны кысу-җәберләүдән яклау һәм бистәдә ике таш мәчет төзелешенә рөхсәт бирү турындагы гозерен тыңлый. Илдә төрле диннәргә хәерхаһлы Екатерина II Казан губернаторына төзелеш эшләрендә татарларга каршы төшмәскә боера.

Мәчет төзелешенә биш мең сум акча җыела. Каюм Насыйри язмаларына караганда, бирелгән мөмкинлектән тизрәк файдалану өчен, төзелеш бик зур ашыгычлык белән алып барыла. Ул шулай ук «...эш манараны торгызуга барып җиткәч, аның биеклеге өчен борчылган шәһәр хакимияте Екатерина IIгә хат юллый», дип тә яза. Анда: «Син мөселманнарга мәчет төзергә рөхсәт бирсәң дә, алар аны бик биек итеп төзи», – дип зарланалар. Моңа каршы патшабикә: «Мин аларга төзелешкә җирдә урын бирдем, ә һавада биеклеккә күпмегә күтәрелү алар иркендә, чөнки күкләр минем биләмәгә керми», – дип җавап бирә.

Ачылуга гыйбадәтханә үзәк, җәмигъ мәчетенә әйләнә, озак вакыт дәвамында татар халкының рухи тормышы үзәге санала. Бүген ул шулай ук мөселманнарны берләштерүдә мөһим роль уйный. Мәчет 1850–1889 елларда имам булып хезмәт иткән Шиһабетдин Мәрҗани исеме белән атала. Моңа кадәр төрле елларда «Әфәнде мәчете», «Беренче җәмигъ мәчете», «Иске таш мәчет», «Юныс мәчете» (мәхәлләдә сәүдәгәр Юнысовлар династиясе яшәгән һәм мәчетне тотуга акча биргән) дип аталып йөртелгән.

Традиция буенча әл-Мәрҗани мәчетендә үзләренең күпьяклы тирән белемнәре белән аерылып торган күренекле татар дин әһелләре имам булып эшли. Төрле елларда бередә, аерым алганда, Тәлгать Таҗетдин, Равил Гайнетдин, Госман хәзрәт Исхаков имам булып хезмәт иткән.

Бина урта гасыр татар архитектурасы традицияләренә ярашлы рәвештә түбәсендә манара утыртылып ясалган, бередә провинциаль барокко өслүбе дә чагылыш тапкан. Ике катлы ике залы мәчетнең өч ярусы манарасы бар. Фасад һәм интерьерлар бизәлешендә «Петербург» бароккосына хас архитектура бизәкләре татар декоратив сәнгатенең орнаменталь мотивлары белән ярашкан. Мәчетнең архитекторы Казанның беренче профессиональ архитекторы Василий Кафтырев булган дип санала.

Совет чорында әл-Мәрҗани Казанда эшен туктатмаган бердәнбер мәчет була. 2004–2007 елларда мәчет тулысынча реставрацияләнә.

Мәчеттә Казан ханлыгы чорына караган Мөхәммәдгали бәкнең кабер ташы саклана.



«Мин аларга төзелешкә җирдә урын бирдем, ә һавада биеклеккә күпмегә күтәрелү алар иркендә, чөнки күкләр минем биләмәгә керми».

МӘЧКӘРӘ АВЫЛЫНДАГЫ БОРЫНГЫ МӘЧЕТ

Классицизмның башлангыч чоры, барокко элементлары да кергән – Мәчкәрә авылы мәчетен тарихи архитектура белгечләре әнә шулай тасвирлый. Һәм әлеге гыйдабәтханә республиканың кирпечтән салынган иң борынгы дини корылмаларыннан берсе дип тә өстиләр. Ләкин бер генә белешмәлектә дә сез биредәге вакыт сулышы чагылышы, зәңгәр гөмбәзләрдә кояш нурларының уйнавы, идән такталарының рәхәт шыгырдавы һәм тавышыгызның тыныч кайтаваз булып залларда йөрүе турында укый алмассыз.

– Әни белән монда кереп йөргәндә миңа биш яшьләр чамасы иде – монда бик матур ярымтүгәрәк, бормалы баскыч барлыгын хәзергәчә хәтерлим әле! Аны бер кадак та какмыйча ясаганнар. Озак вакытлар мәчеттә колхоз амбары булган, аннан соң эш кирәк-яраклары, ашлама саклаганнар.

Бу Мәчкәрә авылының хәзерге мәчетенең имамы, Кукмара районы Аксакаллар шурасы рәисе Мөнир хәзрәт Йосыповның балачак хатирәләре. Әле күптән түгел генә мәчетнең икенче катында аның сүз раслаучы дәлилләрне – ашлык саклау эзләре табарга була иде. Зур намаз залында өлешчә ишелә башлаган агач түшәмә астында игътибарлырак кешеләр бодай бөртекләре таба алган. 1920 нче еллардан башлап бина үз максатында кулланылмаган. Монда хәтта тавык фабрикасы да урнашкан булган, дип сөйлиләр. 1930 нчы елларда мәчет манарасыз калган... Әйе, дин тыелган заманда әлеге изге урын санга сугылмаса да, мәчет исән калган. Бүген ул Татарстанның иң борынгы җәмигъ мәчетләренең берсе булып тора.

ИСКИТКЕЧ ТАРИХ

Мәчкәрә мәчете манзарасы кай урыннан матур булып ачылганын беләсезме? Ерак түгел генә урнашкан Үтәмешевларның нәсел утарыннан. Сүз уңаеннан, гыйбадәтханә төзелеше 1791 елда үз заманының күренекле эшкуары –

Фото: Александр Ефремов

беренче гильдия сәүдәгәр Габдулла Үтәмешев акчаларына төзелә башлый. Ике елдан соң бирелә беренче намаз укыла.

Мәчетнең революциягә кадәрге тарихы бик матур була. Хәзерге вакытта кечкенә генә Мәчкәрә авылының 19 гасырда эре мөселман агарту үзәгенә әверелә алуын күз алдына китерүе дә кыен! Әлеге мәдрәсәдә белем алу бәхет һәм зур горурлык саналган. Анда укыган шәкертләрнең күбесен бүген без бөек фикер ияләре, мәгърифәтчеләр, дин белгечләре исемлегенә кертәбез. Алар арасында – Габденнасыйр Курсави, Хөсәен Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗанинең бабасы – Сөбхан бине Абдулкәрим әл-Мәрҗани…

БЕРГӘ, КҮМӘКЛӘП…

Зур булмаган стендка урнаштырылган фотоларда мәчетнең тарихын күрергә мөмкин. Әнә Мәчкәрәнең борынгы күренеше. Игътибар итегез әле: ерактан матур булып мәчет күренеп тора! Шуңа күрә югалганы урынына яңадан кыскарак итеп ясалган манара тарихи чынбарлыкка туры килә.

2005 елда гыйбадәтханәне авыл кешеләре реставрацияли башлый. Ләкин төзекләндерүне үз көчләре белән башкарып чыга алмыйлар – мәчетне яңарту өчен таләп ителгән эш күләме артык зур була, шуңа күрә әлегә ул авария хәлендә санала. Бәхеткә, проблема хәл ителәчәк. Мәчкәрә мәчете «Мирас – Наследие» мәдәни мирасны саклау программасына кертелгән. Тиздән биредә төзекләндерү буенча зур күләмле эшләр башланачак: нигезне һәм диварларны ныгыту, гидроизоляция ясау, су торбалары кертү… Реставрацияне иганәчеләр хисабына эшләргә ниятлиләр – мәчет эшләрен бабаларыбыздан калган күркәм гадәт буенча бергә, күмәкләп җиңеп чыгачаклар. Һәм инде ике елдан соң Мәчкәрә мәчете манарасыннан, бөтен мөселманны намазга өндәп, күптән көтелгән азан тавышы яңгыраячак. Т

Мәчетнең революциягә кадәрге тарихы бик матур була. Хәзерге вакытта кечкенә генә Мәчкәрә авылының 19 гасырда эре мөселман агарту үзәгенә әверелә алуын күз алдына китерүе дә кыен!

ИСЛАМ ЯДКӘРЛӘРЕ

КАЗАНДАГЫ ГАЛИ МӘЧЕТЕ

Иске Татар бистәсендәге бишенче җәмигъ мәчете – республикабыздагы төп мөселман дин йортларыннан берсе. Татар дини архитектурасы һәйкәле XVIII–XIX гасырлар чигендә сәүдәгәр Муса Мәмәш акчасына салына. Тик ни өчен соң аны «Гали мәчете» дип йөртәләр?

1798 ел. Күренекле сәүдәгәр-сәнәгатьче Муса бине Мөслим бине Мәмәш Казанда Печән базары тирәсендә таш мәчет салдыра. Иске Татар бистәсендә бу инде бишенче мәчет була һәм ул чакта Болак артының көньяк-көнчыгышына күпләп күчеп утыра башлаган мөселман сәүдәгәрләрен җәлеп итүче беренче үзәккә әйләнә.

БЕР ГАСЫРЛЫК ТАРИХ

Сигез кырлы нәфис манара һәм классицизмның башлангыч чорына хас формалар, эчендә – ике намаз залы. Әлеге мәчет баштарак шундый була. Исемнәре дә төрле – «Муса бай мәчете», «Тихвин урамындагы таш мәчет», «Бишенче мәхәллә мәчете»... 1882 елдан мәчетнең архитектурасы акрынлап үзгәреш кичерә башлый: башта сәүдәгәр Уразаев бинаның көньягына өстәп янкорма төзетә, ә инде 1897 елда сәүдәгәрләр Галиев белән Иманкулов мәчетне тагын да зурайту өчен акча бирә.

Гали мәчетенең иң беренче имамнарыннан берсе күренекле дин белгече, галим Сәгыйть бине Әхмәт була. Аның өч улы белән оныгы да дин юлын сайлый. Шулай да дин йортының иң гөрләгән чоры атаклы дин эшлеклесе, мәгърифәтче, педагог-ислахчы Галимҗан Галиев (Баруди) исеме белән бәйле. Мәчеткә бәйләнеп калган «Гали» сүзе – аңа хөрмәт билгесе, ә бүген исә әлеге бөек шәхес истәлегенең чагылышы.

Баруди Гали мәчетен 1882 елда җитәкли башлый һәм анда 1917 елгы революциягә кадәр хезмәт итә. Бу вакыт эчендә иман йорты Казан татарларының иҗтимагый-сәяси тормышы үзгәренә әверелә. Баруди мәчет каршында яңа ысул белән укытучы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ача, ул Россиядә иң зур мәдрәсәгә әйләнеп, даны чит илләргә кадәр тарала.

Фото: Александр Ефремов, ru.wikipedia.org, naslediekazan.ru, yandex.ru, ТР Диния нәзарәте

ИМАН ҺӘМ АЛГАРЫШ

Галиәсгар Камал, Нәкый Исәнбәт, Хөсәен Ямашев, Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Фатыйх Әмирхан – алар барысы да «Мөхәммәдия»дә белем алган күренекле шәхесләр. 36 ел эчендә аны меңнән артык шәкерт тәмамлаган.

Сүз уңаеннан, баштагы чорында «Мөхәммәдия» үз юнәлешендәге уку йортларыннан артык аерылып тормый. Әмма Баруди уку программасына математика, география, табигать белеме, физика, тарих кебек дөньяви предметларны кертүне алга сөрә. Шәкертләр газета да чыгара, ә 1906 елда мәдрәсәдә профессиональ театр оештырыла! Мәдрәсәнең үз яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы да була, кышын анда шәкертләр тимераякта шуа. Әйе, Гали мәчете каршындагы мәдрәсәдә традицияләр белән заманчалык бергә үрелеп бара...

Хакимияткә советлар килгәч, мәчет тә, мәдрәсә дә эшен туктата. 1930 нчы елларда иман йортының манарасы һәм көньяк башнясы юкка чыга. Бина үзгәртелеп корыла, эчке ягы җимерелә, таушала, талана. Бинада кунакханә, соңрак коммуналь хуҗалык хезмәте урнаша, бары тик 1997 елда гына мәчет дин тотучыларга кире кайтарыла.

Бина шактый җимерек, таушалган хәлдә була, шулай да тәҗрибәле осталар, зур тырышлык куеп, әлеге архитектура һәйкәленең тышкы ягын беренчел халәтенә

кайтаруга ирешә. Ә менә эчке якны, интерьерны, кызганычка каршы, кайчандыр гамәлдә булган кыяфәттә торгыза алмыйлар. Шулай да яңа образ очраклы түгел – ул тарихи елъязмаларга, хезмәтләргә таянып эшләнелә. 2015 елның 22 декабрендә яңартылган Гали мәчете, ниһаять, реставрациядән соң беренче мәртәбә җәмәгать намазы өчен ишекләрен ача.

Шулай да дин йортының иң гөрләгән чоры атаклы дин эшлеклесе, мәгърифәтче, педагог-ислахчы Галимҗан Галиев (Баруди) исеме белән бәйле.

ОЛЫ ЕЛГАДАГЫ АГАЧ МӘЧЕТ

Балык Бистәсе районы Олы Елга авылындагы борынгы агач мәчеттә «Татарстан» журналистларының инде әллә ничә тапкыр булганы бар: озакка сузылган динсезлек чорыннан соң 1980 нче еллар азагында изге бина тәртипкә китерелгәч тә; 1990 нчы елларда ул мәдәни мирас объекты итеп танылгач та; һәм былтыр, 2021 елда, яңартылган һәм реставрацияләнгән мәчет мәхәллә халкы һәм Казаннан килгән дәрәҗәле кунакларга ишеген ачкач та.

БЕРЕНЧЕ ТАРИХ. АМБАР

Мөселман гыйбадәтханәсен 1879 елда указлы мулла Вәлиулла Галиев Казан губерна идарәсе раслаган проект буенча төзетә. Дингә каршы көрәшнең көчәюе белән яманаты чыккан 1937 елга кадәр ул мәхәллә халкына хезмәт итә. Хәтта тирә-якта Олы Елганы үз атамасы белән түгел, «мәчетле авыл» дип кенә йөртәләр. Әмма 1937 елда, башка күп кенә мәчет кебек үк, бирелгәнсен дә ашлык амбарына әйләндерәләр.

– Мин хәтерлим әле, – дип сөйләгән иде бервакыт мәчет хакында язарга килгән «Татарстан» журналына мулла Таһир Гайнетдинов, – балачакта без бу амбарда качыш уйный идек. Манарадагы ядрә эзләрен дә хәтерлим, күрәмсең, аны кемдер мишень итеп файдаланган...

ИКЕНЧЕ ТАРИХ. МОГҖИЗА

Олы Елга халкының тарих һәм легендалары журнал төпләмәләрендә хәзер дә саклана. Шуларга күз салабызмы?

– Узган гасырның 30 нчы елларында була бу могҗиза... – дип сөйләделәр безгә. – Бер җәйдә мәчет манарасын кисәргә дип дәһриләр килә. Кинәт күктә кара болыт пәйда була, бик көчле җил чыга, әлеге бәндәләр манарага менә алмый, кире китә, ул җимерелми кала.

Фото: Александр Ефремов



ӨЧЕНЧЕ ТАРИХ. ИСЛАМ ТЫЛСЫМЫ

– Авыл халкын Әбүбәкер мулла дингә китерә, – дип сөйли Олы Елга музее директоры Хәтимә Солтанова. – Ул безгә 1393 елларда Әлкидән килә, ул вакыт әле авыл оешып кына килә. Әбүбәкер мулла Чулманны чапанына утырып кичкән, диләр. Моны күреп торган кешеләр аның тылсымлы көченә шаккаткан һәм ана ияргән. Борынгы бабаларыбыз шул рәвешле ислам динен тота башлаган.

ДҮРТЕНЧЕ ТАРИХ. ИЗГЕ ДОГА

– Моннан берничә ел элек мәчеткә бер кеше килеп керде, – дип искә алган иде Таһир хәзрәт Гайнетдинов. – Безнең белән күрешеп, намаз укыгач: «Аллаһка шөкер! Әтиемнең телэге кабул булды!» – диде. Совет чорында авыл яныннан үткәндә, минераль ашлама складына әйләндерелгән мәчетне күреп, бик диндар әтисе елап җибәргән икән. Һәм Аллаһы Тәгаләгә ялварган: «Йа Раббым! Бу мәчетне иман нуры яктыртсын иде! Ул кабат изге урынга әйләнсен иде!» – дип дога кылган. Улына исә: «Килер бер көн, бирегә халык кабат йөри башлар әле. Улым, биредә кабат намаз укылачагына мин ышанам», – дигән. «Ул чакта бу бөтенләй тормышка ашмаслык хыялга охшаса да, хәзер мин әтием догасының кабул ителүен күрәм. Аллаһы Тәгаләдән ул нәкъ менә шуны сорап дога кылды бит, димәк, мәчетнең яңадан торгызылуында аның да өлеше бар», – диде мөсафир.

БИШЕНЧЕ ТАРИХ. ТУГРЫ САКТА

Тагын бер риваятьтән күренгәнчә, мәчетнең ярымае һәрвакыт кыйбла ягына карап торган, шунлыктан авылда беркайчан да бернинди табигать бәла-казасы булмаган. Авыл халкы, мәчет үзләрен бөтен афәтләрдән саклый, дип ышана.

АЛТЫНЧЫ ТАРИХ. ҮҖӘТЛЕК

Яңартылган мәчет ачылышыннан «Татарстан» журналистлары тагын бер тарихка баеп кайтты. Биредә яшәгән Сөнгатулла Юнысов үзенең тугыз баласы белән мәчеткә һәрчак ярдәм иткән: үз акчасына буяган, ремонтлаган, үҗәтләнеп, аны кабат мәхәллә халкына кайтару артыннан йөргән. Бу турыда безгә Сөнгатулланың кызы һәм оныгы сөйләде.

«Бабабызның мәчете ачылды, Аллаһка шөкер! Мин аны буяганымны яхшы хәтерлим әле...» – дип күз яшьләрен тыя алмады ханымнарның берсе.

«Мәчетне халыкка кайтаруны даулап, 1980 нче еллар азагында әтием Уфага, Мәскәүгә һәм хәтта Ленинградка барган. Гап-гади авыл кешесе барыбер үз дигәненә иреште: 1988 елда мәчет тәртипкә китерелде», – ди Сөнгатулланың кызы Исламия Хәйретдинова.

ҖИДЕНЧЕ ТАРИХ. МАКСАТКА ИРЕШҮ

Олы Елгадагы гыйбадәт йорты – Татарстанда иң борынгы агач мәчетләрдән берсе, XIX гасыр агач архитектурасы үрнәге. Шуңа күрә реставрация эшләре бик катлаулы була һәм күп көч таләп итә. Белгечләр бураның чын бүрәнәләренең 70 процентын саклап кала. Чорма түшәменең өрлекләрен, бәпкәләр (атламалар) системасын, манара нигезен нәкъ элеккечә итеп эшлиләр. Намаз залларының интерьерларын бик уйлап яңарталар. Мәчетнең тышкы кыяфәтен саклап калалар. Хәзер ул җылытыла, тәһарәтханәсе дә бар.

Кыенлыклар да җитәрлек була. Мәчетне сүтеп, танылган архитектор Александр Поповка Вологда өлкәсенә алып китәләр. Әмма бер айдан соң белгеч акчаны ике тапкыр арттыруны сорый, мәчет бүрәнәләре исә кадерсезләнеп җирдә таралып ята. Кире алып кайтырга карар кылалар. Таһир хәзрәт үзе бара, Кама Тамагы районы Архангельские Кляри авылыннан китерелгән чиркәү бүрәнәләренең дә реставрация көтеп җирдә аунап ятуын күрә. Әле һаман да шунда ята, диләр...

Әмма барысы да яхшы тәмамлана. Проектны Казанның «Берләштерелгән төзелеш компаниясе» реставрацияләү оешмасы җиренә җиткереп төгәлли.

«Мәчетне бабаларыбыз моннан 140 еллап элек төзегән. Ул чактан бирле бик күп вакыт үткән. Шулай булса да, уртак тырышлык белән без бинаны саклап калдык һәм яңадан торгыздык», – диде реставраторларны бүләкләгәндә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов.

«Мәчетне бабаларыбыз моннан 140 еллап элек төзегән. Ул чактан бирле бик күп вакыт үткән. Шулай булса да, уртак тырышлык белән без бинаны саклап калдык һәм яңадан торгыздык», – диде ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов.

«МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ: ГАСЫР КИЧЕП...

Руфия Фазылова

Вакыт иртәнге сигезенче ярты. Туктаусыз ачылып-ябылып торган мәдрәсә ишегеннән һәркем ашыкмый гына үтә. Этеш-төртеш, кабалану юк, хәтта кычкырып эндәшмиләр дә. Бер-берсенә елмаеп: «Әссәламугаләйкүм», – дип сәлам биргән яшьләр ишек төбендә үк аяк киемен алыштыра. Әйе, монда бүтән дөнья, бүтән яшьләр... Итагатьле, диләр бездә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә баргач, бу сүзнең асылына төшендем.

«ЮГАРЫ ҺӨНӘРИ ДИНИ БЕЛЕМ БИРӘБЕЗ»

Гаҗәп, әмма шулай: моннан бер гасыр элек салынган баскычлар, кирпеч диварлар, мичләр шул килеш саклланган. Узган ел төгәлләнгән реставрациядән соң фасадка беркетелгән фарсы язулы такта да урынында калган. (XX йөз башында «Мөхәммәдия», халык мәдрәсәсе булганга, рәхмәт тактасы белән бүләкләнә)

Тарих турында сүз чыккач, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең үткәне хакында искәртеп узарга кирәктер. Россиянең иң борынгы ислам уку йортларыннан берсе ул. 1882 елда күренекле дин эшлеклесе, мәгърифәтче Галимҗан Барудиның этисе Мөхәммәтҗан Галиев башлангычы белән төзелгән мәдрәсә тиз арада татарлар арасында гына түгел, күп кенә төрки халыклар арасында да танылу ала. Биредә укырга теләүчеләр шуның кадәр күбәя ки, сәүдәгәр Үтәмешев 1885 елда - икенче катны, 1886 елны өченче катны агачтан өстәп кордыра. Мәдрәсәнең даны Россия мөселманнары арасында тиз тарала. Монда татарлар гына түгел, башкорт, казах, кыргыз, калмыклар һәм башка төрки халыклар да белем алырга атлыгып тора. 1901 елда шәһәр башлыгы Александр Лебедев өч катлы таш мәдрәсә төзелешенә рөхсәт бирә. Беренче ташны салырга ишан Зәйнулла Рәсүлев тә килә. Дини уку йортының үз ашханәсе, хастаханәсе, бакчасы, урманчылыгы да була.

Алдынгы карашлы мәдрәсә шәкертләре «Мөхәммәдия», «Телескоп», «Манзаратул-галям» газеталарын чыгара башлый. 1906 елда хәтта «Сәйяр» һөнәри театр труппасы оештыралар. Ни кызганыч, шулай утыз алты ел дәверендә меңләгән шәкерткә белем иңдергән, югары квалификацияле белгечләр әзерләгән уку йортын 1918 елда ябалар. (Сәбәбе аңлашыла: илдә алып барылган сәясәт.) Мәдрәсә шәкертләре арасында Хөсәен Ямашев, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт кебек мәшһүр шәхесләр дә була.

Мәдрәсәдә «яңа тарих», «иске тарих» дип сөйләшәләр. «Мөхәммәдия» яңадан 1993 елда гына ишекләрен ача. Үзгәртеп кору чоры башлангач, дин әһелләренә дә яңа мөмкинлекләр туа. 1990 елның 29 ноябрендә «Иман» мәркәзе оеша. «Мөхәммәдия»не яңадан торгызу, аның иң абруйлы дини уку йорты, шәрыкның университеты икәнлеген искә төшерү нәкъ менә шул вакытта башлана. Нәтиҗәдә, «Иман» мәркәзе өч ел дәвамында әзерлек эшләре алып бара – мәдрәсәне ачу өчен җирлек булдырыла. 1993 елның 6 июлендә, оештыручыларның гомуми җыелышында, «Мөхәммәдия» Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөдире итеп Вәлиулла хәзрәт Якупов сайлана. Яңа җитәкчелеккә шактый кыенлыклар белән очрашырга туры килә – иң беренче булып бина мәсьәләсе килеп баса, уку әсбаплары юклык, мөгаллимнәр составын туплау... Аллаһның рәхмәте белән болар барысы да җайлана. Тиз арада мәдрәсәнең абруе бөтен илгә тарала. Нәтиҗәдә, шәкертләрнең килеп уку географиясе ел саен арта бара – Омск, Ерак Себер, Төмән, Пенза, Оренбург, Самара, Түбән Новгород, Чиләбе, Ханты-Манси, Чечен, Чита, күрше өлкәләр турында әйткән дә юк... БДБ илләре: Таҗикстан, Казахстан, Үзбәкстан, Украина кебек җирләрдән дә мөселманнар килә. Бүген кайсы гына төбәкне алсаң да, «Мөхәммәдия»не тәмамлаган шәкертләрне очратырга мөмкин. Аларның күбесе имам, йә булмаса мөгаллим вазыйфасында хезмәт итә.

– Дини уку системасы баскычларга бүленгән: башлангыч, урта, югары, – диде «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең укыту эшләре буенча директор урынбасары Зөлфәт Габдуллин. – «Мөхәммәдия»нең көндезге бүлеген тәмамлаучылар югары һөнәри дини белем алып чыкса, кичке һәм читтән торып уку бүлеге шәкертләре урта һөнәри белем үзләштерә. Көндезге бүлектә утыз яшькә кадәрле яшьләр белем алса, кичке һәм читтән торып уку бүлегендә көндез эшләүче яки башка уку йортларында белем алучы ир-егетләр, ханымнар, туташлар укый. Араларында фән кешеләре, галимнәр дә бар.

Фото: ТР Диния нәзарәте, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе. РЕКЛАМА

Мәдрәсәдә барлыгы 25 остаз эшли. Аларның сиксән проценты «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган. (Бу элек XIX гасырда да шулай булган.) Шул ук вакытта һәр остазның дөньяви югары белеме дә бар. Мөгаллимнәр турында сүз чыккач, шунысын да әйтергә кирәк: гел белемнәрен күтәрәләр, дини мәгариф өлкәсендә дәреслекләр нәшер итәләр. Алар буенча «Мөхәммәдия»дә генә түгел, башка дини уку йортлары шәкертләре дә белем ала.

Мәдрәсәдә өч телдә – татарча, гарәпчә, русча белем-тәрбия бирәләр. Соңгы елларда татар теленә аеруча игътибар арткан.

– Уку татар телендә генә барса, рус телен татарча укыган кебек булыр иде, – диде Зөлфәт Габдуллин. – Гарәп теленә бәйле фәннәр, әлбәттә, гарәпчә укытыла. Аерым фәннәр генә рус телендә алып барыла. Ә тәрбия мәсьәләсе, укудан тыш чаралар гел татар телен үстерүгә кайтып кала.

Без Тукайның туган көне уңаеннан оештырылган шигырь уку бәйгесенең финалына туры килдек. Мәдрәсә ул көнне мәртәбәле кунакларны кабул итте. Баксаң, мондый чара ел саен була икән.

«БЕР ГЕНӘ МӘЗҺӘПНЕ ТАНЫЙБЫЗ»

Укыту программасына күз салам: көндезге бүлектәге шәкертләр 56 фән укый. Шуның яртысы дөньяви фән булса, яртысы дини фәннәр икән.

– Сезнең уку йортын тәмамлаган шәкертләр киләчәктә кем булып эшли ала? – дим директор урынбасарына.

– Иң әүвәл бер үзенчәлекне аңларга кирәк: безнең төп максат – әхлаклы, тәрбияле, киң карашлы, дөрес фикер йөртүче шәхес тәрбияләү. Ассызыклап әйтәм – тәрбиягә зур басым ясала. Ә конкрет һөнәргә килгәндә, шәкертләребезгә дин өлкәсендә эшләргә бөтен мөмкинчелекне бирәбез. Шул ук имам, остаз, тәрбияче булыпмы. Безнең бит әле хәләл өлкә, Дания нәзарәтенә караган башка оешмалар бар. «Хозур» телевидениесе, радиосы, «Зәкят», «Хаҗ» юнәлеше булсынмы, сайлау мөмкинлеге зур. Шул ук вакытта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаучылар гарәп телен камил дәрәҗәдә белә. Димәк, тәрҗемәче, гарәп теле укытучысы булып та эшли алалар. Гарәп телен КФУда, Көнчыгыш телләр факультетында өйрәтәләр. Безнең укучылар алар белән олимпиадаларда, ярышларда очраша. Һәм аларның нәтиҗәләре югары.

Көз көне «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, зурлап, үзенең 140 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк. Реставрация эшләре дә әлеге зур датага бәйле. Әле төзекләндерү эшләре дәвам итә. Ул тагын да зураячак, заманчалашачак.

Мәдрәсәнең укыту эшләре буенча директор урынбасары Зөлфәт Габдуллин белән бер четерекле тема хакында сөйләштек – мәзһәпләр. Чикләр ачылганнан соң, Россиядә, шул исәптән Татарстанда да төрле мәзһәп буенча яшәү күзәтелә.

– Безнең мәдрәсәдә Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча белем бирелә, – диде Зөлфәт хәзрәт. – Бу мәдрәсәнең концепциясенә кертелгән, юнәлеш билгеләнгән. Шәкертләр укырга кергәндә имза куя – мәдрәсәнең уставы белән таныштым, аның белән килешәм, диләр. Ә уставта нәкъ Әбү Хәнифә мәзһәбе турында сүз бара. Кеше монда килгәч башка фикерне тарата икән, димәк, ул уставка каршы килә. Һәм мәдрәсәдән куылырга мәҗбүр була. Без моңа бик җитди карыйбыз.

...Итагатьле, дигән идем сүз башында. Тагын әле, мәрхәмәтле, дип тә өстисе килә. Ел саен «Мөхәммәдия» шәкертләре балалар йорты, картлар йортларына бара. Күңел җылысын гына түгел, төрле кирәк-яраклар да бүләк итәләр. Чын ислам кануннары белән тәрбияләнүче шәкертләргә кызыгып кайттым. Нинди дәрәҗәле уку йортында, тирән белемле остазларда белем алалар бит!

УСЫ: КЫЙБЛАГА КАРАП...



Фото: Александр Ефремов

УСЫ

Актаныш районы Усы авылы халкы быел Ураза гаетен аерым бер дулкынлану белән каршылаган – 1995 елда төзелгән мәчет бинасы ниһаять төзекләндерелгән. Дөрес, әле тулысынча түгел – манарасы белән түбәсен яңартасы калган. Тик татарда «Башланган эш – беткән эш» дигән мәкаль бар. Усылылар якын киләчәктә анысы да булыр дип өметләнә. Актанышның иң борынгы, дини авылларының берсе Усыда булып, җирле халыкның тормышы белән таныштык.

Руфия Фазылова

«МӘЧЕТКӘ ХАЛЫК КӨЧЕ КҮП КЕРДЕ»

Авылга кергәндә үк ерактан мәчет каршы алды. Дөресрәге, иң беренче күзгә аның күгәрә башлаган манаралары чалынды. Авыл халкы шунда көтә дигәч, туры иман йортына юл тоттык. Әле ремонт эшләре төгәлләнеп кенә бара, шуңа күрә эшчеләр дә биредә иде.

Танышуны Усы авылы имамы Фоат абый Шакировтан башладык. Унҗиденче ел имамлык вазыйфасында икән:

– Авылда иң беренче мәчет кайчан төзелгәнен төгәл генә әйтә алмыйбыз, – диде хәзрәт. – Ләкин революциягә кадәр Усыда ике мәчет булган, монысы хак. Кызганыч, алар сакланып калмаган. Мин 1951 елгы, ул биналарның берсен дә хәтерләмим, чөнки аларны сүткәннәр иде инде. Революциягә кадәр төзелгән ике мәчетнең берсе әлеге урында булган. 1995 елда, авыл халкының теләген истә тотып, бирегә яңа гыйбадәтханә төзелде. Яңа мәчет «Мөхәммәтвәгыйз» – минем этинең исемен йөртә. Аның оныгы, абыйның улы була инде, мәчет өчен бура кайтарды. Шул чорда совхоз җитәкчесе булып эшләгән Зиннәт Әхмәевнең дә ярдәме бик зур булды. Төзелеш эшләре белән хуҗалыкта мастер булып хезмәт

1

– Яңа мәчет «Мөхәммәтвәгыйз» – минем әтинең исемен йөртә, – диде Усы авылы имамы Фоат абый Шакиров.

2

Мәчетне төзекләндерүне Усы авылы фермеры Фәнис Нурлыев башлап йөргән.

куйган Шәрип Хәбетдинов җитәкчелек итте. Әти совет заманында да авылда хәзрәт булып торган. Шуның өчен дә мәчетне аның исеме белән атадылар.

Меңләгән бүтән татар авылларындагы кебек үк, совет чорында Усыда җомга намазларын авылның бер йортында укыганнар. Коръән ашлары да туктамаган. Гает намазларын исә ир-атлар авыл зиратына барып укыган.

– Бу мәчетнең салынганын әтиегез күрдеме соң? – дим Фоат хәзрәткә.

– Юк, 1995 елда әти инде вафат иде.

Утыз елга якын вакыт эчендә иман йорты яңартылмаган, тышкы яктан. Эчен исә берничә ел элек такта белән тышлап, буяп куйганнар.

– Элек мәчетне төзеп кую бик гади иде бит, – дип дәвам итте хәзрәт. – Бурасын күтәреп, түбәсен яптылар да кереп намаз укый башладылар. Монда бер нәрсә дә юк иде. Соңыннан инде эчен ясый башладык. Барысын да авылдашлар биргән сәдакага эшләдек. Әлхәмдүлилләһ, безнең авылда халык бик иманлы, яхшы күңелле.

Мәчетне яңарту өчен материалларны сәдака акчасына алсалар, эшләвен Усы авылы ир-атлары башкарган. Бушка. Изге Рамазан аенда әнә шулай зур савапплы гамәл кылганнар.

– Безнең авылдан зур эшмәкәрләр чыкмаган, – диде Фоат хәзрәт. – Шуңа күрә күп акчалар белән ярдәм итүче иганәчеләребез юк. Аллаһның биргәненә шөкер, зарланмыйм: хәлдән килгәнчә һәркем ярдәм итә.

Мәчетне төзекләндерүне Усы авылы фермеры Фәнис Нурлыев башлап йөргән. Авылдашлары аны гел мактап телгә алды. Фәнис абыйның гомер иткән хәләл җефете узган ел вафат булган. Әнә шуңа да ул бу эшкә тотынган.

– Мәчетне тышларга дип калайларны Фоат абый алдан алып куйган иде, – диде Фәнис абый. – Ураза гаетенә кадәр өлгертик, мәчетебез бигрәк мескен хәлдә бит, дидем хәзрәтебезгә. Ул ризалашты. Инде тышын гына түгел, ишек, тәрәзәләрен, капка-коймасын да яңартасы килде. Вотсаптта махсус төркем булдырып, авылдашлардан акча җыюны оештырдым. Дүрт йөз мең сумлап булды. Читтә яшәүчеләр дә хәлдән килгәнчә ярдәм күрсәтте. Аллага шөкер, мәчетебез яктырып, матураеп китте. Инде озакка сузмыйча манара, түбәсен дә яңартасы килә. Аллаһ җүн бирер, дибез.

ШӘҺӘРДӘН - АВЫЛГА

Усы бик зур авыл түгел. (Сүз уңаеннан, Минтимер Шәймиев әнисенең туган авылы ул.) Биредә 91 йорт бар, 235 кеше яши. Дәүләт программасы нигезендә күпфункцияле үзәк салып куйганнар. Аның бер ягында башлангыч мәктәп, икенчесендә мәдәният йорты, китапханә урнашкан. Кызганыч, узган ел балалар бакчасы ябылган. Башлангыч мәктәптә дә дүрт кенә бала белем ала.

Усының зур сөенече – ике ел элек үзәк урамга асфальт салынган. Әлегә кадәр көз-яз көннәрендә авылга керә торган булмаган. Хәзер бу өлешчә хәл ителгән, әмма авылда икенче проблема калган – фермалар бетерелгәнгә, эш урыннары кимегән.

Кая барсак та, яшь гаиләләр белән кызыксынабыз. Усыда алар бармак белән генә санарлык, шуларның берсе – Вәзиевлар. Үткен, бөтен эшне булдыра торган бу гаиләгә чын мәгънәсендә сокландык.

Данияр белән Эльвира өйләнешкәч тә Түбән Кама шәһәрендә яшәгән. Бер-бер артлы ике уллары туган. 2013 елда исә Усыга кученеп кайтканнар.

– Мин – полиция бүлегендә, Эльвира Чаллы шәһәрендәге Идел буе спорт һәм туризм академиясендә эшли иде, – диде Данияр Вәзиев. – Кисәк кенә әтием вафат булды. Шуннан соң шәһәр тормышын калдырып, туган авылга кайтырга булдык. Эльвира да каршы килмәде.

Усыга кайткач, Данияр колхозга механизатор булып урнаша, ә Эльвира балалар бакчасына эшкә керә. Ике кечкенә уллары Камил белән Гадел да бакчага йөри.

Бүген инде малайлар Усы башлангыч мәктәбендә белем ала. Данияр «Саф» җәмгыятендә мал табибы булып эшли, Эльвира Усы мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе вазыйфасын башкара. Ир белән хатын икесе дә югары белем алган. Яшь гаиләнең планнары зурдан – узган ел төп йортлары каршысына яңа нигез салганнар. Хыяллары – шунда зур йорт җиткерү.

– Әти белән әни гомергә мал асраган, шуңа күрә авылга кайткач, без дә баш санын киметмәдек. Әле киресенчә арттырдык, – дип ихаталары белән таныштырды Эльвира. – Ике ел элек мини-ферма программасына кердек, яңа терлек сарае салдык. Яңа «Газель» белән трактор сатып алдык. Техникаларны Данияр йөртә, бер секунд тик утырмый ул.

Вәзиевләр хуҗалыгында унике сыер, бозаусарыклар, кош-корт бар. Сыер санын тагын арттырырга уйлыйлар.

– Төп эш урыныгыз да бар, шуның кадәр малны да карарга ничек вакыт табасыз? – дим Эльвирага.

– Каенанам да бар бит, ул төп ярдәмчебез. Сыерларны иртән аппарат белән савабыз, аннан эшкә чыгып китәбез. Төшкене ашатырга кайтып җитәбез. Шулай бара инде ул, көйләнелгән. Улларыбыз үсеп килә, кул арасына керә башладылар инде.

– Шәһәрдән соң авыл тормышы куркытмады алайса?

– Мин бит авыл кызы, Сарман районында туып-үстем. Кайда да эшләргә кирәк. Монда үз эшебез дә булгач күңелле. Хәере белән йортыбызны җиткереп, сөенеп яшәргә язсын. Иң зур теләк, максат әлегә шул.

3

Вәзиевлар узган ел төп йортлары каршысына яңа нигез салган.

4

Тәбрис Кашапов биш ел элек ул туган авылында хәләл продукция – ярымфабрикатлар ясауны җайлаган.

ХӘЛӘЛ ПИЛМӘН, ӨЧПОЧМАК...

Усы авыл җирлегенә Качкын авылы да керә. Ике авылга бер КФХ, бер пилмән цехы, ике шәхси эшмәкәр, өч мини-ферма, унҗиде үзмәшгуль кеше бар. Ике авылның да әллә ни зур булмаганын исәпкә алсаң, шактый батыр йөрәкле кешеләр яшәгәнен күрәбез.

Аларның берсе – Тәбрис Кашапов. Биш ел элек ул туган авылында хәләл продукция – ярымфабрикатлар ясауны җайлаган. Пилмән, мантый, кәтлит, өчпочмак – берничә төрле ризыкны туңдыргычта катырып, сатуга озаталар. Цехта барлыгы сигез хатын-кыз хезмәт куя.

– Бу ташландык бина элеккеге башлангыч мәктәп иде, - дип сүзен башлады Тәбрис. – 2017 елда аны сатып алып үз кулларым белән ремонт ясадым. Әнә шуннан акрынлап эшкә керештек.

– Ярымфабрикатлар ясау өчен итне сатып аласызмы? – дим.

– Әйе, авыл кешеләреннән сатып алабыз. Барысы да хәләл стандартлар буенча эшләнелә.

Тәбрис белән цехка уздык. Бөтен җиргә Коръән яңгырап тора. Башларына яулык япкан апалар көлешә-көлешә пилмән ясый иде. Төшкә кадәр мантый ясап туңдырганнар. Барысы да Усы апалары икән. Көнгә йөз утыз кило пилмән ясыйлар.

– Эш бүленгән безнең, – диде Айзирәк Таҗиева. – Беребез камыр ясый, икенчебез кисә, өченчеләр бөгә. Итне Тәбрис үзе әзерләп бирә. Иртәнге сигезенче яртыга киләбез дә уникедә кайтып китәбез. Бер сәгатьтән янә эшли башлыйбыз. Дүрткә кадәр монда без.

– Пилмән камырын гадәти рецепт белән ясыйсызмы? – дим.

– Әйе, йомырка, аз гына су, тоз. Яхшылып басабыз да камыр җәя торган станокка куябыз. Кул белән җәеп торасы юк, рәхәт.

– Бер кеше көнгә күпме пилмән бөгә? – дим.

– Төрлечә инде, кулы остарганнар егерме биш кило да ясый. Әнә Роза апа өч-дүрт ай элек килгән иде, хәзер ул да унҗиде-унсигез кило пилмән бөгә башлады.

Апалар белән аралашып алдык. Бирегә килгәнче кем балалар бакчасында, мәдәният йортында эшләгән. «Җитезлек булса, ярымфабрикатларны ясарга авыр түгел», – диделәр.

Хезмәт хаклары күпме эшләгәненә карап икән. Бер кило пилмән ясаган өчен кырык сум алалар. Саннарда исәпләсәң, авыл җире өчен бер дигән хезмәт хакы килеп чыга.

– Пилмәннәрне ясагач аш-су тактасына тезәбез, – диде Айзирәк апа. – Икенче көнне пакетларга тутырабыз. Ярты килолы, бер килолы да итәбез. Аннан Тәбрис үзе сатуга озата инде.

Усыда ясалган ярымфабрикатлар Актанышның үзенә, күрше-тирә авылларга китә. Соңгы арада Санкт-Петербург шәһәреннән күпләп алып китә башлаганнар.

– Алып карадылар да, яраттылар. Тагын заказ биреп киттеләр, – диде Тәбрис.

– Бу эшкә ничек алындыгыз? – дим.

– Өйләнешкәч тә гаиләм белән Лангепас, Пермь шәһәрләрендә яшәдек. 2002 елда яңадан туган якка кайтырга карар кылдык. Башта төрле эшләрдә, шабашкаларда йөрдем. Аннан шулай үз эшемне башларга ниятләдем.

Тәбрис Кашапов унбиш еллап диндә икән. Башта хәләл җефете Миләүшә намазга баскан. Аннан гаилә башлыгы да кушылган.

– Миләүшәнең гаиләсе дини, – диде Тәбрис. – Шулай намаз укыды-укыды да, бер мәлне ташлады бу. «Ник намазыңны укымыйсың?» – дидем. «Ире укымаган хатынның намазы кабул булмый икән», – диде. Шуннан мин дә кушылдым. (Көлә. – Авт.)

АКТАНЫШ ЧӘКЧӘГЕ

Һәр төбәкнең йөзе булырдай үз ризыгы бар. Актанышта ул, әлбәттә, чәкчәк. Шуның өчен дә Усы авыл җирлеге башлыгы Зиннәт Әхмәев безне Наилә Гарипова янына алып барды. Усыда гына түгел, бөтен районга билгеле чәкчәк пешерү остасы ул. Ераклардан ук килеп заказ бирәләр икән.

Без килгәндә дә хуҗабикә чәкчәк пешереп ята иде:

– Авыз ачтыручылар бар, заказ бирделәр, – диде.

Наилә апаның төп эш урыны – «Әнәк» агрофирмасында, сыерлар сава. Шулай ук үзмәшгульлек программасында да теркәлгән.

– Заказга чәкчәк пешерә башлаганыма унике ел булды, – дип елмайды Наилә апа. – Кыш көннәрендә бик күп булмый, туйлар чоры башлангач чәкчәк пешерми бер атна да калганым юк. Кайберәүләрнең өйләренә дә барып әзерлим. Күчтәнәчкә дип тә заказ бирәләр. Актаныш хакимиятеннән дә киләләр. Районга зур кунаклар җыенса да, чәкчәк әзерләргә миңа әйтәләр. Чит илләрдә узган Сабантуйларына да пешереп бирдем. Берсендә Президент Владимир Путинның сыйныф җитәкчесенә дип тә чәкчәккә заказ бирделәр.

Наилә апа ире Фазылҗан абый белән өч ул үстергән. Олы малайлары Фәдис үз гаиләсен корган инде. Уртанчылары Рәдис, Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятен тәмамлап, Түбән Кама драма театрында эшли. Кечесе Вәдис Актаныш гимназиясендә белем ала. Усыга атна азагында гына кайтып йөри, интернатта яши.

Хуҗабикә чәкчәк белән безне дә сыйлады. Бер сүз белән әйткәндә – авызда эри ул. Берничә ел элек нәкъ менә шундый ризык авыз иткән булды, анысы да Актанышта!

– Мондый чәкчәкнең сере нәрсәдә? – дим.

– Яхшы он һәм туңдырылган авыл йомыркасында, аны суыткыч камерасыннан кичтән алып калдырам. Төн чыкканчы эри ул. Шуны миксер белән яхшылап берничә минут болгатам да он кушам. Камыр уңсын өчен иң мөһиме – йомырканы әйбәтләп болгату. Ул үзеннән-үзе кабара. Гадәттә, заказга дигән чәкчәкне 20–30 йомыркадан ясыйм. Өчәр килолап була. Ә гаилә өчен әзерләгәндә ун йомыркадан да җитә, өч зур савыт чәкчәк чыга.

...Актанышка юлга кузгалганда, барысына да өлгерербезме дип, шактый борчылган идек. (Башта Әнәккә дә кердек бит.) Аллаһның рәхмәте, шундый рәхәт сәяхәт булды ул. Усы авыл җирлеге башлыгы кешеләрне кисәтеп куйган, әзерләнеп көтеп торганнар. Усылылар ачык, кунакчыл. Алардан алган яхшы энергия Казанга кадәр озата кайтты.

Берничә көн узгач, авыл җирлеге башлыгы Зиннәт Әхмәев мәчет фотоларын җибәрде: «Булды, иман йортыбыз Гает бәйрәменә әзер. Өлгерттек, әлхәмдүлилләһ!» - дип язды ул. Усылыларның зур шатлыгына без дә ихластан сөендек.

5
Усыда гына түгел, бөтен районга билгеле чәкчәк пешерү остасы Наилә Гарипова.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Сиринә Шәмсиева, китапханәче:

– Усы авылы исеме уйсу үзәнгә бәйле рәвештә килеп чыккан дигән риваять бар. Чыннан да шулай булырга мөмкин. Авыл шулай урнашкан.

Икенче фикер, монысы инде риваять кенә түгел: күрше Пучы авылында Рахмай Хисмәтуллин исемле язучы бар иде. Ул 2000 нче елларда Петербург архивларыннан безгә азмы-күпме тарихны алып кайтып бирде. Аның әйтүенчә, Усы, Пучы, Тучы – борынгы кеше исемнәре.

Актаныш хакимиятендә Усы авылы 1434 елда нигезләнгән дип язылган. Ләкин бу тарих әле өйрәнелеп бетмәгән. Ул тагын да алдарак оешкан булырга бик мөмкин.

АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ: КАРАР ҺӘМ КҮРСӘТЕР УРЫННАР КҮП

Туристлар һәм Татарстан кунаклары бу якка бик теләп килә, чөнки бередә истәлекле урыннар буа буарлык!

АВЫЛГА ИСЕМ БИРГӘН СОБОР

Алексеевск үзәген мәһабәт Воскресение чиркәве бизәп тора.

Аның нигезенә беренче таш 1966 елның 22 июнендә Казан һәм Татарстан архиепископы Анастасий тарафыннан салынган. Собор авылда 1712 елдан башлап бер-бер артлы төзелгән өч борынгы гыйбадәтханәнең рухи традицияләрен дәвам итә. Нәкъ менә 1712 елда алпавыт граф Петр Матвеевич Апраксин үтенече нигезендә Мәскәү митрополиты изге Алексий исеменә атап беренче агач чиркәү куела. Шул вакыттан бирле авыл үзенең хәзерге Алексеевск исемен йөртә.

Чиркәүнең 12 чаңнан гыйбарәт тиңдәшсез чаң манарасы бар. Аңа 3 кечкенә (авырлыгы 6 кг нан 16 кг га кадәр), 6 уртача зурлыктагы (36 кг нан 340 кг га кадәр) һәм 3 зур (660 кг нан 3300 кг га кадәр) чаң керә.

Чаң манарасының конструктив үзенчәлекләре бередә «Алексеевские перезвоны» чаң кагу фестивален үткәрергә мөмкинлек бирә. Һәр ел аңа Россиянең күп кенә төбәкләреннән һәм якын чит илләрдән иң оста чаң кагучылар җыела.

2022 елның 4 июнендә XX юбилей фестивален үткәрү планлаштырыла, аның темасы – «Россиянең рухи маяклары: иман, соборлылык, гаилә һәм Ватан».

Фотолар Алексеевск районы хакимиятеннән алынды. РЕКЛАМА

ТУГАН ЯК МУЗЕЕ: ҺӘРКЕМГӘ КЫЗЫКЛЫ БУЛАЧАК

Гаҗәеп пот башы, келәймәле борынгы ядрә һәм башка раритетлар – һәр әйбернең, һәр ядкәрнең үз тарихы бар

Алексеевскидагы музей 1987 елда оеша, аңа туган як тарихын өйрәнүче ветеран Виталий Абрамов нигез сала. 2008 елда музейга аның исеме бирелә. 228 кв. м мәйданда туган як тарихына, этнографиягә, җирле һөнәрчелек үсешенә, гамәли сәнгатькә караган 19 меңнән артык ядкәрдән гыйбарәт бик кызыклы коллекция тупланган.

ЕРАК ҮТКӘНДӘГЕ КЕШЕ

Музейның горурлыгы – чама белән 3–5 мең ел элек борынгы оста чокып ясаган бер пот башы. Бу сынның нинди максатта кулланылганлыгы бүгенгәчә билгесез булып кала.

Археолог, тарих фәннәре докторы, профессор Константин Руденко «Песчаный» утравы табышмаклары» мәкаләсендә болай дип яза: «Нәкъ менә Алексеевск музеенда мин беренче тапкыр уникаль таш скульптураны күрдем. Кешенең баш сыны комташтан эшләнгән. Биеклеге – 17 см, киңлеге – 14 см, калынлыгы – 11 см. Сынның нигезендә аны элэктереп кую өчен тишем бар. Потта мыеклы кеше сурәтләнгән. Башына конус рәвешендәге башлык кидерелгән. Мондый сыннарны башка очратырга туры килмәде».

Бу сирәк ядкәр музейга ничек килеп эләккән соң? Монысы да – галиҗәнап очраклылык эше. Узган гасырның 60 нчы елларында туган як тарихын өйрәнүче яшьләр төркеме Чулмандагы Берёзовая Грива утравында ял иткән. Валентина Исаева (Вилданова) очраклы рәвештә генә кеше башын хәтерләткән бер сәер таш таба, аны үзе белән ала, шуннан соң бу таш күпмедер вакыт сарайда тузан җыеп ята. Бу табылдыкның киләчәк язмышын Ирина Семёнова (Зиновьева) хәл итә, ул аны Виталий Абрамовка тапшырырга тәкъдим ясый.

Башны Казан һәм Мәскәү экспертлары берничә тапкыр тикшерә, алар әүвәл аның чынмы-ялганмы икәнлегенә ышана алмый, ташны күптән түгел генә ясалган берәр нәрсә дип уйлыйлар. Тик пот барлык экспертизаларны да лаеклы үтә.

ДЕМИДОВ ЯДРӘСЕ – ТУПЛАНМАНЫҢ ГОРУРЛЫГЫ

Музей экспозициясендә тиңе юк борынгы экспонат – XVIII гасырда тау сәнәгатьчеләре Демидовларның Уралдагы чуен-корыч кою заводларында җитештерелгән, «Д» хәрефе рәвешендәге келәймә сугылган, тоташ коеп ясалган чуен туп ядрәсе тәкъдим ителә. Алексеевск өчен бу экспонат аерым әһәмияткә ия, чөнки ул елларда Демидовлар династиясе шактый озак вакыт авылның хуҗасы булып тора. Ядрәне 1966 елда Чулман ярында Алексеевскиның туган як тарихын өйрәнүчеләре табып ала. Аның авырлыгы – 9 кг га якын.

ҖАН ҖЫЛЫСЫН САКЛАГАН УРЫН

Алексеевск бизәкләп туку фабрикасы– Татарстанда рус бизәкләп туку традицияләрен саклаган бердәнбер предприятие.

Продукциянең уникальлеге аның кулдан эшләнүеннән, милли бизәкләр һәм мотивларга сакчыл мөнәсәбәттән гыйбарәт. Предприятиенең барлык товарлары: бизәкле эскәтерләр, өстәл япмалары, сөлгеләр, тастымаллар табигый мамыктан һәм җитеннән җитештерелә. Музей үрнәкләрен өйрәнү, борынгы бизәкләр торгызу буенча зур эш алып барыла.

2022 елда фабрикага 95 яшь тула, ә тукымалар әүвәлгечә җанлы сулышны һәм хатын-кыз кулларының искиткеч җылысын саклый.

Продукцияне Алексеевск районында фабриканың фирма кибетендә*, Alextkach.ru сайтында һәм OZON сәүдә мәйданчыгында сатып алырга мөмкин.

*«Алексеевская ФХТ» ҖЧҖ, 422900, ТР, Алексеевск шәһәр тибындагы бистәсе, Павелкин ур., 22. ОГРН 1041635600984.

ТЫНЫЧ ТАБИГАТЬ КОЧАГЫНДА ЯЛ ИТҮ

Алексеевск районында шәһәрләр шау-шуыннан сыенып урыннар күп.

Lebedinoe ECO глэмпингы. Ул Чулман буендагы Лебедино авылы янында, урман-кырлар арасында урнашкан. Территориясендә бар уңайлыклары булган биш йорт һәм актив ял итү, күңел ачу өчен бик күп мәйданчыклар. Балалы гаиләләр һәм гашыйклар парлар өчен бик шәп ял урыны.



KZN FISHING балык тоту базасы. База Чулман елгасының матур яр буенда, Сакон авылында урнашкан. Биредә Чулмандагы һәртөрле балыкны тотып, рәхәтләнеп ял итәргәмөмкин. Менә дигән яшәү шартлары булган база ел әйләнәсе эшли.

Шулай ук биредә республикада иң зур балык тоту бәйрәме – «KZN FISHING УХАСЫ» фестивале үткәрелә.

«Речная сказка» ял базасы. Казаннан бер сәгатьлек юллык Речное авылында урнашкан. Җилдә яфраклар шыбырдавы һәм кошлар чыркылдавы сайравы – һәр иртә нәкъ менә шулай башлана. Кунаклар коттеджларда һәм бар уңайлыклы кечкенә өйләрдә яши. Актив ял мәйданчыклары бихисап.



Зиннәтуллиннар гаиләсенең «Биләр страуслары» экофермасы. Ул Биләр янындагы «Изгеләр чишмәсе» тирәсендә урнашкан. Биредә африка һәм австралия тәвә кошлары, казлар, үрдәкләр, кытай ефәк тавыклары, күркәләр, фазаннар, йорт куяннары, цесаркалар, нуба кәҗәләре, тавислар, тиеннәр, янут асрала. Хайваннарны ашатырга һәм алар белән фотога төшәргә мөмкин. Балалар зонасы һәм ял чатырлары бар. Быелгы сезонда ферма кунакларын яңа хайваннар: ак тәвә, дөя, токымлы кәҗәләр һәм фантейл токымлы экияти күгәрченнәр көтә.

1

БИЛӘР ТЫЮЛЫГЫ: БОРЫНГЫ ШӘҺӘР МИРАСЫ

Алексеевск районында Биләр авылы янында урта гасыр Көнчыгыш Европаның иң бөек калаларының берсе – Биләрнең калдыклары урнашкан. Рус елъязмаларына ул «Бөек Болгар каласы» дип кереп калган һәм бүген аның чикләрен Кече Чирмешән елгасы үзәнендә шактый төгәл итеп космостан күреп була.

АЛЕКСЕЕВСКИЙ РАЙОН

Бүген Биләр – борынгы шәһәр хәрабәләре генә түгел, күп төрле кызыклы объектларны үз эченә алган тулы бер тарихи-археология комплексы. Аның үзәге, һичшиксез, 1992 елда оештырылган Биләр тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы. 2424,25 гектар мәйданда музей, туфрак өемнәре һәм чокырлар белән әйләндереп алынган борынгы ныгытма-җирлекләр (Биләр, Балынгуз, Горки, Николаев-Баран шәһәрлекләре), күренекле химик А.М. Бутлеровның кәшәнә-төрбәсе булган зират, академик А.Е.Арбузовның Музей йорты, «Изге чишмә» архитектура комплексы һәм башкалар урнашкан.

БИЛӘР – УРТА ГАСЫР МЕГАПОЛИСЫ

Тыюлыкның үзәге дип Биләр шәһәрлеген атарга мөмкин, ул хәзерге вакытта Болгар дәүләте башкалаларының берсе буларак дәүләт яклавына куелган. Бу X гасырның беренче чирегендә нигез салынган иң зур урта гасыр шәһәре калдыклары, ныгытылган әлеге каланың гөрләп яшәгән чагы XI гасыр – XIII гасырның өчтән беренче өлешенә туры килгән.

Үзенең планировкасы буенча Биләр урта гасыр Багдад шәһәрен хәтерләтә, соңгысы баштагы планы буенча түгәрәкләп эшләнгән һәм ике өлештән: шәһәр үзәгендәге резиденция һәм аны уратып алган сәүдә-һөнәрчелек кварталларыннан торган. «Түгәрәк буенча» болай планлаштыру – борынгы күчмә җирлекләргә дә хас була.

1973 елгы аэрофотосъемка материаллары шәһәрлек территориясендә шактый күп кирпеч һәм кирпеч-таш биналарның булганлыгын күрсәтә. Шуларның бишесенең хәрабәләре археологик юл белән ачыклана. Алар арасында эчке шәһәр үзәгендәге Җәмигъ мәчете һәм җәмәгать мунчалары калдыклары бар.

Бүген музей-тыюлыкка экскурсиягә килүче кунаклар манара нигезе сакланган Җәмигъ мәчетенең музейлаштырылган хәрабәләрен, «Алпавыт йортын», кое, Биләр «мунчасын» һәм башка уникаль объектларны күрә ала.

ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ – ИДЕЛ БУЕ БОЛГАРСТАНЫНЫҢ ИЗГЕ ҮЗӘГЕ

Туристларны җәлеп итү үзәге һәм Биләрнең төп урыны булып, һичшиксез, Җәмигъ мәчете санала. Бу монголлар явына

Фотолар автордан, Зөфәр Шакировтан алынды. РЕКЛАМА



кадәрге Идел буе Болгарстанының гына түгел, тулаем төньяк-көнчыгыш Европаның иң борынгы дини корылмасы.

Үз заманында (хәер, хәзерге вакытта да монументальлеге белән хәйран калдыра) юлчыларны тартып торучы мәһабәт мәчет була ул. Һәм безнең көннәргә кадәр аның җир астындагы калдыклары (фундамент, дивар нигезләренең кайбер фрагментлары) һәм манара нигезе генә сакланып калган. Биләрдәге Җәмигъ мәчетенең масштабы чыннан да таң калдыра. Мәчет үзе генә дә биредә бөтен Идел буе Болгарстанының изге үзәге булуына ишарәли.

Башта мәчет агачтан салынган була (мәйданы 1400 кв. метр), бераз вакыттан соң ак таштан өстәп салынган янкорма һәм аерым торучы манара хисабына аны киңәйтәләр. Нәтиҗәдә аның гомуми мәйданы 2500 кв. метрга кадәр диярлек арта!

Мәчетнең таштан салынган яртысындагы намаз залында түбәләрне 24 колонна тотып тора, алар симметрия буенча алты рәткә тезелгән.

Бинаның көнчыгыш фасады пилястралар белән бизәлгән. Җәмигъ мәчете залының уртасында көнчыгыш дини корылмалар өчен хас булган ясалма бассейн урнаштырылган. Залдагы бер кыска диварда Кәгъбә юнәлешен күрсәтүче куыш уелган. Ә аңа каршы якта мәчеткә керү урыны ясалган.

Галимнәр фикеренчә, үз вакытында мәчетнең кирмән тибында почмаклы манаралар да булган. Алар нәкъ Алабуга шәһәрлегендәге кирмән-мәчет, соңрак Болгардагы Җәмигъ мәчете кебек, саклану-оборона функциясен дә үтәгән.

Мәчет белән берүк вакытта диярлек, якынча 10 метр чамасы читтәрәк, кирпеч бина салалар. Аны югары рухани аксөяк вәкилләренең берсе төзеткән. Мөгаен, бу җәмәгать мунчасы, төгәлрәге, тәһарәтләнү, ягъни мәчеткә керер һәм намаз уку алдыннан юыну урыны булгандыр.

Мәчет үзе дә, аның янында салынган кирпеч бина да чакыртылган көнчыгыш осталары ярдәмендә салынгандыр дип уйларга нигез бар. Биләрдә көнчыгыштан килгән төзүче һәм мигъмариятчеләрнең яшәгәнлеге факты казу эшләре барышында каркаслы-балчык диварлы җир өсте торак калдыклары белән раслана. Әлеге йортларда яисә алар янәшәсендә тандыр тибындагы мичләр торган.

Мәчет белән янәшә, аның көньяк-көнчыгыш диварлары янында, югары катламнар зираты урнашкан, биредә күмүләр мөселман кануннары буенча башкарылган. Аның пәйда булу вакыты ачыкланган – X гасырның беренче яртысы. Гади гражданнар зиратыннан

1
«Изге чишмә» комплексының күргәзмә залы.

2
Биләр шәһәрлегенең аэрофотопланы. 1973 ел.

3
Җәмигъ мәчетендә казу эшләренең аэрофотосы.

4
Академик А.Е.Арбузов музей йорты.

аермалы буларак, монда шулай ук квадрат кирпечләрдән салынган кечерәк кенә төрбә формасындагы махсус җир өсте корылмаларында күмәләр. Коллектив күму урыннары – гаилә төрбәләре дә бар.

ИЗГЕ ЧИШМӘ – ХАҖИЛАРНЫ ТАРТУ УРЫНЫ

Биләр комплексының төньяк-көнбатыш өлешендә Хуҗалар тавы итәгендә чыгыш урнашкан. Бу хаҗилар – төбәктә яшәгән төрле конфессия вәкилләре өчен изге урын. Дини аерымлыкларга да карамастан, аларның барысын да бер нәрсә берләштерә – алар Биләр чыгышы суының шифалы көченә ышана.

1997 елда тыюлыкның әлеге өлеше төзекләндерелгән, бүген «Изге чишмә» комплексына чишмә, йола һәм корбан чалу урыннары, религияләрнең берләшүен символлаштыручы монументка күтәрелү, тарихи-археология музее керә.

ХИМИК АРБУЗОВ МУЗЕЙ ЙОРТЫ

Бүгенге Биләр авылын комплексның алыштыргысыз өлеше дип санарга мөмкин – аның территориясендә мәдәни мирас объектлары урнашкан. Бу Биләр шәһәрлегенең якынча өчтән бер өлешен бүгенге авыл биләп торуы белән бәйләнгән. Авылдагы кайбер участокларда борынгы туфрак өемнәре калдыклары табыла, Биләр елгасының үзәне һәм борылмалары урта гасыр чокыры буйлап уза.

Биләргә Кама аръягы саклану сызыгындагы кирмәннәрнең берсе буларак 1654 елда нигез салына. Беренчеләрдән булып биргә Ахтачин төрмәсеннән гаиләләре белән бергә укчылар (стрелецлар) күчерелә, алар көньяк дала ягыннан күчмә кабиләләрнең баскынынннан сакларга тиеш була.

XVIII гасыр – XX гасыр башында Биләр Чистай өязенең иң эре торак пункты буларак шәһәр яны статусында санала. Авыл уртасында XIX гасыр – XX гасыр башына караган бик күп корылмалар бар. Монда шулай ук күренекле химиклар нәселе вәкиле А.Е.Арбузовның музей йорты урнашкан.

БОРЫНГЫ ТӨРБӘ ҺӘМ КУРГАННАР

Кече Чирмешән елгасының уң як яры уникаль тарихи-ландшафт киңлеген тәшкил итә. Елга өсте тигезлегеннән 40–50 метр биеклегендәге плато кырыенда: Горки авылы һәм Балынгуз тавы янында бронза эпохасы курганнары, урта гасыр ныгытма-җирлекләре калдыклары – I һәм II Горки шәһәрлеге, Балынгуз шәһәрлеге аерылып тора. Балынгуз тавында зират (мөселман кабер ташлары Биләр музеенда саклана) һәм урта гасыр төрбәләре хәрабәләре бар. Биеклекләре буенча төрле калкулыкларның иң биек урыныннан Кече Чирмешән елгасы үзәненең искиткеч матур манзарасы ачыла.

БӨТЕН ЮЛЛАР ДА БИЛӘРГӘ ИЛТӘ

Музей-тыюлыкка төрле юнәлешләрдән яхшы юллар буенча барып җитәргә мөмкин: төньяк-көнбатыштан – Казаннан Алексеевск аша Биләр тракты буйлап (ул Нурлатка, аннан соң Самара өлкәсенә кадәр сузыла); төньяк-көнчыгыштан – Чистайдан һәм көнчыгыш Кама аръягы үзәкләреннән; көньяк-көнбатыштан – Базарлы Матак аша Болгардан һәм Ульяновск өлкәсеннән.

5 Изге чыганакта «Чишмә җәннәте» бәйрәме.

6 А. М. Бутлеров каберендәге кәшәнә.

7 Биләр шәһәрлеге, XLIV казу эшләре, 2018 ел. Сары металл асма бизәге.

Зөфәр Гомәр улы Шакиров, тарих фәннәре кандидаты, «Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-тыюлыгы» ТР ДБМУ директоры; КФУ доценты.

Фаяз Шәрип улы Хуҗин, тарих фәннәре докторы, ТР ФА мөхбир-әгъзасы, ТР ФАнең А.Х. Халиков исем. Тарих институты хезмәткәре.

«Әхмәд ибн Фадлан хәлифә әл-Мокътәдирнең Алмыш ханга хатын укый». Н. Хажиәхмәтов картинасы.

ИБН ФАДЛАН СӘЯХӘТНАМӘСЕ

(Кыскартып бирелә)

Бу – Мөхәммәд ибне Сөләйманның буйсынучысы, хәлифә әл-Мокътәдирнең болгарлар патшасына җибәрелгән кече илчесе Әхмәд ибне Фадлан ибне әл-Габбас ибне Рәшид ибне Хаммадның китабы. Ул анда 921–922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә үзе шаһит булган нәрсәләрне, патшалар һәм халыкларның көнкүреше турындагы мәгълүматларны терки.

Әхмәд ибн Фадлан: «Болгарлар патшасы Алмыш мөселманнар хөкемдары Мокътәдиргә – аны дингә өйрәтүче, Ислам диненең кануннарын аңлатучы, аның өчен мәчет төзеп бирүче, аның (хәлифәнең) ислам диненә өндәвен үзенең шәһәрендә һәм бөтен дәүләтендә (халыкка) җиткерү өчен аңа (болгар патшасына) мөнбәр торгызучы кешеләр җибәрүен сораган, һәм ул (болгар патшасы) дошман патшалардан анда торып саклансын өчен аннан (хәлифәдән) кальга салуын үтенгән хат килгәч, аңа (болгар патшасына) аннан (хәлифәдән) нәрсә сораган булса, шуңа ризалык бирелде», – дип әйтте. Һәм бу эштә Нәзир әл-Хәрәми арадашчы булды. Ә мин аңа (болгар патшасына язылган) хатны уку өчен, аңа бүләк итеп җибәрелгән әйберләрне тапшыру өчен, мөселман хокукы белгечләре һәм укытучылар өстеннән күзәтү өчен җибәрелдем... Ә хәлифә тарафыннан илче итеп Нәзир әл-Хәрәминең буйсынучысы Сәүсән әр-Расси (билгеләнде)...

Шулай итеп без Тынычлык шәһәреннән (Багдадтан) өч йөз тугызынчы елның сәфәр аеның унбер төне узгач, пәнҗешәмбе көнне (921 елның 21 июнендә) кузгалып киттек...

...Аннан соң без күп көннәр бардык һәм Җаха (Урал) елгасын кичеп чыктык, аннан соң Ирхиз (Иргиз), аннан соң Мочаны (?), аннан соң Самурны (Самара?), аннан соң Киналны (Кинель), аннан соң Сух (Сок), аннан соң Күнҗүлү (Кичүле?) елгасын кичеп чыктык. Һәм без төркиләрдән бер кабилә иленә килеп эләктек, аларга «башкортлар» дип әйтәләр...

...Без бу кешеләр (башкортлар) иленнән кузгалып киттек һәм Җарамсан (Зур Чирмешән) елгасын кичеп чыктык, аннан соң Уран (Урень) елгасын, аннан соң Урым (?) елгасын, аннан соң Байнах (Майна) елгасын, аннан соң Ватыг (Утка) елгасын, аннан соң Нийасна (Бездна?) елгасын, аннан соң Җуушыр (Кече Чирмешән) елгасын кичеп чыктык... Без болгарлар патшасыннан – ә ул без бара торган кеше – бер көн һәм бер төн (юл бару) ераклыгында булганда безне каршылау өчен үзенең хакимиятенә буйсынган дүрт патшаны (кабилә башлыкларын), үзенең ир туганнарын һәм улларын җибәргән иде. Алар безне каршыладылар, аларның ипиләре, итләре һәм тарылары бар иде, һәм алар безнең белән бергә кузгалып киттеләр. Һәм без аннан (Болгар патшасыннан) ике фәрсах ара ераклыкта (12–14 км

чамасы) ераклыкта булганда ул (болгар патшасы) безне үзе каршылады. Безне күргәч, (атыннан төште), бөек һәм кодрәтле Аллага табынып, рәхмәтләрен белдереп, йөзтүбән егылды. Аның җиң эчендә дирһәмнәр бар иде, һәм ул аларны безгә сипте. Ул безнең өчен чатырлар кордырды һәм безне шунда урнаштырды. Безнең аның янына килем җитүебез өч йөз унынчы елның мөхәррәм аеның уникенче төне үткәч, якшәмбе (көнне) булды (922 елның 17 мае).

Хәлифәнең хатын укыганны ишетсеннәр өчен, ул (болгар патшасы) үз иленең патшаларын (кабилә башлыкларын, бәкләрен), гаскәр башлыкларын һәм хөрмәткә лаек башка кешеләрен җыйганчы, без үзебез өчен корылган чатырларда якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрдә (торып) калдык. Пәнҗешәмбе (көне) килеп җиткәч (922 елның 21 мае) һәм алар җыелгач, без үзебез белән алган ике чигелгән байракны җәеп җибәрдек, аны (Болгар патшасын) кара киемнәргә киендердек һәм чалма кидердек. Мин хәлифәнең хатын чыгардым һәм аңа: «Хат укыганда утырып тору рөхсәт ителми», – дидем. Һәм ул аякларына торып басты, үз дәүләтенең шунда булган күренекле, хөрмәткә лаек кешеләре дә (торып бастылар). Ә ул бик юан һәм зур корсаклы кеше. Мин (укый) башладым һәм хатның башын укыдым. Һәм: «Сиңа тынычлык булсын! Һәм чыннан да мин сиңа (мөрәҗәгать итеп), Аллаһыны данлыйм, Аннан башка бөтән бөек көч юк», – (дигән) сүзләргә җиткәч, мин: «Мөселманнарның хөкемдарына тынычлык теләп җавап бир!» – дидем. Һәм ул җавап бирде, һәм алар да (шунда булган кешеләр дә) барысы бергәләп җавап бирделәр.

Безнең өчен (ягъни без укыганны) хәрефен хәрефкә тәрҗемә итүдә тәрҗемәче дә ялгышмады. Һәм без хатны укып бетергәч, алар «Аллаһу әкбәр!» сүзен әйттеләр. Бу сүзләр белән, әйтерсең лә, Җир сәламләде (Җир яңгырап торды).

Аннан соң мин вәзир Хәмид ибне әл-Габбасның хатын укыдым, һәм ул (болгар патшасы) бу вакытта басып торды. Аннан соң мин аңа утырырга куштым, һәм ул Нәзир әл-Хәрәминең хатын укыганда утырып торды. Һәм мин хат укуны тәмамлагач, аның (болгар патшасының) иярченнәре аңа бик күп дирһәмнәр чәчте. Аннан соң мин хуш исле нәрсәләрдән аның өчен һәм аның хатыны өчен тәгаенләнгән киемнәрдән, энҗеләрдән торган бүләкләрне чыгардым, һәм мин ялгышмадым, без моны тәгәлләгәнче, аңа һәм хатынына әкренләп күрсәтеп тордым. Аннан соң мин аның хатынын кешеләр барында бүләкләдем, ә ул аның (болгар патшасы) белән янәшә утыра иде. Һәм бу – аларның йоласы һәм аларның гадәте. Һәм мин аны бүләкләгәндә хатын-кызлар аңа дирһәмнәр чәчте, һәм без чыгып киттек.

Бер сәгать чамасы вакыт үткәч, ул (Болгар патшасы) безнең арттан (чакыртып) җибәрде, һәм без аның янына (мәҗлескә) кердек...

...Хатны укыганнан соң һәм бүләкләрне тапшырганнан соң өч көн үткәч, болгар патшасы минем арттан чакыртып кеше җибәрде. Һәм инде аңа дүрт мең динар мәсьәләсе җиткерелгән иде. Мин аның янына кердем, ул миңа утырырга кушты, һәм мин утырдым, ә ул миңа хәлифәнең хатын ыргытты һәм: «Бу хатны кем алып килде?» – диде. Мин: «Мин», – дидем. Аннан соң ул миңа вәзирнең хатын ыргытты һәм: «Шулай ук моны дамы?» – диде. Мин: «Мин», – дидем. Ул: «Аларның икесендә дә телгә алынган акчалар белән нәрсә булды?» – дип сорады. Мин: «Аларны җыю авыр булды һәм вакыт та кысан иде...», – дидем...

Мин Болгар илендә (күп) могҗизалар күрдем. Аерым алганда, Болгар иленә килгәннең икенче көнендә үк кичкә табан, кояш батар алдыннан, без, илчелек әгъзалары, күк йөзенең кинәт кызыл төскә керүен күрдек, һавада каты гөрелдәү тавышлары ишетелде. Шулвакыт миннән ерак түгел кулларына ук-җәяләр, сөңге һәм кылычлар тоткан шәүләләр – атлы җәйдәклар килеп чыкты. Аларны без бик ачык күрдек, әмма вакыт-вакыт бу сугышчылар болыт арасына кереп югалгандай булалар иде. Һәм менә бераздан алар белән янәшәдә тагын бер шундый ук төркем пәйда булды. Гаскәр гаскәргә ташланган шикелле бу отряд тегесенә каршы һөҗүмгә күчте. Без моннан куркып, ялварырга, үтенергә, инәлергә керештек, ә болгар хуҗаларыбыз исә безнең кыланмышларыбыздан көләләр һәм гаҗәпләнәләр иде...

...Мин аларның (болгарларның) этләр улавын яхшыга юраганнарын күрдем, һәм алар аңа бик нык шатланалар һәм (алар) муллык, бәхет һәм иминлек елы турында сөйлиләр...

Мин алар илендә чикләвек агачларыннан да күп (нәрсә) күрмәдем. Мин инде аларның урманын да күрдем, аның иңе-буе кырык фәрсахка җитә иде...

...Аларның ризыгы – тары һәм ат ите, ләкин бодай һәм арпа да күп. Аларны чәчеп үстергән кеше уңышын үзенә ала. Патшаның, һәр елны һәм һәр өйдән аңа бирелә торган бер кеш тиресеннән башка, (ашлык уңышына) хакы юк. Әгәр ул үзенең гаскәриләренә берәр илгә яу чабарга кушса, табыш сыйфатында аңарда (яулап алынган малда) аның өлеше бар. Туй уздырган, чакырып кунак сыйлаган һәркем, сый мәҗлесенең күләменә карап, балдан ясалган бер савыт шәрабтән һәм бодайдан мәҗбүри рәвештә патшага өлеш чыгарырга тиеш булган...

Алар барысы да чатырларда (юрталарда) яши, ләкин патшаның чатыры бик зур – мең һәм аннан да артыграк кеше сыйдыра, анда әрмән келәмнәре җәелгән. Чатырның уртасында – Византия парчасы белән тышланган патша тәхете.

Аларның йолаларының берсе шундый: әгәр берәр кешенең улының баласы туса, аны атасыннан элек бабасы (кулына) алган һәм: «Аңа (балага) – ир булып җитешкәнче аны тәрбияләргә – атасына караганда иң зур хокук миндә», – дип әйткән.

Әгәр дә инде болгарлардан берәр кеше вафат булса, улларыннан элек аның (үлгән кешенең) ир туганы варис булып кала. Һәм мин патшага: «Бу (исламда) рөхсәт ителми», – дидем, һәм аңа, ул аңлаганчыга кадәр, мирасның нәрсә икәнлеген, (ислам кануннарына туры китереп) ничек бүләргә кирәклеген аңлаттым...

...Һәм алардан (болгарлардан) берәр кеше аңлы рәвештә кеше үтерсә, алар аның үзен үтерәләр. Әгәр ул аны хаталанып үтерсә, аның өчен нарат агачыннан сандык ясыйлар һәм аны сандык эченә урнаштыралар, өстеннән кадаклап куялар. Аның янына өч көлчә һәм бер кувшин су куялар. Алар аның өчен дөя иярендәге таякчыклар кебек итеп өч багана (бүрәнә) көйләп куялар һәм аны шул баганалар арасына элеп (асып) куялар һәм: «Без аны Күк белән Җир арасына урнаштырабыз, аңа яңгыр һәм кояш төшә, бәлки Аллаһ чыннан да аңа шәфкать күрсәтер», – дип әйтәләр. Һәм аны вакыт черетеп һәм җил таратып бетергәнче, ул асылып куелган килеш кала.

Ирләр һәм хатыннар елгага юынырга төшәләр һәм шәрә килеш бергә юыналар, коеналар, бер-берсеннән яшеренмиләр һәм һичбер хәлдә дә, һичнинди юл белән дә зина кылмыйлар... Һәм мин хатын-кызлар ирләрдән яшеренсеннәр өчен тырышудан туктамадым, ләкин минем бу эшем барып чыкмады...

Аларның урманнарында умарта кортларының оялары күп була, һәм алар корт ояларын беләләр һәм бал эзләргә чыгып китәләр...

Болгарлар арасында сәүдәгәрләр күп, алар төркләр җиренә чыгалар һәм сарыклар алып кайталар. Вису дип атала торган җиргә дә барып йөриләр, аннан кеш һәм кара төлке тиреләре алып кайталар.

Без алар арасында (бер кабиләнең) гаилә әгъзаларын күрдек; алар биш мең хатын-кыз һәм ир-ат җан иярен тәшкил итәләр. Инде алар барысы да ислам динен кабул иткәннәр. Аларны бәрәнҗәрләр дип йөртәләр. Һәм инде алар үзләре өчен агачтан мәчет төзегәннәр һәм анда һәркөн намаз укыйлар. Алар догалар укый белмиләр әле, һәм мин аларны ничек итеп (нинди сүзләр белән) дога кылырга өйрәттем.

Һәм чыннан да, инде минем җитәкчелегемдә Талут исемле бер кеше ислам динен кабул итте, һәм мин аңа Габдулла дип исем куштым.... Аның этисе, хатыны һәм балалары да ислам динен кабул итте...

...Һәм Болгар патшасы Хеллече дигән су (күл) яныннан Җаушир (Кече Чирмешән?) елгасы янына кузгалып китте һәм шунда ике ай булды. Юлга кузгалып китәр алдыннан суар дип аталучы кабиләгә хәбәр җибәреп, аларга аның белән бергә китәргә боерды. Ә алар аның кушуын кире кактылар. Һәм алар ике төркемгә бүленделәр. Бер төркем белән Вырыг исемле бер кеше идарә итә иде. Һәм Болгар патшасы аңа (аларга) чакыру җибәрде: «Чыннан да кодрәтле һәм Бөек Аллаһ миңа ислам динен һәм мөселманнар хөкемдары (хәлифәсе) тарафыннан хакимлек дәрәҗәсен бүләк итте. Һәм мин Аллаһының колы, һәм бу эшне Аллаһ миңа үзе йөкләде. Һәм кем дә кем миңа каршылык күрсәтә, мин аны кылычтан үткәрәчәкмен», – диде.

Үз кабиләсенең патшасы белән икенче төркем дә бар иде, ул (кабилә башлыгы) үзен искил кабиләсе башлыгы дип таныштырды. Һәм ул Болгар патшасына буйсынган иде. Ләкин ул әле исламны кабул иткән кеше түгел иде. Һәм болгар патшасы беренче төркемгә бу фәрманны җиткергәч, алар аның мөнәсәбәтеннән курыктылар. Һәм алар барысы бергә аның артыннан Җаушир елгасы янына киттеләр...

...Көннәрнең берсендә мин аннан сорадым һәм аңа: «Синең дәүләтең бик зур, акчаларың күп, керемең күпсанлы, ә син ни өчен хәлифәдән әлеге әз генә акчаларга синең өчен ныгытма (крепость) төзеп бирүен үтендең?» – дидем. Һәм ул әйтте: «Мин, ислам бәйсез дәүләтенең киләчәге бар һәм аларның акчалары дини кануннар тарафыннан рөхсәт ителгән чыганаклардан алыналар, дип санадым. Һәм мин моны шул сәбәпле сорадым. Һәм чыннан да, әгәр дә мин үземнең акчаларга, көмешләргә-алтыннарга ныгытма төзергә уйлаган булсам, дөрестән дә, мирнем өчен моңарда һичнинди авырлык булмас иде».

Ә болгар патшасы өстендә хәзәр патшасына ясак түләү бурычы ята. Ул аны үзенең дәүләтендәге һәр йорттан бер кеш тиресе белән түли. Әгәр дә хәзәрләр иленнән болгар иленә сәүдә корабы килсә, болгар патшасы атка атланып чыга һәм корабтә булган тауарларны санап чыга һәм аларның һәркайсыннан уннан бер өлешен ала. Әгәр инде руслар (варяглар) яки башка кабиләләрдән бүтән кешеләр коллар белән килгән булса, патша шулай ук һәр ун баштан берсен сайлап ала.

Ә болгар патшасының улы хәзәр патшасы янында аның тоткыны (заложник) булып тора. Берзаман хәзәр патшасына болгар патшасы кызының чибәрлеге турында хәбәр барып ирешкән. Һәм ул аны кодаларга җибәргән. Ә болгар патшасы каршылык күрсәткән, Хәзәр патшасы яу җибәргән һәм кызны көч белән алган. Хәзәр патшасы – яһүд, ә ул (болгар патшасы кызы) – мөселман, һәм ул хәзәрләр патшасы янында булганда үлгән. Аннан соң хәзәр патшасы болгар патшасының икенче кызын сорап кеше җибәргән. Бу хәбәр болгар патшасына яучылардан алданрак килеп өлгергән һәм ул, хәзәр патшасы аның апасы белән эшләгән кебек аны да көч белән тартып алыр дип куркып, аны искил патшасына (бәгенә) кияүгә биргән. Ә ул, искил патшасы, болгар патшасының кул астындагы кеше. Шул хәлләр болгар патшасын хөкемдарга (Багдад хәлифәсенә) хат язуга этәргән, һәм ул аннан (хәлифәдән) хәзәр патшасыннан саклану өчен ныгытма төзүен үтенгән...

Һәм мин русларны (варягларны) күрдем, алар үзләренең сәүдә эшләре буенча килеп җиткәннәр һәм Итил елгасы буенда корабларыннан төшкәннәр иде...

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

САФ ЭНЕРГИЯ

– Гамәлгә ашыру инструментлары булмаса, идеянең мәгънәсе юк. Бу Хәмзә Баһманов сүзләре. Инженерлык фикере даһие һәм талантлы оештыручы буларак, ул республика өчен перспективалы проектларны алга сөрүче булды. Тагын шуны да әйтәсе килә: энергетика тармагы бу яктан бигрәк тә уңды – аның өчен Баһманов озак еллар дәвамында «үз кеше» булды һәм шулай булып кала да.



Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго»
АҖ генераль
директоры

2018 елның 29 августы. Бу көн минем хәтергә бик вак мизгелләренә кадәр уелып калды. Идарә пульты янында минем белән бергә Россия энергетика министры Александр Новак һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов басып тора. Без бергә кызыл төймәгә басабыз һәм яңартылган ТЭЦ-1 турбинасын эшләтеп җибәрәбез. Әлеге җылылык энергиясе үзәге безнең төп идея – республика башкаласының энергетик куркынычсызлыгын көчәйтүне тормышка ашыру өчен мөһим инструмент булды. Булды, Казан, сиңа хәзер энергия кытлыгы янамый! Һәм бу проектның уңышында Хәмзә Әзәловичның ролен бәһаләп бетергесез.

«ТАНЕКО» генераль директоры вазыйфасында Баһманов эшләгән җиде ел дәвамында аны «гасыр төзелешенең җитәкчесе» дип йөрттеләр. Ә инде ТР сәүдә һәм сәнәгать министры урынбасары урыны тәкъдим ителгәч, журналистлар аны шунда ук диярлек «Античубайс» дип атады – энергетика өлкәсендә үзәк тарафыннан кабул ителгән карарларны (ә аларда хосусыйлаштыруның төп идеологының аерым бер «өлеше» бар) гадел һәм кыю рәвештә тәкыйтьләгәне өчен. Ул чакта Хәмзә Әзәлович республика энергетика тармагының төп рупорына әйләнде.

Ул җайланма-җиһазларның таушалуын-искерүен, энергия кытлыгы янавы турында җиткерде, аларның барысын да хәл итәргә кирәк... Белгәнебезчә, Баһманов буш сүз сөйләргә яратмый, шуңа күрә ул эшләгәндә шәһәрләрне җылылык белән тәэмин итүнең нәтиҗәле схемаларын эшләү оештырылды, соңрак алар Генерацияләүче компания тарафыннан тормышка ашырылды. Универсиада «имтиханын» да уңышлы тапшырдык: ул чакта барыбыз бергә энергия белән тәэмин итүнең ышанычлылыгына, аның куркынычсызлыгына ирешүнең югары «классын» күрсәтә алдык. Ниһаять, тагын шуны да әйтергә кирәк: ул Алабуга районында озак көтелгән подстанция төзелешен ахырына кадәр җиткерде, аңа тармагыбыз өчен легендар шәхес – Юрий Владимирович Щелоков исеме бирелде...

«Энергетиканың алгы сызыгына» Хәмзә Баһманов 2014 елда килде. Безнең командада ул «Генерацияләүче компания» ААҖнең стратегик үсеш буенча генераль директоры урынбасары вазыйфасын биләде. Аның җаваплылыгындагы эшләр аеруча катлаулы булулары белән аерылып торды, шуңа да карамастан, ул аларны һәрвакыт шәп итеп башкарды. Әйтик, соңгы еллардагы төп проектларыбызның берсе – ТЭЦ-1 энергоблогын төзү дүрт айга иртәрәк тәмамланды. Эшләтеп җибәрү тантанасына чакырылган Александр Новак әлеге вакыйганы бөтен Россия энергетикасы өчен мөһим дип билгеләп үтте. «Биредә иң алдынгы, инновацияле технологияләр кулланыла. Һәм бу безгә экологиялелек турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Бер кВт ка 218 грамм шартлы ягулык тоту – бу Россия буенча алганда бер ярым тапкырга кимрәк!» – диде ул һәм гомумән станциядә җитештерү культурасының югары булуына басым ясады. Менә ул инженерлык фикере һәм оештыру талантының чагылышы нинди була!

Юбилеегыз белән, хөрмәтле Хәмзә Әзәлович! Сез бүген дә республикабыз иминлеге хакына фидакарь хезмәтегезне дәвам итәсез. Сездә оптимизм һәм энергия сокландыра! Үзегез дә һәрвакыт яңа идея һәм бурычларның катлаулылыгы белән рухланган! Ихлас күңелдән Сезгә нык сәламәтлек һәм барлык эшләрегездә уңышлар телим!

Фото: tatar-inform.ru

РОССИЯ ИСЛАМ ИНСТИТУТЫ

ӘЗЕРЛЕК ЮНӘЛЕШЛӘРЕ:

ТЕОЛОГИЯ БАКАЛАВРИАТ МАГИСТРАТУРА

ЛИНГВИСТИКА БАКАЛАВРИАТ МАГИСТРАТУРА

ЖУРНАЛИСТИКА БАКАЛАВРИАТ МАГИСТРАТУРА

УКЫТУ ФОРМАСЫ – КӨНДЕЗГЕ, ЧИТТӘН ТОРЫП.
ДӘҮЛӘТ ҮРНӘГЕНДӘГЕ ДИПЛОМ БИРЕЛӘ.
СТУДЕНТЛАР ТУЛАЙ ТОРАК БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛӘ.
ДОКУМЕНТЛАР 20 ИЮНЬДӘ ТАПШЫРЫЛА.

КАЗАН ш., ГАЗОВАЯ ур., 19
+7 (843) 251-01-55 (кабул итү комиссиясе)
+7 904-717-01-55
http://kazankiu.ru
priem-kiu@mail.ru

Лицензия №1929, 2016 елның 8 февраленнән
Дәүләт аккредитациясе турындагы таныклык №3154, 2019 елның 19 июненнән

реклама

КАЗАН ИСЛАМ УНИВЕРСИТЕТЫ

ЮНӘЛЕШ:

«ДИНИ ОЕШМАЛАР ӨЧЕН ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ҺӘМ ДИНИ ПЕРСОНАЛ ӘЗЕРЛӘҮ»

ЮГАРЫ ДИНИ БЕЛЕМ

ИСЛАМ ФӘННӘРЕ БАКАЛАВРЫ, профиль: ислам фәннәре

КОРЪӘН ФӘННӘРЕ БАКАЛАВРЫ, профиль: Коръән фәннәре

УКЫТУ ФОРМАСЫ – КӨНДЕЗГЕ, КӨНДЕЗГЕ-ЧИТТӘН ТОРЫП, ЧИТТӘН ТОРЫП УКУ

УРТА ҺӨНӘРИ ДИНИ БЕЛЕМ БИРҮ

профиль: ислам фәннәре
квалификация: имам-хатыйб, ислам нигезләре укытучысы
УКЫТУ ФОРМАСЫ: ДИСТАНЦИОН БЕЛЕМ БИРҮ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН КУЛЛАНЫП ЧИТТӘН ТОРЫП УКУ.

Читтән килгәннәргә тулай торак бирелә.
Документлар 20 июньнән кабул ителә.

КАЗАН ш., ГАЗОВАЯ ур., 19
+7 (843) 251-01-55 (кабул итү комиссиясе)
+7 904-717-01-55
http://kazankiu.ru
priem-kiu@mail.ru

Лицензия №1017, 2014 елның 9 июне.

реклама

ТАБИГЫЙ ЮУУ МАТДӘЛӘРЕ

IN SAF

САФ СЫЙФАТНЫҢ ЯҢА ИСЕМЕ!

- Хәләл, табигый көнкүреш химиясе
- Экологик, кеше һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркынычсыз
- Су белән бик яхшы юыла
- ТР Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты тарафыннан сертификацияләнгән

OZON, WILDBERRIES, Яндекс.Маркет, KazanExpress, ВКонтакте /vk.com/in_saf_halal

Жамалиев Юсыф Фәнгизович ОГРНИП 319169000152503, 16.09.2019 ел.

ТЕЛ.: +7 904-666-78-30

реклама

MEDEL
КҮП ЮНӘЛЕШЛЕ КЛИНИКА

КАЗАНДАГЫ «МЕДЕЛ» КЛИНИКАСЫНДА УНИКАЛЬ ДӘВАЛАНУ

520-20-20

Аяклардагы варикоз – теләсә кайсы стадиядә

1 сәгать эчендә дәвалау. Операциядән соң ук йөрергә һәм эшли башларга мөмкин. **14 ел дәвамында ЭВЛК-МЕДЕЛ куллануның уңышлы мисалы. 3000нән артык операция.**

Умыртка баганасындагы бүсер

Операциясез, мускулларны электр белән стимуляцияләү һәм лазер ярдәмендә дәвалау. **Нәтиҗәле, хәтта бердәнбер өмет операция булганда да.**

Баш авыртулары, мигрень

Мускулларны электр белән стимуляцияләү һәм лазер ярдәмендә дәвалау. **Авыртуны баса торган дарулардан тулысынча баш тарту.**

Йоклаганда гырлауны лазер белән дәвалау

«МЕДЕЛ» клиникасында гырлауны лазер белән дәвалау (увулопалатопластика) лазер тиясе урынның тоюын басып торып, уңайлы шартларда башкарыла. Лазер артык тән тукымасын киптереп, проблемалы зоналарны тыгызрак итеп, аңкау, кече телгә йогынты ясый. Моннан соң сезгә гадәти тормыш рәвешен үзгәртергә кирәкмәячәк. Процедура сулыш алуны күпкә яхшырта, бу исә уңайлырак һәм тирәнрәк йокларга булыша. Гадәттә 1–5 сеанс таләп ителә, барысы да пациентның хәленә бәйле.

Борын сөяген (бүлгесен) турайту

Лазер серопластикасы – лазер ярдәмендә борын бүлгесен турайту буенча уникаль технология. Ул 30 минут эчендә авыртуларсыз, наркозсыз башкарыла. Процедура уникаль, патентланган Лор-Лазекс инновацияле лазер технологиясе буенча үткәрелә. Ул озак тернекләнүне таләп итми.

- **Наркозсыз, уңайлы эшләнә.**
- **Сулыш алу сизелерлек дәрәҗәдә җиңеләя, яхшыра.**
- **Процедура 30–60 минут эчендә башкарыла.**
- **Хастаханәгә яту таләп ителми.**

Аденоидларны дәвалау

Әле күптән түгел генә бу наркоз астында, димәк, бала организмы өчен куркынычсыз булмаган ысул, медикаментлар ярдәмендә яисә хирургия юлы, авыртулы методлар белән башкарыла иде. **Хәзер балаларда аденоидларны Казандагы «МЕДЕЛ» клиникасында Лор-Лазекс инновацияле лазер технологиясе ярдәмендә дәваларга мөмкин.** Бу аденоидларны дәвалауда чыннан да революцион ысул. Лазер технологиясе аденоид тукымасын авырттырмыйча, канатмыйча киптерә. Процедура вакытында бала үзен тыныч тота, уңайлы хис итә.

реклама

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

«ЭКСКЛЮЗИВ»: ЗАТЛЫ БҮЛӘКЛӘР

Затлы әйберләр бүләк итегез. Шундый затлы бүләкләрне сайлап алу мөмкинлеге – бары тик «Эксклюзив» салоннарында гына!

Бизәнү әйберләре: алка, муенча, беләзек, чылбыр асма бизәкләр-гасырлар дәвамында безнең әбиләр, әниләрнең сандыгында иң кадерле әйбер булып сакланган. Татар хатын-кызлары беләзекләргә мөкиббән булган. Алтын-көмеш беләзек хатын-кызның киемен тулыландырып торган. Кайнана булачак килененә Коръән сүрәләре белән бизәлгән пар беләзекләр бүләк иткән. Алай гына түгел, беләзекнең эчке ягына кәләшнең исемен дә язганнар.

Алкалар исә – хатын-кызлар арасында иң киң таралган бизәнү әйбере. Аның хәтта милләте дә юк, аерма фәкать бизәкләрдә. Һәркемдә, хәтта ярлырак гаиләләрдә дә көмеш алка, беләзек-йөзекләр кыз-кыркын, ханым-туташларның күңелен җылыткан. Татарлар күбрәк айлы айкаларга өстенлек биргән. Алар хатын-кызны күз тиюдән саклый дип саналган. Айлы алкалар шулай ук ана образын гәүдәләндергән.

Тагын бер бизәнү әйбере – йөзек. Урта гасырларда ук татарлар өчен кыйммәтле һәм кирәкле бизәнү әйберенә әйләнгән ул. Йөзек кию мәҗбүри саналган. Кунакка барганда туташ һәм ханымнар кайчакларда хәтта икешәр-өчәр йөзек кия торган булган. Мондый йола хакында күп кенә тарихчылар, шул исәптән Карл Фукс та язып калдырган.

Кыскасы, зәркән бизәнү әйберләре элек-электән милли киемгә ямь, матурлык өстәгән, нәфислек, миллилекнең бер өлеше итеп кабул ителгән. Аның функцияләре дә күп булган: күз тиюдән саклау кебек ырымнардан башлап, хатын-кызның нинди нәселдән булуын, билгән вазыйфасын күрсәтүгә кадәр.

«Эксклюзив» кибетләр челтәре хатын-кыз бизәнү әйберләренең бөтен нечкәлекләрен истә тота. Монда ниләр генә юк – яшь кызларга чылбырлы мөселман асма бизәгеннән башлап, ханымнар өчен беләзек, айлы алкаларга кадәр бар. Шулай ук егетләргә дә сайлау мөмкинлеге зур: мөселман йоласы буенча туры китереп эшләнгән көмеш ирләр бизәнү әйберләре – йөзек, асма бизәкләр. Шулай ук затлы гәрәбә дисбеләр дә бар. Соңгысы кадерле әниләргә, дәү әниләргә, җомга намазына йөрүче әтиләргә шәп бүләк булачак.

«Эксклюзив» кибетләр челтәре, традицияләрне саклап, шатлык бүләк итә. Килегез, моңа үзегез дә инаныгыз!

сеть ювелирных салонов
ЭКСКЛЮЗИВ

Казан, Р. Зорге ур., 67; Бутлеров ур., 29; Чистай ур., 15/16; Восстание ур., 62.

exclusive.kazan www.exclusive-jewelry.ru РЕКЛАМА.



Бәрәкәтле

Часть культуры, часть стола

Милли сөт бренды

Тәмне көчәйтүче һәм зарарлы буягыч матдәләрсез

Хәләл статуслы ризыклар

40 тан артык төрдәге продукт, шул исәптән корт, катык кебек татар милли ризыклары

+7 (3412) 66-85-70
www.bereketle.com

Буыннан буынга тапшырыла торган традицияләр

Реклама

«АВИАТОР» КАНАТЫ АСТЫНДАГЫ ЭЛЕКТРОН ОАЗИС

Бохараның үзәк мәйданындагы Пои-Калян мәчете диварлары сыек кына сары-кызыл һәм зәңгәр төсләргә буяла. Урта гасырларда төзелгән әлеге бинаны шул рәвешле яктырткач, ул төнге күктә йөзә торган гаҗәеп футуристик объектка әйләнә. Пои-Каляннның туристлар яратып өлгергән әлеге кыяфәтен «Авиатор» сәнәгать технопаркының бер резиденты булган «НИТЕОС» ҖЧҖ компаниясе белгечләре тудырган.



Технологик эшкуарлык оазисы. Технопаркның төп функциясен әлеге билгеләмә төгәл тасвирлый. Казанның Авиатөзелеш районы индустриаль зонасында урнашкан «Авиатор», артык шапырынмый гына, приборлар ясау, электроника, автоматика, үлчәгеч системалары һәм диодлы яктырткычлар өлкәсендә җитештерүне үстерүгә бөтен шартларны да тудыра. Илебез сәнәгатенә нәкъ менә бүген кирәк булган юнәлешләр бу. Әлеге оазисның барлыкка килүе – технологик могҗиза түгел, ә «Авиатор»га нигез салучы, Казанның «серияле эшкуары» Марат Бикмуллин идеяләре эволюциясе нәтиҗәсе.

ҮЗ СЕРИАЛЫНЫҢ ГЕРОЕ

1990 нчы еллар башы. Казан дәүләт университетының физика факультетын күптән түгел генә тәмамлаган Бикмуллинның фатиры «Оста куллар» түгәрәгенә охшаган. Бөтен җирдә төрле калибрлы плата, корпус, үткәргечләр таралып ята. Яшьләр чираттагы тапкыр үзләре проектын ясап, үзләре җыйган антирадар прототибын сыный, шунда ук эшләнеп җитмәгән урынын җиренә җиткерә. «Серияле» җитештерү исә, ягъни антирадар, автосигнализация һәм башка электрон җайланмаларны дистәләрчә данәдә җыю буенча цех ярымҗимерек завод бинасында урнашкан. Марат Бикмуллин үзләре җитештергән продукцияне Казанның автомобиль базарында сата. Бизнес яхшы бара, әмма тиздән үзгәртеп кору башланачак һәм Казан Кулибиннары чит ил җитештерүчеләре белән көндәшлеккә каршы тора алмаячак.

«Әгәр дә 90 нчы елларга кире кайтсам, мин фәнне һәм югары технологияләрне яки бизнесны сайлар идем. Әмма теләсә кайсы бөек идея инвестицияләргә мохтаҗ. Син ул инвестицияләрне йә сорап аласың, йә үзең эшләп табасың. Мин эшләп табу яклы», – дигән булган Марат Бикмуллин әңгәмәләренең берсендә. Һәм ул вакытта, утыз ел элек, электрон җитештерүне туктатып, ул акча эшли башлый. Башта импорт товарлар белән сәүдә итеп, аннан соң – бизнеслар булдырып. Бөтен Татарстанга мәгълүм «БИМ-радио», «Курай» радиосы, Казандагы «Сакура» даруханәләр челтәре, «Мирокон» һәм башка компанияләр әнә шулай барлыкка килә.

ҮСЕШ ФИЗИКАСЫ

Әмма кеше кайчандыр физиканы аңлап, яратып, аннан файдаланырга өйрәнгән икән, ул гомерлеккә физик булып кала. 2000 нче еллар ахырында Марат Бикмуллин электрон һәм электронга якын җитештерүләрне кабаттан торгызу белән шөгыльләнә башлый. Иң уңышлы мәйдан Авиатөзелеш районының сәнәгать зонасы булып чыга. Җитештерүләр башта ике склад мәйданын били, әмма охшаш әйберләр

Фото: Александр Ефремов; мәриянең матбугат хезмәте. РЕКЛАМА

бер-берсенә тартылучан була бит – предприятиеләр саны арта башлый. Оптимальләштерүче, рационализатор һәм синергия идеясе тарафдары булган Бикмуллин предприятиеләрне бер кластерга берләштерү идеясе белән яна башлый. Шул рәвешле 2017 елда «Авиатор» барлыкка килә. Бүген аның 12000 квадрат метр мәйданында югары технологияле продукция җитештерү буенча махсуслашкан 13 резидент компания һәм 23 арендатор эшли.

«Авиатор» резидентлары җитештерә торган җайланмалар һәм җиһазлар чит илләрдә эшләнгән аналоглар белән көндәшлеккә чыдам. Сәбәбе шунда: предприятиеләр үзләре фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшчәнлеге алып бара. Марат Бикмуллин традициясе буенча, алар эшнең бөтен циклын үзләре башкара – продукт булдыруга техник биремне язудан алып аның прототибын җыю һәм җитештерә башлауга кадәр. Боларның барысы да – иң яхшы инженерлык табышларын даими эзләү һәм күпьеллык тәҗрибә нәтиҗәсе.

БЕРЕНЧЕ БИШЛЕККӘ КЕРЕРГӘ

MyHeat компаниясе белгечләре ягып җылыту казаны өчен смартфоннан идарә ителә торган беренче «акыллы» контроллерларын 2014 елда ук уйлап таба. Бүген аның камилләштерелгән модельләре Россия һәм Евразия икътисади берлеге илләрендә дистрибьюторлар челтәре аша уңышлы сатыла. MyHeat белгечләре хәзерге вакытта сәнәгать контроллеры проектын эшли. Тест режимындагы сынаулар якын арада башланырга тиеш.

«Техавтоматика» ЖЧҖ арадаш максатларыннан берсе – компанияләргә ресурсларын һәм чималны исраф итүләрен кыскартырга булышу. Компания автомобильләр һәм техника өчен тапшыргычлар эшләүгә махсуслашкан. Әлеге үлчәгеч җайланмалар ягулыкның, ашлыкның, ашламаның күләмен билгели. 2019 елда «Техавтоматика» (Бортникның Инновацияләргә булышлык итү фондыннан) портатив анализатор эшләүгә грант откан. Моннан тыш, компания GPS-мониторинг системалары һәм кучереп йөртелә торган метеостанцияләр дә эшләп чыгара. Соңгылары, бик күп фунцияләреннән тыш, авыл хуҗалыгы культураларының авырулярын алдан әйтә һәм УФ-нурланышны үлчәү нигезендә су сибү графигын фаразлый ала. Бик күп процесслар югары технологияле җиһазларда башкарыла, әмма монтажлаучы һәм слесарьларның кул хезмәте дә зур роль уйный. Аларның эш сыйфаты автоматлаштырылган металл эшкәртү линияләре күрсәткән нәтиҗәләрдән югарырак.

«Авиатор» резиденты «НИТЕОС» ЖЧҖнең максатлар офыгы киң-табыш күләме буенча Россия җитештерүчеләре арасында беренче бишлеккә керү. Предприятие үзендә җыелган диодлы яктырткычлар ярдәмендә фасадларны яктырту-бизәү белән шөгыльләнә. «НИТЕОС» ЖЧҖ проектларына яктыртуның оста дизайны һәм нәтиҗәле технологик башкару хас. Компания яктыртып бизәгән объектлар арасында – Казанның Кол Шәриф мәчете, «Әкият» курчак театры, Бохарада Пои-Калян мәчете, Мегион, Лангепас һәм Советск шәһәрләре урамнары (Ханты-Манси автономияле округы), Мурманск порты, Иркутск авиация заводы һәм башкалар бар. 13 ел эшләү дәверендә Россия территориясе буйлап 7620 дән артык проект гамәлгә ашырылган.

ЛЕГЕНДАНЫҢ КАЙТУЫ

Физик киртәләрдән тыш, «Авиатор» резидентлары үсешенә киртәләр юк. 12000 квадрат метр мәйданга гына сыймый инде алар. Резидентлыкка

яңа гаризалар арта тора. Оешма Россиянең Кластер, технопарк һәм махсус икътисадый зоналар ассоциациясенә керә. Казан мәйданчыгының тәҗрибәсе бизнесларын үзләренә туры килә торган төбәктә башларга әзер эшкуарларны да кызыктыра. Күпсанлы ачышлар, уйлап табуларга патентлардан тыш, «Авиатор» резидентлары бүгенге вазгыятьтә үтә дә мөһим булган өстенлеккә ия – алар импортка бәйле түгел. Компанияләр 60–75 процентка илдә җитештерелгән компонентлар базасына ирешкән һәм электроника, автоматика, үлчәгеч системаларының тулы бер исемлеге буенча дәүләт заказын үтәүдә катнашырга әзер.

– Безнең технопаркны 200 гектардан артык мәйданда сәнәгать зонасы әйләндереп алган (чикләре Дементьев, Михаил Миль һәм Петр Витер урамнарыннан уза). Җирнең бер өлеше торак комплексы салырга җыенучы төзүчеләрнеке. Авиатөзелеш районы – Казанда электроника, приборлар ясау һәм авиакосмос технологияләренең легендар кече ватаны. Безнең карашка, шул оазисны – җитештерү, фәнни, рекреацион һәм торак зоналарын берләштергән кластерны нәкъ менә биредә булдыру мантыйкка ярашлы булыр иде, – дип сөйли «Авиатор» сәнәгать технопаркының «Микор» Идарәче компаниясе генераль директоры Олег Степанов. Тугыз катлы офис-җитештерү бинасы һәм укыту блогы да булган югары технологияле компетенцияләр үзәге кластерның йөрәгенә әйләнер иде.

Бу идеяне «Авиатор» вәкилләре апрель аенда кризиска каршы штаб эшчәнлеге кысаларында әлеге мәйданга эш сәфәре белән килгән Казан мэры Илсур Метшинга да тәкъдим иткән. «Татарстанда гына түгел, Идел буенда бердәнбер», – дип шәрехләгән «Авиатор»ның казанышларын Илсур Метшин һәм технопаркның искиткеч зур планнарын тормышка ашыру өчен кирәк булган документацияне килештерүдә булышырга вәгъдә биргән.

Казань, ул. Дементьева, 2Б к4
+7 (906) 328-17-66
+7 (917) 227-28-28
aviatorkzn.ru
mail@aviatorkzn.ru
Технопарк АВИАТОР

ТРЕНДТА – ИМИНЛЕК

Металл детекторларының үз модасы бар. Татарстанның «Метаскан» предприятиесе – бу моданы билгели торган предприятиеләрдән берсе.

ТРЕНД №1: КОВИДКА КАРШЫ

Пандемия вакытында «Метаскан» үзенең аркалы металл эзләгечләр конструкциясенә тепловизор өстәде. Өстәвенә, арка аша уза торган бер төркем кешедән һәркайсының тән температурасын үлчәргә сәләтлене. Шул ук вакытта детектор ул кешедәге металл әйберләрне, аларның урнашу рәвешен һәм металл составын (кара яки ак металл), шулай ук килүченең йөзен һәм аның битлек кигәнме-юкмы

икәнлеген таный. Әгәр килүче кешенең үзе белән берәр күләмле металл предметы булса, аның тән температурасы югары яки ул битлек кимәгән икән, хәвеф сигналы кушыла. «Ковидка каршы» детекторлар тиз арада югары уку йортларына, мәктәпләргә, балалар бакчаларына, клиникаларга, Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләрендәге төрледән-төрле бүтән иҗтимагый учреждениеләргә таралды. Күптән түгел бу технологик хит яңа югарылыкка күтәрелде.

– Күптән түгел безнең «капка»ларның вируска каршы тору үзлекләре барлыкка килде. Сканерның өске өлешенә вентилятор, рециркулятор һәм һаваны зарарсызландыру җайланмасы урнаштырдык. Вируслар һәм бактерияләр бу җайланманың ультрашәмәхә нурланышына эләгеп үлә, – дип аңлата «Метаскан»ның баш конструкторы, Идел буе дәүләт технология университеты (Марий Эл) доценты Алексей Фоминых. – Безнең системаларның аермасы шунда: башка маркаларның моңа охшаш җиһазлары белән чагыштырганда, безнеке аша сәгатенә 5 тапкыр күбрәк һава уза.

ТРЕНД №2: КЕЧЕ ҮЛЧӘМ

Алексей Фоминых – металл эзләгеч конструкцияләрнең идеологы гына түгел, аларны эшләүче дә. Берничә шундый технологиягә ул үз компаниясен булдырганчы ук патент алган. Фәнни нигездә эш йөртү һәм практик тәҗрибә бүген «Метаскан»га базар таләпләрен мизгел эчендә эләктереп алырга мөмкинлек бирә.

Әйтик, эпидемиягә каршы чикләүләрнең күпхалыклы чаралар уздырганда үтәлергә тиешлеләре бетерелгәннән соң, компания Эчке эшләр министрлыгы һәм Росгвардия бүлекчәләре тарафыннан актив кулланыла торган портатив сканерлар җитештерә башлаган. «Капка»лар 0,5х0,6 м зурлыктагы, 0,4 м калынлыктагы, авырлыгы 20 кг нан артмаган «төенчек»кә җыеп куела ала. Мондый корылма теләсә кайсы автомобиль багажнигына сыя. Ә төрле бәйрәм-кичәләр уздырылган урында ул янә «капка»га әйләнә. Портатив металл детекторы нибары 1,5 ватт электр энергиясе куллана (шул ук вакытта аналоглары– 30 ваттка кадәр). «Капка»лар гадәти электр челтәреннән (туклану блогы 220 вольтны 12 вольтка үзгәртә), автомобиль розеткасыннан яки үз аккумуляторыннан энергия ала. Аккумулятор тәүлек буе эшләсен өчен,

Фото «Метаскан» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

аны нибары өч сәгать дәвамында кору да җитә. Җайланманың түбән көчәнештә эшләве балалар учреждениеләрендә куллану өчен искиткеч кулай, чөнки анда җиһазларның максималь куркынычсызлыгы таләп ителә. Тиңе юк конструкциягә ия булу бәрабәренә «Метаскан»ның барлык «капка»лары югары сизгерлеккә ия, ә электромагнит нурланыш дәрәҗәсе әйләнә-тирә мохит фоныннан югары түгел.

ТРЕНД №3: ХӘЗИНӘ ЭЗЛӘҮ

«Метаскан» аркалы металл детекторларын гына түгел, кулда тотып йөртелә торган грунт металл эзләгечләрен дә камилләштерә. Ә андыйларга сорау инде берничә ел арта бара. Былтыр бер клиент компаниядән 10 мең сумга металл эзләгеч сатып алган. Өч ай эчендә ул 750 мең сумлык тимер-томыр табып тапшыра алган. Катлаулы икътисади вазгыятьтә бу бер дә начар түгел. Махсус шундый тәвәккәл гражданнар өчен компания процессорлары аналог режимлы схемаларга алыштырылган модельләрне сатуга чыгарган. Бу адым аппаратның үзкыйммәтен арзанайта, шулай ук аны җитештерү эшен импортка бәйлелектән коткара. Билгеле бер составка ия табылдыклар кызыксындырган кешеләр өчен «Метаскан» базарга яңа «Ультраскан» моделен чыгарган. Ул ике төрле генә түгел, ә 180 төр металлны аера-таный. Моннан тыш, компаниянең барлык приборлары хәзер су үткәрми торган итеп чыгарыла. Хәзер тәңкәләрне 1 метр тирәнлектәге суда да эзләргә була.

ТРЕНД №4: ТОРБАЛАРНЫ КҮРҮ

«Метаскан» аппаратларын ТКХ хезмәтләре һәм нефть чыгару компанияләре инде ун елдан артык актив файдалана. Вакыт-вакыт аларга кабель яки торбаларның билгеле бер участогын казып алырга туры килә. Тик безнең климатта фасыллар алмашынган чак грунтка бик нык тәэсир итә. Бер туңган, бер эрегән вакытта, грунт күчә, ә аның белән бергә җиргә күмелгән бөтен нәрсә дә, шул исәптән төрле коммуникацияләр дә читкә шуа. Кабельләр, торбалар, нефтьүткәргечләр билгеле бер шартларда берничә ел эчендә чит-читләргә яки тирәнгә таба берничә метр күчәргә мөмкин. Планга карап эш итүнең бөтенләй файдасы юк, ә теләсә каян казу авария куркынычын тудыра. Бу очракта «Тетта» һәм «Файнд» металл эзләгечләре ярдәмгә килә. Нефтьүткәргечләргә тоташып, кара алтын урлап ятучылар һәм шул үткәргечләргә тоташкан урында хәтта эшкәртү станцияләре урнаштырган бәндәләр булуы сер түгел. Сүз уңаеннан, намуссыз гражданнар зыян салган урыннарны да шул ук металл эзләгечләр ярдәмендә ачыкларга мөмкин.

ТРЕНД №5: ИЛӘП-ЧИСТАРТЫП БАРУ

Станокларга һәм чит ил җиһазларына запас частьлар кыйммәтләнү шартларында предприятие ватылуларны булдырмый торган технологияләргә көннән-көн ешрак мөрәҗәгать итә. Чимал массасына эләккән кадак яки ниндидер тышлау материалы кисәге тулы бер җитештерү линиясенең туктальшына китерергә мөмкин. Металл сизә торган тапшыргычларны көйләү күпкә нәтиҗәлерәк. «Метаскан» инде берничә ел пилорамаларны металл детекторлары белән тәэмин итә. Күптән түгел компания клиентлары исемлегендә хастаханәләр дә барлыкка килгән. Кер юу машиналарына шприц, энә, скальпель һәм башка инструментлар эләкмәсен өчен, алар сканерлар сатып ала.

– Март аенда безгә яшел зоналарда мүлчәләү (агач калдыкларын ваклау) белән шөгыльләнә торган компаниядән кызыклы заказ килде. Мүлчә аппараты куакларны, зур булмаган агачларны, таякларны кисеп ала да, шул йомычкаларны ваклап, җиргә сибеп тарата. Бу аппаратта кыйммәтле фрезалар тора. Аларга тимерчыбык эләксә, агрегат сафтан чыга, – ди Алексей Фоминых. – Без мондый ысулны кулланырга булдык: мүлчә аппараты алдыннан терәк тәгәрмәчләрдә безнең металл эзләгечнең тапшыргычы бара. Ул берәр металл әйбер яки тимерчыбыкны күреп алуга, агрегат шундук туктый.

Күп кенә җитештерүчеләр клиентларның куркынычсызлыгы һәм иминлеге турында кайгырта. Әйтик, «Основной продукт» компаниясе металл детекторларны кукуруз таякчыкларын җитештерү линиясе өчен сатып алган.

ТРЕНД №6: ШАРТЛАУГА КАРШЫ

«Метаскан» тәҗрибәсе оборона сәнәгате өчен дә бик файдалы. Хәзер компания пластик шартлаткыч җайланмаларны таба торган металл эзләгеч проекты белән мәшгуль. Бу шартлаткычларның составына металл элементлар керә, димәк, аларның кая куелуын сканер ярдәмендә билгеләргә була. «Метаскан» зур тирәнлектәге бик вак металл детальләрне сизә алачак җайланма булдырырга планлаштыра.

ТРЕНД №7: УНИВЕРСАЛЬ

– Безнең компаниянең шигаре – «Без үлчәүләр өчен теләсә нинди электрон җайланма ясый алабыз». Проектны тормышка ашыру вакыты аның катлаулылыгына бәйле. Әгәр без аны мина эзләгеч очрагындагы кебек нульдән башласак, беренче прототипны якынча ике айдан җыябыз. Безнең ассортиментта төрле модификациядәге детекторларның һәм металл эзләгечләрнең 40тан артык моделе бар, – дип сөйли Алексей Фоминых. – Хәзер без, Россия электроникасын җитештерүче компания статусын алу өчен, теркәү процедурасын узабыз. Интеллектуаль милеккә 12 патентыбыз бар. «Метаскан» импортны алыштыру юнәлешендәге продуктлар булдыру өчен кирәкле ресурсларга ия. Бу эштә безгә дәүләт тә, булачак заказчыларыбыз да ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

METASCAN
metascan-md.com
тел. 8 800 444-00-27
info@metascan-md.com
grunt. metascan-md.com

ИМАНЛЫ ҖИТӘКЧЕ

Күз алдына китерегез: механизатор тракторы янына килә дә карточкасын куя: шул мизгелдә компьютер аның эш сәгатен исәпли башлый. Ә кузгалып киткәч, эшченең хезмәт хакы икенче бәя белән санала. Кырга чыккач, өченче бәя... Әле ун ел элек кенә болар барысы да могҗиза кебек тоелса, бүген бу көндәлек тормышта кулланыла. Актаныш районының «Әнәк» агрофирмасында әнә шундый заманча технологияләр белән эшлиләр.

БАТЫРЛЫК

Фарис Гаяз улы Фәтхиевне Актаныште белмәгән кеше юк. Алай гына дип әйтү дөрес түгел, республиканың авыл хуҗалыгы тармагы өлкәсендә эшләүчеләр өчен ул яхшы таныш: ТРның атказанган икътисадчысы, «Ел җитәкчесе – 2021» конкурсының «Предприятияне цифрлаштырып үзгәртү» номинациясе җиңүчесе. Ул җиңгән бәйге, яулаган дипломнар турында язсаң (шул исәптән Россия күләмендәге), бер генә бит җитмәячәк.

«Әнәк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Аның карамагында 7 мең баш мөгезле эре терлек, 28 мең 900 гектар сөрү җирләре исәпләнә. Югары егәрлекле заманча техника, ашлык саклау өчен зур амбарлар, машина-трактор паркы, ашханә, администрация бинасы – болар әле Әнәк авылында гына. Тагын бүтән авылларда да шундый парклар бар. Кыскасы, бүген «Әнәк» агрофирмасы – агрохолдинглар көнләшерлек хуҗалык!

Язгы чәчүгә йөз процент әзер алар. Ә бит 2007 елны, эш башлаган чакта, Фарис Гаяз улы үзе дә моның кадәр колач җәярбез дип уйламаган.

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

– Безнең басуларны үлчисе, машина-тракторларның кайсы басуга барганын, күпме чәчкәнен-урганын, хәрәкәт тизлеген тикшереп, санап торасы юк, – дип елмайды җитәкче. – Цифрлаштыру технологиясе буенча тракторлардагы датчиклар офистагы белгечләргә минут эчендә хәбәр җиткерә. Бездә эшләмичә генә акча алып булмый, бөтен җирдә гаделлек.

Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, Фарис Гаяз улы баш икътисадчы, баш хисапчы булып та эшли. 2005 елда исә Актаныш сөт заводына директор итеп куялар. Ике елдан артык эшләгәннән соң, үзе теләп китү турында гариза яза. Югыйсә призлы урыннар алып, гел макталып киләләр, хезмәт хакы да әйбәт. Тик аның күңеле җир эшенә тартыла.

– Сөт заводына кадәр «Нур Баян» хуҗалыгында баш икътисадчы булып эшләдем мин, – диде Фарис Фәтхиев. – «Нур Баян» хуҗалыгының «Әнәк» дип аталган тармагы бар иде, 2001 елда оештырдык без аны. Җитәкчелек белән килешеп, «Әнәк» 2007 елның 18 апрелендә аерылып чыкты. Язгы чәчү эшләрен башлар вакыт – 5 мең 300 гектар сөрү җире бар. Техника бик иске, проблемаларны саный китсәң... Тик Аллаһы Тәгалә юнь бирә ул.

Ул елны «Әнәк» агрофирмасы чәчү эшләрен районда иң соңгы булып тәмамлый. Башка хуҗалыклар эшләрен 20 майга төгәлләсә, алар исә Сабан туеннан соң да чәчү чәчә. Әлбәттә, район җитәкчелеге моңа рәхмәт әйтми. Ләкин ул елны яңа аерылып чыккан хуҗалыкның башка чарасы булмый – ягулык юк, ашламага кытлык, чәчүлек орлык җитәрлек түгел... Фарис Гаяз улы һәр хуҗалыктан диярлек бурычка чәчүлек орлык, ашлама җыеп йөри. Хәтта кырда эшләүчеләрне көн дә үз акчасына кафеда ашата. Әлеге дә баягы, ашханә дә юк бит.

– Буш кул белән аерылып чыктык дисәм була, – дип дәвам итте Фарис Гаяз улы. – Утырып эшләргә кабинет та юк иде, башта мәдәният йортының бер бүлмәсен алып тордык. Аның каравы, кадрлар җитәрлек иде. Тәҗрибә күрсәткәнчә, монысы бик зур әйбер.

Бәхеткә, ул елны һава шартлары әйбәт туры килә: иген күкрәп үсә. Иң азактан чәчелгән кырларга чүп чыкмый кала. Нәтиҗәдә, шул ук елны районда иң югары уңыш алалар. Һәм барлык бурычлардан котылалар. Шуңа өстәп, район хуҗалыклары арасында оештырылган бәйгедә 500 мең сумлык ашлама да оталар. Эш башлаган хуҗалык өчен бу зур ярдәм була.

– Иң соң чәчеп тә, иң югары уңыш алуны могҗиза дип кабул иттегезме? – дим.

– Аллаһы Тәгаләнең безгә ярдәме булды. Тагын шунысын да әйтим: ул елларда кредит аласы җайлы иде. 2007 елда «Россельхозбанк» белән килешүләр төзеп, кредитка техника алдык. Бизнес-планың булса, зур суммалар алып була иде. Ә бизнес-план ул минем гел башта йөрде.

2008 елда «Әнәк» агрофирмасына тагын дүрт хуҗалык кушыла. Аларның хәлләре мөшкел була, берничә ай хезмәт хакы түләнмәгән, бурыч өстенә бурыч...

– Әле үзегез дә аякта нык басып тормагансыз. Бурычка чумган хуҗалыкны алырга ничек батырчылык иттегез? – дим.

– Чәчү өчен орлыклары, кадрлары бар иде аларның. Ә бу инде ярты уңыш дигән сүз. Эшне дөрес оештырып җибәрсәң, сазлыктан чыгып булачагын белдем.

«БАРЫСЫ ДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘДӘН...»

Фарис Гаяз улы 2008 елдан бирле намазда. Сөт заводында эшләгән чагында ук ике дөньяны бергә алып барырга кирәклеген күңеле белән тоя башлый. Инде «Әнәк» агрофирмасын җитәкли башлагач, бу изге ниятен тормышка ашыра.

– Бервакыт күптәннән аралашып яшәгән Марсель абый Түбән Камага – җомга намазына барырга чакырды, – дип искә алды әңгәмәдәшем. – Катькат шалтыратты. Тәвәккәлләп, бөтен эшемне ташлап, әнә шулай Түбән Камага чыгып киттем. Бар дөньямны онытып вәгазь тыңладым. Аннан соң аерым да хәзрәт белән дин темасына сөйләштек. Кайтырга чыккач кына, агрофирма эшләре искә төште. Акча күчәргә тиеш иде, ашыга-кабалана банкка шылтыраттым, акча килгән. Икенче эш буенча янә телефон номерын җыйдым, уңай хәл ителгән. Кыскасы, бөтен эш эшләнгән. Шуннан үземә нәтиҗә чыгардым...

Фарис Гаяз улы бүген фәкать Аллаһ кушканча яшәргә тырыша. Хәтта башкаларга комачауламас өчен агрофирма эшен дә артык киңәйтми.

– Тормышың хәләл була икән, проблемалар азая, – ди җитәкче. – Сөт эшкәртүне дә җайлыйк, тәүлегенә ничә тонна сөт савабыз, диләр миңа. Ләкин мин бит аннан икенче кешенең эшенә аяк чалачакмын. Ә булганына канәгать итә белергә кирәк.

Фарис Гаяз улы җаны-тәне белән хәмергә каршы. Бүген ул хуҗалыгында эчкечелеккә юл куймаска тырыша. Һәр җыелышта халыкка дин кануннарын аңлата, аларны Аллаһ кушканча яшәргә өнди.

– Бик күп дин китаплары укыйм, – диде җитәкче. – Кеше гел үсештә булырга тиеш. Тагын иманны ныгыту, Аллаһка якынаю өчен Хаҗга барырга киңәш итәр идем. 2013–2014 елларда Хаҗга бардым. Яңадан биш тапкыр Гомрә хаҗында булдым. Әле быел да февральдә бардым. Шуннан әйтеп бетергесез бер рәхәтлек алып кайтам.

Фарис Гаяз улы хәләл җефете белән бер ул, ике кыз тәрбияләп үстергән. Җиде оныклары бар. Улы этисенең уң кулы, директор урынбасары эшләрен алып бара, ике кызы исә әлегә декрет ялында. Ирләре белән Әнәктә яшиләр. (Сүз уңаеннан, «Әнәк» агрофирмасындагы техникаларны цифрлаштыруны нәкъ менә кияүнең берсе – Марат Кинеев башкарган.)

Яшьләр дигәннән, ТР Дәүләт торак фонды белән берлектә Әнәктә яшь гаиләләр өчен уналты яңа заманча йорт салганнар. Төп шарт – ир яки хатын агрофирмада эшләргә тиеш. Нәтиҗәдә, шушы йортларда гына да иллегә якын бала тәрбияләнә. Димәк, Әнәкнең заманча балалар бакчасы, урта мәктәбе әле гөрләп торачак дигән сүз.

– Авыл хуҗалыгы тармагы отышлы бизнес ул, – диде саубуллашканда Фарис Гаяз улы. – Үзең яхшы итеп җитештерәсең, үзең сатасың. Дөрес гамәлне кылып, коллективны туплап эшлисең икән, уңышка ирешү авыр түгел. Җир эшен Аллаһы Тәгалә дә ярата, зур сөннәт санала ул. Шуның өчен яратып эшлим.

...Шулай да була икән! Фарис Гаяз улы янынан икенче бер дөнья ачып кайттык. Дөньялык белән бергә ахирәтне кайгыртып яшәүче сирәк, гаҗәп җитәкче ул.

PRESSA

КУКМАРА ИТЕКЛӘРЕ: КИЕП ЙӨРҮ ҮЗЕ БЕР БӘХЕТ

Менә гасыр ярым инде Кукмара киез итек басу-киез комбинатында басылган данлыклы аяк киемен яратып кияләр. Гаҗәпләнәсе дә юк: киез итекнең өстенлеге бәхәссез! Аннан да уңайлырак, экологик яктан чиста һәм җылырак аяк киемен уйлап тапканнары юк әле. Кукмара осталары баскан йөзләрчә заманча модель арасында исә курыкмыйча подиумнарга менгерердәйләре дә бар.

БҮГЕН КИЕЗ ИТЕК ЯНӘ МОДАДА

Сүз дә юк, соңгы елларда киез итек дөньякүләм масштабта трендка әйләнде. 2022–2023 елларның кышына да аларга уңыш юрыйлар.

– Әлбәттә, заманча итекләр ак-сыл-соры яки кара «баба»ларына караганда күпкә нәфисрәк. Киез итеккә бәясе ягыннан да, кулланылышы ягыннан да һәрвакыт зарурлык булган. Бүген әлеге аяк киеме уңайлы булуы белән аерылып тора, – ди «Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» АҖ генераль директоры Ләлә Шәрипова. – Бүген безнең модельләр шул дәрәҗәдә камилләштерелгән ки, аяк киеменең матурлыгына карап, аның тыйнак кына киез итек булуын тиз генә тану мөмкин дә түгел.

Кайчагында без үзебез дә комбинатта җитештерелгән продукциябезне йолдызлар һәм медиашәхесләр аягында күрәбез. Никадәр зур сайлау мөмкинлеге була торып та нәкъ безнекен үз итүләре сөендерә.

СЫЙФАТЫ ЮГАРЫ, БӘЯСЕ АРЗАН

Данлыклы брендның киез итекләрен җитештерү өчен комбинатта бары тик сыйфатлы сарык йоны гына файдаланыла, аны озак еллар буе сыналган сатучылардан гына алалар. Һәрбер партиясен җентекләп тикшерәләр. Әмма моннан тыш, киез итек җитештерү өчен җилем, олтан, велюр, йон тукыма, молния-каптыр-

Фотолар «Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» АҖнан алынды. РЕКЛАМА

малар, шнурлар һәм башка бик күп нәрсә кирәк була әле... Фурнитура яки компонентларның күп өлеше Россиядә җитештерелми.

Киләчәктә дә уңышка ирешү өчен бүген югары сыйфатны һәм арзан бәяләрне саклап калу мөһим, дип саный комбинат хезмәткәрләре.

Һәм алар булдыра да! Икътисадта вазгыять катлаулы булса да, бүген биредә җитештерү куәтен арттыралар. Кукмаралыларны киез эшләнмәләргә, балалар итекләренә ихтыяҗ арту гына түгел, бер урында таптанганны кичерми торган көндәшлек шартлары да яңа үрләргә этәрә. Ә сатып алучыны һәрвакыт табып була, дип ышана алар – Россия зур, ә товар уникаль һәм кызыклы.

ЫШАНДЫРА ТОРГАН ТОТРЫКЛЫЛЫК

Бер тотам гади сарык йоны уңайлы җылы аяк киеменә әйләнә: җитештерү процессы һәрвакыт сихерле, ә киез итек басу – бигрәк тә. Йон һәм кеше кулы – башка берни дә юк. Хәер, тагын бик күп хезмәт һәм көч кирәк икән әле.

Кукмара киез итек басу-киез комбинаты хезмәткәрләре массакүләм ихтыяҗ булган продукция җитештермәгәннәрен яхшы аңлый. Глобаль җылыну һәм аяк киемнәре муллыгы шартларында йоннан эшләнгән аяк киеменә ышаныч тудыру өчен аның кирәклегенә инану, әшеңә тулаем бирелгәнлек, сыйфат югарылыгы һәм даими үсештә булу кирәк. Биредә нәкъ шундыйлар эшли дә, шунлыктан чираттагы икътисадый кризис аларны куркытмый.

Комбинат эшче хезмәткәрләрне тотрыклылыгы, нигездә бер сменалы эше белән җәлеп итә. Һәр хезмәткәр бушлай кайнар аш, тулы социаль пакет белән тәэмин ителә. Тынычсыз вакытларда тотрыклылык тыныч-

Комбинатның теләсә кайсы хезмәткәре Кукмара итеген тышкы кыяфәтеннән үк танып ала. Табанында предприятиенең логотибы булганга гына да түгел.

Киез итек бары тик юылган һәм үсемлек калдыкларыннан арындырылган чиста сарык йоныннан җитештерелә. Аны басканда кислота кулланылмый, бары тик төрле температуралы су һәм пар гына кирәк. Киез итек җитештерү циклының 35 процентына кул хезмәте керә. Булачак итекнең калынлыгы һәм тыгызлыгы кул белән капшап карап билгеләнә. Фәнни-тикшеренү институтында эшләнгән һәм аякның анатомик формасын кабатлаган калыпларга салына. Йөнтәслектән станокларда арындыралар, шуннан соң гына киез итек матурая. Шул ук вакытта йонның файдалы үзлекләре тулысы белән саклана. Киез итекләр тыгыз да, кирәгенчә генә йомшак та килеп чыга. Кигәндә утырмый, формасын саклый һәм озакка чыдый. «Кукмара итекләре» – һәркем алырлык бәягә табигый аяк киеме ул.

ландыра, иртәгәге көнгә ышаныч бирә. Кукмара киез итек басу-киез комбинатында гаилә белән генә түгел, ә берничә буын вәкилләре эшли икән – димәк, бу комбинатка эш бирүче буларак тулы ышаныч турында сөйли.

ЗӘВЫК ЭШЕ: ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ САТЫП АЛУЧЫ ӨЧЕН

Сатып алучы һәрвакыт нindидер яңалык көтә, һәм аның теләкләре көннән-көн үзгәреп тора. Әмма Кукмара киез итекләре арасында биш һәм аннан да күбрәк ел дәвамында чыгарыла торган модельләр дә бар. Алар уңайлы, универсаль һәм тугры сатып алучылары – өлкән буынның таләпләренә тулысынча җавап бирә: составының табигыйлыгы, уңайлылыгы, сыйфаты һәм һәрвакыт сатуда булуы белән сөендерә. Бер парны киеп туздыргач, алар яңадан нәкъ шундыйны сатып ала.

Хәзерге заман кешесе гел хәрәкәттә, ә мода ирекле. Сатып алучының теләкләрен алдан белеп, комбинат хезмәткәрләре ел саен гамәлдәге модельләрне яңартып тора, яңа вариантлар тәкъдим итә.

Быел бренд дистәдән артык яңа модель белән тулыланачак.

Серияне җитештерүгә кую процессы тиз була алмый, әмма ел саен яз көне башлана торган бөтенроссия аяк киемнәре күргәзмәләре җитештерүне «тонус»та тота. Алар бөтен тенденцияләрне, аяк киемнәре дөньясында яңалыкларны белеп тору мөмкинлеген бирә. Биредә комбинат вәкилләре үзләренең коллекциясен тәкъдим итә, даими сатып алучылары белән очраша һәм яңаларын таба. Нәкъ менә әлеге күргәзмәләр дизайнерларга яңа идеяләр табарга ярдәм итә, кызыклы һәм заманча модельләр булдырырга илһамландыра.

МИЛЛИ КОЛОРИТ

Традицион рәвештә комбинат ел саен Россиянең төрле шәһәрләрендә уза торган федераль Сабан туена, Бөтенроссия авыл Сабан туена сату белән чыга.Һәм аларның сәүдә ноктасы янында һәрвакытта да сатып алучылар бик күп була. Нәкъ менә Сабан туйларына дип комбинатта милли бизәкләр чигелгән киез эшләнмәләр җитештерә башлаганнар да инде. Киез түбәтәйләр беренче чиратта алынып бетә. «Читек» стилендәге итекләр бәйрәм кунакларын таң калдыра. Чигүле башмакларны бүләк итеп тә, Татарстаннан сувенир итеп тә алалар. Күпләр чит җирләрдә яши бит. Һәм Кукмара товарлары алар өчен туган җир, татар мәдәнияте турында җылы хатирәләр ул. Тукай исемендәге аэропортта, Казанның Бауман урамында татар милли бизәкләре чигеп

төшерелгән башмаклар һәрвакыт сатуда бар. Кукмара киез итек басу-киез комбинатында намазлык, башмак яки оек, аларны саклау өчен уңайлы букчадан гыйбарәт намаз кирәк-яраклары җыелмасы да җитештерелә.

ГОМЕРЛЕК ЯРАТУ

Бүген Кукмара киез итек басу-киез комбинаты җитештерә торган продукцияләр каталогында 300дән артык модель бар. Аларны өч җитештерү линиясе башкара. Бирердә киез эшлиләр, итек басалар, өйдә кия торган, көндәлек киез аяк киемнәрен тегәләр. Шулай ук 100 процент сарык йонынннан юрган, мунча комплектлары, йон тутырылган киез жилет, милли түбәтәйләр җитештерәләр.

– Кешеләр безнең фирма кибетенә беренче тапкыр килгәч, йоннан җитештерелгән продукциянең төрле булуын күреп аптырап кала. Бик күпләр йоннан киез итек кенә басып була дип белә, – ди сату бүлеге башлыгы Диана Галәветдинова. – Өйдә кия торган аяк киеме бездә сату буенча беренче урында бара. Киездән тегелгән башмаклар гомерлеккә. Бер тапкыр андый башмакны киеп карасагыз, башка төрлесенә күзегез дә төшмәячәк. Йомшак, җылы, уңайлы, дәвалый торган, табигый...

Хәзер урамда йөри торган киез аяк киеме дә популярлаша бара. Безнең бай ассортимент теләсә кайсы ихтыяҗны канәгатьләндерә ала: балыкка киеп барыр, урамда йөрер өчен киез каталар, көн саен кия торган ботинка һәм итекләр, кедлар, кроссовкалар, ягып җылытылмый торган складларда эшләгәндә кияр өчен пима һәм кыска кунычлы итекләр, башмаклар, киң олтанлы аяк киемнәре, офиста кияргә модалы лоферлар, яшьләргә челси (шнурсыз ботинка) һәм берцлар (хәрби ботинка).

Шунысы шатландыра: сатып алучылар табигый һәм сыйфатлы аяк киемнәренә өстенлек бирә башлады. Иң мөһиме: үзләре өчен сарык йонының төп үзлекләрен ачты. Ул кан әйләнешен яхшырта, буын һәм мускуллардагы авыртуны баса, коры җылы бирә, «сулый». Йон – чыннан да табигатьнең тиңсез бүләге.

Хәзер без үз алдыбызга шундый максат куябыз: яшьләр өчен киездән заманча коллекция булдыру. Үсеп килүче буын балачактан сәламәтлекне саклауга йөз тоткан дөрес аяк киеме кию гадәтен булдырырга тиеш.

Кукмара киез итекләре уңышының сере нидә? Минемчә, бүген җитештерелә торган киез итекләр инде модадан артка калган дип кабул ителми. Заманча модельләр теләсә кайсы образга һәм стильгә туры килә. Хәзер үз-үзен хөрмәт итә торган һәрбер хатын-кызның кышкы коллекциясендә киез яки тула итек бар. Ⓣ

2020 елда «Балачак унъеллыгы» Бөтенроссия проекты кысаларында Татарстанда «Яңа туган балага бүләк» акциясе башлап җибәрелгән. Бүләккә бирелә торган әйберләрнең барысы да Татарстанда җитештерелгән, һәм алар арасында Кукмара киез итек басу-киез комбинатының балалар итеге белән сарык йонынннан сырылган балалар юрганы да бар.

КУКМОРСКИЕ ВАЛЕНКИ

Күпләп сату бүлеге:
e-mail: opt@kvvk.org
Телефоннар: (84364) 2-08-31, 8-800-250-11-32

Фирма кибете
Адрес: Кукмара шәһәре, Вахитов урамы, 1.
Телефон: (84364) 2-08-78

АРЗАН БӘЯГӘ СЫЙФАТЛЫ ДӘВАЛАУ

Сыйфатлы стоматология ярдәмен хәзер Россиянең иң яшь шәһәрләреннән берсе Иннополиста да алырга мөмкин. Бөтен гаиләгә тәгаенләнгән «Шәһәр стоматологиясе» заманча клиникасы Спорт урамы, 116 адресы буенча ачылган.

14 ел дәвамында «Шәһәр стоматологиясе» челтәре теш дәвалау-сәламәтләндерү буенча тулы комплекслы хезмәт күрсәтә торган клиникалар төркеме булып үсә алган. Югары квалификацияле белгечләре, һәртөрле хезмәтләр күрсәтә алуы һәм инновацион технологияләре белән «Шәһәр стоматологиясе» дистәләрчә мең пациентның ышанычын яуларга өлгергән һәм уңышлы эшчәнлеген дәвам иттерә.

БАЛАЛАР ҺӘМ ӨЛКӘННӘР ӨЧЕН

Иннополиста өлкәннәр һәм балалар өчен стоматология клиникасы ачылу шәһәр халкына гына түгел, ә Татарстанның якын-тирә район һәм шәһәр кешеләренә дә сыйфатлы һәм артык кыйммәт булмаган бәягә теш дәвалау мөмкинлеген бирә. Клиникада заманча дәвалау-диагноз кую җиһазлары белән эшлиләр, бу исә һәрбер пациентка үз дәвасын табарга мөмкинлек бирә.

АВЫРТУ ҺӘМ КУРКУСЫЗ

Теш табибы янында куркуын җиңә алмаган балалар һәм өлкәннәр өчен белгечләр бирегә седация ысулын куллана. Бу азот оксиды белән кислород кушылмасы, аның үзенә күрә бер тәмле, татлы исе бар. Пациент аны махсус битлек аша сулый һәм күпмедер вакыт узуга тынычлана. Седация куркынычсыз технология булып тора һәм кыска гына вакыт эчендә организмнан тулысынча чыгып бетә. Әлеге процедура бигрәк тә балаларның тешен дәвалаганда киңәш ителә, чөнки нәкъ менә бала вакытта теш табибыннан курку формалашып кала.

Матур җиһазлар, уңайлы көтү зоналары, хезмәткәрләрнең ачык йөзе клиника турында уңай тәэссоратларны тагын да көчәйтеп җибәрә. Бәләкәй пациентларны кайгыртып, Иннополис-

Фотолар «Шәһәр стоматологиясе» клиникасыннан алынды. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



ның «Шәһәр стоматологиясе»ндә интерактив уеннар, балалар өчен китаплар һәм уенчыклар зонасы да булдырылган.

МЕДИЦИНА ТУРИЗМЫ

Күрше шәһәр һәм бистәләрдән килгән пациентлар өчен клиникада табибка язылу эше шундый итеп оештырылган ки, кыска гына вакыт эчендә дәвалау мөмкин кадәр тулы һәм тиз башкарыла. Шуңа да пациентлар клиникага килгәч, көнкүреш мәшәкатьләреннән һәм эшләреннән арынып, тулысы белән теш дәвалауга бирелә ала, буш вакытта исә кояш баешының гүзәллеге һәм фән-техника могҗизалары белән хозурланырга була.

Беренче тапкыр килгәч, табиб белән тешне дәвалау планлаштырыла, консультация бирелә, диагноз куела. Иң заманча 3D-томограф бөтен казналыкка югары сыйфатлы компьютер томографиясе ясау мөмкинлеге бирә. Аның ярдәмендә табиб, клиник вазгыятьне күреп, яшерен проблемаларны ачыклый. Алга таба белгеч, вакытын, ничә тапкыр килергә кирәклекне һәм дәвалау хакын әйтеп, тешне дәвалауның тулы планы вариантларын тәкъдим итә. Иң соңыннан пациентка, уңайлы вакытны сайлап, дәвалануга килү көне билгеләнә.

Клиникада теш дәвалау буенча барлык төр хезмәтләр дә күрсәтелә: авыз куышлыгының профессиональ гигиенасы, теш һәм уртларны дәвалау; эстетик стоматологиянең барлык төрләре: традицион терапевт процедураларыннан башлап – реставрация – керамик протезлар һәм цирконий диоксидыннан винирлар куюга кадәр. Без Швейцария, Франция һәм Израильдә эшләнгән, вакыт сынавын үткән имплантлар куябыз, шулай ук үтә төгәл компьютер диагностикасы ясыйбыз, хирургия дәвалавы һәм теш агарту процедураларын үткәрәбез.

Әгәр дә сез теш дәваларга планлаштырасыз икән, клиника администраторы белән элемтәгә керегез. Без, барлык нечкәлекләрне искә алып, сезгә бик теләп ярдәм итәрбез. «Шәһәр стоматологиясе» – арзан бәягә сыйфатлы дәвалау ул! Т

Иннополис ш., Спорт ур., 116.
+7 (843) 216-87-16;
Язылу whats app
һәм telegram
+7 986-900-26-59 аша

«ИВОЛГА»: ИННОВАЦИЯЛЕ ШИФАХАНӘ

Баулының матур урман-парк зонасында «Иволга» шифаханә-профилакторие урнашкан. Ял итүчеләргә сәламәтлек, илһам һәм уңай хис-тойгылар бирер өчен медицина инновацияләре гамәлгә кертелә торган урын ул.

– «Иволга»да тулы кыйммәтле һәм сыйфатлы дәвалану, тыныч һәм рәхәтләнеп ял итү өчен барлык шартлар да тудырылган, – ди шифаханәнең баш табибы Римма Мөхәммәтшина. – Киләчәккә бик күп проектларыбыз бар, һәрвакыт кешеләр турында кайгыртkan «Татнефть» компаниясе җитәкчелеге ярдәме белән аларның һичшиксез тормышка ашырылачагына ышанам. Шулай булгач, безгә рәхим итегез, монда көч туплап, сәламәтлекне ныгытачагыгыз һич шөбһә уятмый!

ИММУНИТЕТ

COVID-19 кичергән кешеләр өчен шифаханәдә махсус тернәкләндерү программасы эшләнгән. Ул консультация, диагностика, гомуми терапия кебек күп төрле хезмәтләрне колачлый. Тикшеренүләрнең күләме, дәва төрләре һәм процедураларның саны санаторий-профилакторий белгече тарафыннан һәр кешенең авыруын һәм аңа нәрсә яраганын-ярамаганын исәпкә алып билгеләнә. Дәресләр индивидуаль рәвештә дә, төркем белән дә үткәрелә. Монда скандинавия йөреше, йөзү, аквааэробика түгәрәкләре бар. Кыскасы, стрессны киметеп, иммунитетны күтәрәләр.

САВЫГУ-ТЕРНӘКЛӘНҮ

«Иволга»да үзәк нерв системасына һәм терәк-хәрәкәт аппараты функцияләренә зыян килгән пациентларны савыктыру юнәлешендә бай тәҗрибә тупланган. Rea Terra биологик элементәле медицина тредмилы, HUBER нейромеханиканы торгызу һәм диагностикалау аппараты, аякларга актив һәм пассив хәрәкәт терапиясе өчен «Имитрон» йөреш имитаторы, хәрәкәтләрне координацияләү һәм тигезлек саклауны яхшырту, балансны торгызу өчен биологик элементәле «Баланс-мастер» тренажеры, умыртка баганасын тартып дәвалау ысулы – болар барысы да пациентка төрле травмалардан һәм операцияләрдән соң аякка басуда һәм күпчелек неврологик хасталарны дәвалауда нәтиҗәле ярдәм күрсәтү мөмкинлеге бирә.

ЯЛ

Шифаханәдә диетик һәм рациональ туклануга да югары технологияле процедуралар комплексы дәрәҗәсендәге игътибар бирелә.

Көндәлек өч тапкыр ашату төрле ихтыяҗлары һәм авырулары булган кешеләрне күздә тотып көйләнә. Сүз уңаеннан, күптән түгел генә шифаханә туклануның «Хәләл» стандарты таләпләренә җавап бирүен раслаган таныклык алган.

Ял итүчеләр яши торган бүлмәләр белән дәваханәнең заманча бинада бергә урнашуы торак корпустан чыкмыйча да дәвалау процедураларын узу мөмкинлеген тудыра.

ДӘВАЛАУ

«Иволга» шифаханә-профилакториендә пациентлар өчен берничә дистә төрдәге дәвалау һәм сәламәтләндерү процедураларын күздә тоткан куәтле дәвалау-диагностика комплексы эшли.

Санаторий-профилакторий коллективында 25 медицина белгече, шул исәптән 8 тар белгечлек табибы исәпләнә.

ГАРМОНИЯ

Җилкәләрне киереп турайтырга, яңа көнне елмаеп каршыларга, стрессны коеп төшерергә, туйганчы кислород суларга... Сәламәтлек өчен тагын нәрсә шәбрәк булырга мөмкин? Әгәр моңа савыктыру һәм профилактиканың заманча программаларын, иҗади рухлы медицина кадрларын, яшәү һәм ял итү өчен уңайлы шартларны, тулы кыйммәтле һәм тәмле ризыкларны, зиннәтле мохитне дә өстәсәң, үз сәламәтлекләренә сак карарга күнеккән кешеләр арасында «Иволга»ның ни өчен шулай популяр булуы аңлашыла.

АКТИВЛЫК

«Иволга»да балалар почмагы, балалар һәм өлкәннәр өчен аерым бүлемле ябык йөзү бассейны, төрек һәм фин сауналары; заманча тренажер залы; терренкур; зур теннис өчен корт; балалар өчен уен мәйданчыгы; волейбол кыры; шифаханә-профилакторий янәшәсендә футбол кыры; пинг-понг өчен теннис өстәле бар. Т

Фото: ivolga.tatneft.ru. РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

СЕЗНЕҢ БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛГАН МАТУРЛЫК

Заманча косметология технологияләре безнең яшьне мәхәббәт өчен генә түгел, үзебез өчен дә яшәртергә сәләтле.

Бервакыт Казандагы «СкинМед» косметология клиникасына популяр блогер-нутрициолог мөрәҗәгать итә. Кызны пигментлы тап борчый. Моңа кадәр ясалган косметология процедуралары булышмый, һәм икенче бер клиника табибы пикосекундлы лазер тәкъдим итә. Россиядә барлыгы шундый җиде аппарат бар, шуның берсе нәкъ менә «СкинМед»та. Беренче мәртәбә куллану ук нәтиҗәле булып чыга. Тиздән тап бөтенләй күренми башлый. Шулай да кызны иң тәэсирләндергәне – битнең яктырып китүе, бит тиресе тон бирүче кремнан башка да тип-тигез.

«СкинМед» клиникасында операциясез яшәрү технологияләрен куллану портфолионы моңа охшаш тагын бик күп тарихлар белән баета ала. Аларның саны күбәйгәннән күбәя бара, чөнки Альтера-терапия* һәм пикосекундлы лазер** бүгенге көндә – дөнья косметологиясе тренды.

– Бервакыт мин Парижда узган халыкара косметология конгрессында катнаштым. Шунда пикосекундлы лазер презентациясен күрдем. Бу технология мине сокландырды! – дип сөйли «СкинМед» директоры Гүзәл Галиева. – Аннан соң мин әлеге технологияне үземдә сынап карадым. Мин акне һәм пигментлы таплар белән интегәм. Биттәге җөйләрне һәм тапларны нәкъ менә пикосекундлы лазер яхшы бетерә. Нәтиҗәсе шаккаткыч булды. Үземдә кулланып караган зур тәҗрибәдән чыгып шуны әйтә алам: башка бер генә процедура да мондый нәтиҗәне бирми.

Лазердан аермалы буларак, Альтера-терапия вакытында ультратавыш кулланыла. Бит тиресен тарттыруның әлеге ысулын Дженнифер Лопес, Ким Кардашьян, Дженнифер Энистон, Катя Лель, Ольга Орлова, Варвара, Лёля Турубара, Артур Цветков кебек популяр кешеләр кулланган. Бу күз кабагы тиресенең асылынып төшүен кисәтә, борын-ирен җыерчыкларының тирәнлеген киметә, бит тиресен тарттыра, бит-йөз формасын яхшырта.

«СкинМед» белгечләренә 30-50 яшьлек пациентлар күп килә. Еш яңгырый торган үтенеч – көзгедәге чагылыш илһамландыруын дәвам итсен. Иң өлкән ханымга – 70 яшь. Ул процедурага юбилее алдыннан килгән, кунаклар каршында күркәмрәк күренәсе килә. Процедура чыннан да үзенә үзе ясаган бүләк булып чыга.

«СкинМед» белгечләре тарафыннан операциясез яшәрү процедурасын куллануның өч сәбәбе:

- Куркынычсыз. Клиника өчен бу – өстенлек. «СкинМед» бары тик бөтен тиешле клиник сынаулар уздырылган методикаларны гына куллана.
- Нәтиҗәлелек. Шуңа күрә бу технологияләр йолдызлар арасында бик популяр.
- Радикаль тыкшынуның булмавы. Әлеге процедуралар табигый матурлыкны саклый. Шуңа аларны төрле яшьтәге һәм төрле конфессиягә караган ханым һәм туташлар куллана ала. Т

Процедурага кадәр

Процедурадан соң, 180 көн

Процедурага кадәр

Процедурадан соң, 450 көн

Процедурага кадәр

Процедурадан соң, 120 көн

Рөстәм Нургалиев, Казан ислам университеты дини дисциплиналар кафедрасының өлкән укытучысы

– Без – Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылган. Ул яратканны төзәтү тәкәбберлек һәм дөрес түгел. Без шулай ук Аллаһның сынау сыйфатында төрле авырулар, чирләр һәм алар белән бергә дәвасын да җибәрүен беләбез. Әмма дәвалау белән Аллаһ яратканга тыкшыну чиген тоя белергә кирәк. Шәригать хирургия юлын тыя, әмма яшьлекне табигый саклау буенча заманча ысулларны рөхсәт итә. Хәләл сертификаты СкинМед клиникасы технологияләренең экспертлар тарафыннан җентекләп өйрәнелгәнен һәм бу технологияләрнең тышкы кыяфәтне карау буенча рөхсәт ителгән методикаларга керүен аңлата.

** Альтера-терапия (Ultherapy®) – дөньядагы бердәнбер операциясез бит тиресен тарттыру һәм микрофокуслы ультратавыш ярдәмендә җыерчыкларны киметү технологиясе.*

*** Пикосекундлы лазер ярдәмендә бит тиресен тарттыру – тиренең өске катламнарына операциясез яшәртү тәэсире ясый торган косметик процедура. Пикосекундлы лазер шулай ук җөйләрне, акне, шрам, татуировка эзләрен бетерү өчен кулланыла.*

Фотолар «СкинМед» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

–МИН ЯБЫК ИШЕК АРТЫНДА УТЫРУЧЫ ДИРЕКТОР ТҮГЕЛ

Алия Паутова, «Сезнең Салым Консультантыгыз» компаниясе җитәкчесе, бизнес белән уңышлы идарә итә, ике бала тәрбияли, бөек шәхесләрнең биографияләрен укый һәм өзлексез уку-өйрәнүдә.

ҺӘРВАКЫТТА ДА ҮЗЕМНЕҢ ЭШЕМ БУЛУЫН ТЕЛӘДЕМ

– Башта бу бары тик хыял гына иде, ә аннан соң конкрет хисапчылык юнәлешен алды, – дип сөйли Алия. – Чаллыда икътисад-төзелеш көллиятен тәмамладым, аннан соң Казанда Социаль һәм гуманитар белем институтында укыдым. Белгечлегем буенча эшли башладым һәм үз бизнесымны булдыру турындагы хыялымны тормышка ашыру мөмкинлеген эзләдем. Барысы да килеп чыкты – мин инде сигез ел дәвамында үз компаниямне җитәклим! Ул чакта, 2014 елда, миңа әнием һәм ирем бик булышты – беренче балам белән декрет ялында утырган вакыт иде. Бүген компания штатында инде ун кеше санала, барлык хезмәткәрләр дә ышанычлы, озак вакыт эзләгәннән соң сайлап алынганнар дияргә кирәк, шуңа күрә мин аларга үземә ышанган кебек ышанам. Һәм хәзер, кызым белән декретта чакта, минем үземә көне буе эшләмәскә дә була – командамның сынатмаячагын беләм. Бу бик мөһим, чөнки безнең эшчәнлек клиентларыбызның финанслары белән бәйле, ә бу гаять зур җаваплылык.

УКЫРГА, УКЫРГА ҺӘМ ТАГЫН БЕР КАТ УКЫРГА!

Хисап һәм салым исәбе – бик тиз үзгәрүчән өлкә, күңелсезләнеп торырга вакыт юк, яңа төзәтмәләр, кагыйдәләр гел кереп тора. Мин Мәскәү профессиональ хисапчылары институты әгъзасы булып торам, һөнәри баш хисапчы аттестатым бар. Аны мәҗбүри 40 сәгать укулар үтеп, ел саен раслап торам. Күптән түгел генә тагын һөнәри салым консультанты аттестатын да алдым. Үсеш һәм уку-өйрәнү безнең өчен бик кирәк! Моннан тыш даими рәвештә семинарларда, вебинарларда, форумнарда катнашам. Командам да миннән калышмый, әйтик, хәзерге вакытта кадрлар бүлеге укулар үтә.

БАШЫМНЫ ЯЛ ИТТЕРЕРГӘ КИРӘКЛЕГЕН АҢЛЫЙМ

Өстәвенә, ял миңа гына түгел, коллективка да кирәк, шуңа күрә без кызыклы кешеләр белән очрашулар, мастер-класслар кебек чараларга йөрибез, чит шәһәрләргә экскурсияләргә барабыз һ.б. Кая да булса чыгу-бару традициягә әйләнде – гадәттә бу августта, хисап периоды тәмамланганнан соң оештырыла.

Үзем хәзерге вакытта гарәп хәрефләрен өйрәнәм, бассейнга йөрим, балалар белән шөгыльләнәм, күптән түгел генә МАК карталарны куллану буенча курслар уздым. Укырга яратам – бу бизнес, шәхес буларак үсеш, биографияләр турындагы китаплар. Күптән түгел генә Лев Толстой биографиясен укыдым, Мөхәммәд Пәйгамбәр тормышы белән кызыксынам, алга таба планда – Джеки Чан.

Аңлашыла ки, тәүлектә 24 сәгать кенә, һәм бөтенесенә дә өлгерергә кирәк, бу очракта тайм-менеджмент булыша. Әлеге дә баягы бу тема турында да күп укыйм, тәҗрибәдә кулланам. Үз көнемне төгәл планлаштырам, иртән торгач, бүген нишләргә, дигән нәрсә юк – барысы да алдан билгеләп куелган. Кул астында эшләүчеләремне тайм-менеджментка өйрәтергә тырышам, тиздән безнең күчмә киңәшмә булачак, һәм бу регламентның бер пункты булып тора.

НИ ӨЧЕН КЛИЕНТЛАР БЕЗНЕҢ КОМПАНИЯНЕ САЙЛЫЙ?

Әлеге сорауга мин үзем төгәл җавап бирдем инде. Беренчедән, бездә кадрлар гел алмашып тормый, бөтенесе дә күптәннән эшли. Хезмәткәрләрнең даимилеге, тотрыклылыгы – клиентлар өчен бик мөһим, чөнки бу бит гаилә табибы кебек синең бөтен тарихыңны, проблемаларыңны белә, ничек булышырга икәнлеген аңлый. Шуңа да кеше ел саен шул ук салым консультанты белән эшли икән, бу ышаныч уята.

Икенчедән, клиентларга минем аларны шәхсән үземнең белүем, кайбер эшләрен өлешчә үзем алып баруым да ошый. Мин ябык ишек артында утыручы, вазыйфасына бары тик контрольлек кенә кергән директор түгел. Мин һәрвакыт аралашуга һәм ярдәм кулы сузарга әзер. Шуңа күрә дә безнең компанияне кешеләр дуслары һәм танышларына тәкъдим итә, дип уйлыйм. Сүз уңаеннан, клиентларыбызның 90%ка якыны диярлек безне нәкъ менә бер-берсеннән ишетеп эзләп тапкан. Ышанычлы тәкъдим – клиентларыбызның үз хисап һәм салым исәбе эшләрен безгә ышанып тапшыруларының өченче сәбәбе әнә шул.

Компаниянең адресы һәм телефоннары:
Яр Чаллы ш., Тынычлык пр., 25а йорты.
Телефон (8552) 58-88-52, 8-927-466-06-56.
info@vnlnch.com, инстаграмм vnk_chelny,
сайт vnknch.com.

Фото «Сезнең салым консультантыгыз» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА





МОҢАРЧЫ БУЛМАГАН ЭПОС

Ксения Сёмина

«Туган Атаман каршысында дер-дер калтырап торган Гөлчәчәкне иңеннән кочты.

– Син бу кызны алып китмәкче буласыңмы?

– Безгә түләргә ун тәңкә көмеш таба алмагач, алып китми нишлим инде? – диде Атаман.

Дулкынлануын көчкә тыеп, Туган Атаманга туры карады:

– Гөлчәчәк урынына, сезнең белән мин китәм! Минем һөнәрләрем күп, сезгә кирәгем чыгар».

Легендар язучы Зөлфәт Хәкимнең «Туган батыр» әкият-повестендагы төп геройның маҗаралары әнә шулай башланып китә. Шул ук исемдәге проект командасының максаты – аз да түгел, күп тә түгел, яңа татар эпосын һәм хәзерге заманның гаммәви мәдәниятендә популяр башка геройларны узып китәчәк батыр образын булдыру. Алга куелган бурычны әлеге образ аеруча катлауландыра. Популяр маглар, суперкешеләр, бернинди принциплары булмаган медиа һәм аниме персонажлары урынына

Фотолар «Туган авылым» милли комплексының матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА. 6+

Сулдан уңга:
язучы **Зөлфәт Хәким,**
Татарстан мөфтие **Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
эшмәкәр, хәйрияче, «Туган авылым» милли комплексын гамәлгә куючы,
«Туган батыр» проектының авторы һәм оештыручысы **Радик Абдрахманов.**

авторлар гаделлек, намуслылык, кыюлык, мәхәббәт кебек төшенчәләрне үзенә идеал итеп куйган гап-гади малайны сайлап ала. Проект инициаторларын менә шундый, чын мәгънәсендә титаник эшкә керешергә нәрсә мәҗбүр иткән соң?

– Герой булмау! Әйе, балалар һәм өлкәннәр өчен милли әдәбиятыбызда Былтыр, Камыр батыр һәм башкалар кебек геройлар бар. Тик исемен атау белән кем турында сүз барганын һәркем аңларлыгы юк иде. Мин әнә шундый геройны булдыру идеясе белән мавыгып киттем, – ди эшмәкәр, хәйрияче, «Туган авылым» милли комплексын гамәлгә куючы, «Туган батыр» проектының авторы һәм оештыручысы Радик Абдрахманов. Аның ниятен шунда ук Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм язучы Зөлфәт Хәким күтәреп ала.

Берничә ай эчендә проект командасы чын каһарман образларын, диниман идеяләрен, төп милли, мәдәни, кешелек кыйммәтләрен колачлаган экият-повесть булдыра.

БАТЫРЛАР БЕЗНЕҢ АРАДА

Әнә шулай итеп Туган исемле малай, аның дуслары Гөлчәчәк, дошманы Карабаш, аларның этиәниләре һәм күршеләре – Имәнле авылы кешеләре, Имәнле урнашкан ил белән идарә итүче саран һәм җавапсыз Котсыз хан, урман юлбасарлары, урман халкы барлыкка килә. Имәнлегә килеп, кайгы-хәсрәт һәм вәсвәсә таратып йөрүче җен-пәриләр дә өстәлә. Вакыйгалар шартлы рәвештә урта гасырларда бара, әмма Зөлфәт Хәким андагы хәлләрне шундый итеп тасвирлауга ирешә ки, әйтерсең, анда бүгенгебез турында бәян кылына.

Без китапны ачып җибәрүгә үк, бер-бер артлы төрле авыр хәлләрдән чыгу юлын таба барган Туган өчен җан ата башлыйбыз. Шул ук вакытта аңа көнләшеп тә куябыз, чөнки Туган малай эшләгәне өчен соңыннан оят булырлык бер гамәл дә кылмый. Авторлар фикеренчә, хәзерге заман герое образының нигезендә нәкъ менә шушы сыйфат ята. Татар милли мәдәнияте

иң баштан ук ислам диненә таянган. Иң борынгы сюжетлар безгә исламнан килгән. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы Коръәннең 12 нче сүрәсен бәян кыла. Иң борынгы җырулар – мөнәҗәтләр дә Аллаһка багышланган.

«Мәдәният» сүзе мөселманнар өчен изге Мәдинә шәһәре исеменнән килеп чыккан. XIX–XX гасырларда халкыбызның иң алдынгы фән эшлеклеләре һәм зыялылары мәдрәсәләрдә белем алган.

Яңа татар эпосын уйлап табучылар, повестьның төп геройларының образларын һәм мотивларын эзләп, хаклы рәвештә дингә мөрәҗәгать итә.

– Пәйгамбәребезнең һәм аның сәхабәләренең тормышы, гомумән ислам тарихы каһарманлыкның физик көч кенә түгеллеген, ә ахлакый тарафы да булырга тиешлеген күрсәтә, – ди Камил хәзрәт Сәмигуллин. – Балалар тәрбияләүгә бар гомерен биргән әни кеше дә, һәр көн бик оста, бик тәмле итеп икмәк пешерүче дә, безгә кирәкле ачыш ясау өчен, еллар буе лабораториядә утыручы галим дә – барысы да батырлар ул.

ИҢ ЗУР СЫНАУ

Сюжетның башка юнәлеше дә бар.

– Мине Туган батырның туган җиренә, туган ягына мәхәббәте, аларны саклагандагы кыюлыгы рухландыра. Гомумән, мәхәббәтнең дөньяны коткарачагына ышанам, – дип сөйли Радик Абдрахманов.

Бу мәхәббәт даими рәвештә сынауларга дучар ителә. Бер-берсен коткарып калу өчен, Туган белән Гөлчәчәккә караңгы көчләр хөкем сөргән теге дөнья – Пәрдә арты иленә юл тотарга туры килә. Үз кубызларына биетергә омтылып, җен-парилар балаларны аларның үз аң төпкелләренә күз салырга мәҗбүр итә. «Минем өчен иң куркынычы – курку үзе. Мин куркудан куркам!» – ди Туган Иблискә.

– Минем тормышым һәрдаим диярлек явызлыкка каршы, барыннан да элек үземдәге явызлыкка каршы көрәштә узды. Биографиям шактый бай, анда драматик мизгелләр күп. Шәхес буларак юкка чыгу чигенә, үлемгә бик якын килгән вакытларым да бар иде. Мин хәзер дә чир белән көрәшәм, ләкин рухи түгел, ә физик авыру турында сүз бара. Мин ничек исән калдыммы? Коткару-савыгу сорап, Аллаһы Тәгаләгә ялвардым. Ул миңа тиешле җәзаны җибәрде һәм шул рәвешле мине коткарды, – ди Зөлфәт Хәким.

Туганның антагонисты Карабаш – йомшак холыклы, ялкау, көнче малай. Ул Туган белән Гөлчәчәк арасындагы кебек мөнәсәбәтләр корырга тели, әмма дус булу өчен сабырлыгы җитми. Карабаш авылдашларына карата гел берәр төрле хәйлә кора, ә Туганның физик һәм рухи өстенлеге аның көнчелек утына май гына сибә. Киләсе китапларда бу каршылык башка югарылыкка күтәреләчәк һәм ике егет тә тормыштан сабак алачак.

– Үз эгоңны, үз нәфесеңне җиңәр өчен, зур көч кирәк. Без һәрдаим сынауларга дучар ителәбез, ышаныч һәм өмет арасында торабыз. Безнең өчен бу – Хак Тәгаләне тануга, аңа иман китерүгә бер мөмкинлек. Пәйгамбәребез: «Мин кешеләрнең әхлакларын яхшырту өчен килдем», – дип әйтә. Әхлагың яхшырак булган саен, син Аллаһы Тәгаләгә шулкадәр якынрак, – ди Камил хәзрәт.

КОДТА КӨЧ

Зөлфәт Хәким сатираны һәм күп очракта усал сатираны, турыдан ярып әйтүне яратуын яшерми, ләкин балаларга тәгаенләнгән бу әсәрдә андый нәрсәдән аңлы рәвештә тыелырга тырыша. Проект авторлары Туган малай образын идеаль итеп сурәтләргә тели. Әмма киләсе китапларда Туган батыр инде балалыктан чыгачак. Ә өлкәннәр тормышында төрле коткы сала торган нәрсәләр бихисап, югалтулар да, катлаулы сайлау алдында калу очраклары да була.

– Миңа рафинадланган, артык шомартылган, артык дөрес геройлар ошап бетми. Аларда тормышчанлык юк. Туган батыр андый булмаячак. Мин берничә эпизод уйлап таптым, аларда без Туганның ниндидер тискәре хис-тойгылар да кичерергә сәләтле икәнен күрербез. Әйтик, хезмәтендә бик алга китеп янә кызга күз ата башлаган Карабаштан Гөлчәчәкне көнләү кебек, – дип аңлата Зөлфәт Хәким. – Хаталары да, гаеп хисе дә булачак. Мин китап укучыларның, беренче чиратта балаларның, герой белән бергә шикшөбһәгә бирелүен, аның хаклымы-түгелме икәнлеге турында бәхәсләшүләрен телим.

– Кинотеатрларда супергеройлар турында Марвел фильмнарына чиратларны күргәч, бик кызганыч булып китә. Мин үзебезнең дә шундый популяр персонажларыбыз булуын телим, – дип белдерә Радик Абдрахманов.

Туган батыр шундый персонаж дәрәҗәсенә җитәрлек булып үсеп китсен өчен, ул кулдан килгәннең барысын да эшли. Китаплар – эшнең нигезе генә. Коллекцион сынчыклар, «мерч» (логотиплы, символикалы



кием-салым, әйберләр), компьютер уены җитештерелә башлаган инде. Ел саен «Туган авылым» комплексында уза торган милли тамаша өчен номер әзерләнә, комикслар идеясе дә карала. Һәм хәтта NFT платформасында да цифрлы предметлар һәм персонажлар ясалган. Әмма бөтен бу чаралар Туган батырга күпкә танылганрак һәм рекламаланган Үрмәкүч-Кеше, Бэтмен, Наруто белән ярышта ярдәм итәрме? Шул ук вакытта нәкъ менә Татарстан проектының өстенлеге бар. Авторлар Туган батыр галәмен милли мәдәни кодлар нигезендә кора, ә бу кодлар, башка культуралардан аермалы буларак, генетик хәтер һәм күзаллауны уятып җибәрә. Камил хәзрәт һәм аның хезмәттәшләре, тарафдарлары – дин белгечләре һәм тарихчылар да тарихи тикшеренүләр алып бара.

УК КАЯ КҮРСӘТӘ

Туган батырның төп символы – югарыга төбәлгән уклы җәя. Тарихчы Михаил Худяков сүзләренчә, нәкъ менә шундый сурәт Казан татарларының милли гербы саналган.

Туган батыр гербындагы серле сигезпочмак, Зәһир балдагы, хәтта аерым персонажлар да – һәркайсы туган төбәгебез тарихына һәм динебезгә бәйле вакыйгаларга ишарәли, болар хакында повестьның алдагы кисәкләрендә сүз күп булачак.

– Шифрлар – урта гасырлар мөселман дөньясында бер аралашу алымы ул. Сәлҗүк келәмнәрендә, мәсәлән, андагы бизәкләрне ясаучылар, аны сатучылар турында мәгълүмат бирелә, яки ул келәмнәрне кулланачак кешеләргә юлламалар урын ала. Халкыбызның символлары фольклорда да, борынгы текстларда да очрый, – ди Камил хәзрәт. – Мәчетләрдә ярымайның сулга каравы да юкка түгел. Бу – үсеп бара торган ай, ул «башлану, башлангыч» дигәнне аңлата. Ә иске каберлекләрдә ярымай уңга карый. Бу исә юлның ахыры дигән сүз.

Иске мәчетләрдә еш кына лалә һәм гөлчәчәк рәвешендәге бизәк очрый. Гөлчәчәк – Пәйгамбәребез чәчәге, аның исеме Мөхәммәд шул шәкелдә языла. Лалә гарәпчә «Аллаһ» дип язуны хәтерләтә. 99 лалә Аллаһның 99 исемен белдерә. Һәр бизәк билгеле бер мәгънәгә ия. Бу гореф-гадәтләрнең бер өлеше юкка чыккан, әмма хәзер аларны яңадан торгызу, кайтару мөмкинлегебез бар.

Символлардан тыш, повестьта Шүрәле, Су анасы һәм башка танылган персонажлар да пәйда була. Алар төп геройлар белән бергә үсеп-үзгәреп бара. Әкияти тормышның яңа борылмасын Туган батыр әсәре беренче чиратта кемгә тәгаенләнгән, шулар, ягъни балалар үзләре уйлап таба.

– Мин бу проект турында «Бала-Сити» мәктәбендәге эшкуарлык полигонында чыгыш ясадым. Без җиденче сыйныф укучыларына балалар аудиториясендә бу экиятебезне рекламалау-тарату чараларын, юлларын уйлап табу турында тәкъдим ясадык. Балалар китапны укып чыкты да, мавыгып китеп, бик күп кызыклы идеяләр тудырды, – дип сөйли Радик Абдрахманов. – Алар, мәсәлән, персонажларның коллекцион карточкалары белән өстәл уены ясарга, китаптан туп-туры онлайн-квестка юл ача торган QR-код куярга, геройларыбыз рәвешендәге «скрепыш»лар булдырырга һәм башка нәрсәләрне тәкъдим итте. Без, һичшиксез, бу ысулларны кулланачакбыз. Дөньяданиләр барганын һәм нәтиҗәгә ирешү өчен нәрсә эшләргә кирәклеген балалар кайвакыт бездән яхшырак аңлый. Гомумән, аларның энергиясе проектка бик кирәк!

КАРАҢГЫ СУКМАК

Эпосның 1100 данәлек символик тиражлы беренче китабы дөнья күргән инде. Анда әкиятне дүрт телдә – рус, татар, инглиз һәм гарәп телләрендә укырга була. «Туган батыр»ны уйлап табучылар аны башка телләргә дә тәрҗемә итәргә планлаштыра. Татар мәдәнияте һәм милли кыйммәтләребез турында чит ил аудиториясенә җиткерүнең бик яхшы ысулы ул. Әмма проектның иң зур кыйммәте, мөгаен, башкададыр. Аның авторлары, асылда, традицион рухи һәм сәнгати культура белән бүгенге җәмгыятьнең модельләрен үз эченә алган яңа милли миф булдырырга ниятли.

– Мин мәдәният яки сәнгать әсәрләре ярдәмендә кемне дә булса тәрбияләргә яки үзгәртергә мөмкин дип уйламыйм. Әшебезнең максатын бүтәндә күрәм, – ди Зөлфәт Хәким. – Бала чагымда бервакыт шундый вакыйга булды. Инде караңгы төшкәч, авылда өйгә бакча артындагы тар сукмактан кайта идем. Һәм кайсыдыр мизгелдә юлны югалттым. Мин өйгә илтә торган ул сукмакның шунда кайдадыр караңгылыкта икәнен беләм, тик аны таба гына алмыйм. Без балалар һәм өлкәннәр өчен үзебезгә таба илтә торган сукмакны яктыртып бирә алабыз. Аларга менә шул рәвешле барасы юлны, кыйбланы күрсәтәбез.

Туган батыр

Реклама